**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында

Россия Федерациясе Урман кодексының 86 статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъекты урман планының үрнәк формасын һәм составын, аны әзерләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 декабрендәге 692 нче боерыгы нигезендә һәм Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының уңай бәяләмәсен исәпкә алып **карар бирәм:**

1. Кушымтада теркәп бирелгән Татарстан Республикасы Урман планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Урман планын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә, шулай ук үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Урман планын гамәлгә ашыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» 2009 елның 16 мартындагы ПУ-146 номерлы Указы;
Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» Указына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 23 октябрендәге ПУ-1014 номерлы Указы.

5. Әлеге Указ 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 24 декабрь
№ ПУ-880

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «24 »декабрендәге
ПУ-880 номерлы Указы белән
расланды

# Татарстан Республикасы
# УРМАН ПЛАНЫ

**Эчтәлек**


| | |
|---|---|
| Кереш | 6 |
| I. Татарстан Республикасы турында, Урман планын эшләүнең мәгълүмати һәм методик нигезләре турында мәгълүмат | 7 |
| 1.1. Татарстан Республикасы турында гомуми мәгълүмат | 7 |
| 1.2. Табигать-климат үзенчәлекләре, шул исәптән төп климат күрсәткечләренең үзгәрүе | 14 |
| 1.3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үзенчәлекләре | 17 |
| 1.3.1. Халыкның тулаем саны | 18 |
| 1.3.2. Шәһәр халкы | 18 |
| 1.3.3. Авыл халкы | 18 |
| 1.3.4. Кеше саны 100 меңнән артып китә торган торак пунктлар | 19 |
| 1.3.5. Халык эшли торган хуҗалык тармаклары | 19 |
| 1.4. Урман мәйданнарының административ районнар һәм җир категорияләре буенча бүленеше турында мәгълүмат | 20 |
| 1.4.1. Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының бүленеше турында элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә мәгълүмат | 20 |
| 1.4.2. Торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының бүленеше турында элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә мәгълүмат | 22 |
| 1.4.3. Оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының бүленеше турында элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә мәгълүмат | 23 |
| 1.4.4. Махсус саклanучы территорияләр һәм объектлар җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының бүленеше турында элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә мәгълүмат | 23 |
| 1.5. Башлангыч белешмәләр алу чыганаклары турында мәгълүмат | 24 |
| 1.6. Урман үсә торган районнарга бүленеш | 24 |
| 1.7. Гамәлдәге бүленешкә анализ һәм урманнар мәйданын һәм урманнар составын максатчан билгеләнеше һәм саклаучы урман категорияләре буенча бүлү динамикасы | 26 |
| 1.8. Махсус саклanучы табигать территорияләре чикләрендә урнашкан урманнар турында мәгълүмат | 32 |
| 1.9. Урман планын эшләүнең методологик һәм методик үзенчәлекләре | 36 |
| II. Элеккеге Урман планы гамәлдә булган чорда урманнардан файдалануны оештыруга, урманнарны саклау, яклау, яңадан торгызу буенча чаралар үтәлүенә һәм урманнарның сыйфатламаларын үзгәртүгә бәяләмә | 37 |
| 2.1. Урманнардан файдалану төрләре буенча урманнардан файдалануда планлаштырылган күләмнәргә ирешүне бәяләү | 37 |
| 2.2. Урманнарны фактик үзләштерүгә һәм агач материалы алуның мөмкин булган күләменә анализ | 40 |

| | |
|---|---|
| 2.3. Урманнарны саклау, урманнарны янгыннардан саклауны оештыру чаралары | 42 |
| 2.4. Урманнарны саклау чаралары | 43 |
| 2.5. Урманнарны торгызу чаралары | 44 |
| 2.6. Урман үрчетү һәм җирләрне рекультивацияләү чаралары | 48 |
| 2.7. Урманнар мәйданнарының һәм агач материалы запасының урман хасил итүче төп токымнар һәм куаклыклар буенча бүленеше | 48 |
| 2.8. Урманнар мәйданының агач токымы төркемнәре һәм яшь төркемнәре буенча бүленеш динамикасы | 50 |
| 2.9. Урманнар мәйданының яшь төркемнәре кисемендәге тыгызлык, бонитет классы буенча үзгәрүе | 51 |
| 2.10. Утыртылган урманнарның таксация сыйфатламалары үзгәрүе | 52 |
| 2.11. Урманнарның зәгыйфьләнү, начарлану һәм һәлак булу сәбәпләре | 53 |
| III. Урман ресурсларын һәм урманнарның тирәлек булдыру, су саклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы функцияләрен, урман продукциясе базарларын һәм урманнарны үзләштерүнең киләчәген бәяләү | 57 |
| 3.1. Урман ресурсларын бәяләү һәм киләчәктә алардан халыкның үз ихтыяҗлары өчен файдалану мөмкинлеге турында, шулай ук Россия Федерациясенең аз санлы төп халыклары тарафыннан урманнардан файдалану турында мәгълүмат | 57 |
| 3.2. Инвестиция проектлары турында мәгълүмат | 58 |
| 3.3. Агач материалын һәм башка урман продукциясен сату базарлары | 59 |
| 3.4. Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм аларны җыю, азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю, чәер әзерләү өчен файдалану | 59 |
| 3.5. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатында файдалану | 59 |
| 3.6. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану | 60 |
| 3.7. Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару максатларында файдалану | 61 |
| 3.8. Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылма ятмаларны эшкәртү эшләрен башкару, сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехника корылмаларын, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану | 61 |
| 3.9. Урманнардан файдалануның башка төрләре өчен урманнар потенциалын бәяләү турында мәгълүмат | 62 |
| 3.10. Транспорт юллары төзү, аларны ремонтлау һәм карап тоту ихтыяҗы турында мәгълүмат | 63 |
| 3.11. Экологик потенциалны, урманнарның тирәлек булдыру, су саклагыч, саклау, санитария-гигиена, савыктыру потенциалын һәм башка функцияләрен бәяләү | 64 |

| | |
|---|---|
| IV. Татарстан Республикасы Урман планының, чаралар башкаруның максатлары һәм бурычлары һәм Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорга план күрсәткечләре | 66 |
| 4.1. Татарстан Республикасы Урман планының икътисад, экология һәм социаль өлкәләрдәге бурычлары һәм максатлары | 66 |
| 4.2. Урманнарның экологик потенциалын саклау, климат үзгәрешләренә яраклашу һәм урманнарның тотрыклылыгын арттыру буенча планлаштырыла торган чаралар | 67 |
| 4.3. Урманнарны фактик үзләштерү мөмкинлекләрен анализлау һәм бәяләү нигезендә урманнардан файдалануның перспективалы юнәлешләре, урманнарны төп төрләре буенча файдалануны арттыру, Урман планын гамәлгә ашыру чорына план күрсәткечләре | 69 |
| 4.4. Үзләштерү интенсивлыгы буенча бүлеп, файдалануның төрле төрләре өчен планлаштырылган урманнарны үзләштерүне зоналарга бүлү | 81 |
| 4.5. Урман һәм урман эшкәртү инфраструктураларының, аларның булуын һәм урманнардан файдалануның төрле төрләре өчен урманнарны үзләштерү перспективаларын исәпкә алып, планлаштырылган үсеше | 84 |
| 4.6. Урман кишәрлекләрен план буенча файдалануга тапшыру турында белешмәләр | 84 |
| 4.7. Урманнарны янгын куркынычы янау класслары буенча бүлү, урманнарны янгыннардан саклау буенча чаралар үтәүнең план күрсәткечләре | 85 |
| 4.8. Урманнарны саклау буенча чаралар үтәлешенең план күрсәткечләре | 89 |
| 4.9. Урман орлыкчылыгы объектлары һәм урманнарны торгызу һәм урман үрчетү өчен инфраструктура турында мәгълүмат | 90 |
| 4.10. Урманнарны саклау буенча чаралар үтәлешенең план күрсәткечләре | 91 |
| 4.11. Планлаштырыла торган объектлар, сроклар, күләмнәр һәм, урман кишәрлекләрен проектлауны, урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлүне дә кертеп, урман корылышының башка төрле чаралары | 93 |
| V. Урман хуҗалыгын алып баруның төбәк системасын оештыру, ресурслар һәм кадрлар белән тәэмин итү | 95 |
| 5.1. Дәүләт хакимияте органының структурасы | 95 |
| 5.2. Урман хуҗалыгын алып баруның матди ресурслары һәм кадрлар белән тәэмин ителеше турында мәгълүмат | 95 |
| 5.3. Файдалануның төрле төрләре өчен тапшырылган урманнардан файдалануны, аларны саклауны һәм торгызуны оештыру турында мәгълүмат | 98 |
| 5.4. Урманнарны саклау, яклау һәм торгызу буенча дәүләт (муниципаль) бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр турында мәгълүмат | 98 |

| | |
|---|---|
| 5.5. Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман сагын) гамәлгә ашыруны оештыру турында, контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында мәгълүмат | 99 |
| 5.6. Дәүләт урман реестрын алып баруны оештыру һәм аның төп чаралары турында мәгълүмат | 100 |
| VI. Урман планы чараларын гамәлгә ашыруның икътисадый нәтиҗәлелеген һәм көтелгән нәтиҗәләрен бәяләү | 102 |
| 6.1. Урманнардан файдаланган өчен файдалану төрләре буенча планлаштырыла торган уртача түләү күләме | 102 |
| 6.2. Урманнардан файдаланудан керем алуның файдалану төрләре буенча фаразланган күләме | 102 |
| 6.3. Урманнарның тирәлек булдыру, су саклау, санитария-гигиена һәм башка файдалы функцияләрен икътисадый бәяләү | 102 |
| 6.4. Чараларны финанслау күләмнәрен бәяләү | 102 |
| 6.5. Чараларны гамәлгә ашыруның икътисадый нәтиҗәлелеге | 102 |
| 6.6. Урман планы чараларын гамәлгә ашыруның максатчан фаразланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 103 |

**Кереш**

Татарстан Республикасы Урман планы 2019–2028 еллар чорына түбәндәге материаллар нигезендә әзерләнде:

1) 2011 елның 15 августындагы 557 номерлы; 2012 елның 26 ноябрендәге 792 номерлы; 2013 елның 22 маендагы ОК-01/13 номерлы; 2014 елның 24 мартындагы 2014.5478 номерлы; 2014 елның 8 августындагы 983 номерлы; 2015 елның 17 сентябрендәге 994 номерлы; 2016 елның 15 июнендәге 1010 номерлы; 2016 елның 8 июлендәге 148/4/226 номерлы; 2017 елның 15 маендагы 1017 номерлы шартнамәләр һәм дәүләт контрактлары кысаларында урманнарны 2011 елдан 2017 елга кадәр башкарылган тәртипкә китерү эшләре материаллары;

2) 2016 елның 4 августындагы 092/55Д номерлы; 2016 елның 1 ноябрендәге 092/79Д номерлы; 2017 елның 23 октябрендәге 2017.54195 номерлы дәүләт контрактлары һәм шартнамәләр кысаларында башкарылган Татарстан Республикасы урманчылыкларының урман хуҗалыгы регламентлары;

3) 11К-07/63; Р-17К-09/3; Р-4К-10/1; Р-5К-11/1; Р-4К12/1; Р-14К-12; Р-1К-14/1 номерлы дәүләт контрактлары кысаларында урманнарның сан һәм сыйфат ягыннан сыйфатламаларын билгеләү өлешендә урманнарга 2008 елдан 2014 елга кадәр башкарылган дәүләт инвентаризациясе;

4) 2018 елның 1 гыйнварына Дәүләт урман реестры;

5) 2009-2017 елларга Татарстан Республикасы урманнарының санитар һәм урман патологиясе буенча торышына күзәтү;

6) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш планнары;

7) Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең 2013 елның 30 июнендәге 531 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы.

2019-2028 елларга Татарстан Республикасы Урман планын эшләү Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм «Рослесинфорг» ФДБУ арасында 2018 елның 18 апрелендә төзелгән 1022 номерлы дәүләт контракты нигезендә эшләнде.

Татарстан Республикасы Урман планы Татарстан Республикасының урманнарны планлаштыру документы булып тора һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

## I. Татарстан Республикасы турында, Татарстан Республикасы Урман планын эшләүнең мәгълүмати һәм методик нигезләре турында мәгълүмат

### 1.1. Татарстан Республикасы турында гомуми мәгълүмат

Татарстан Республикасында (алга таба – ТР) 2018 елның 1 гыйнварына Дәүләт урман реестры (алга таба – ДУР) белешмәләре буенча урман фонды урманнарының һәм урман фондына карамый торган башка категория җирләрдә урнашкан урманнарның гомуми мәйданы – 1271,0 мең гектар яки ТР территориясенең 17,5 процентын тәшкил итә. ТР буенча урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә РФ субъектының башкарма хакимият органы булып ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора. Урман фонды җирләрендә урнашкан 1236,3 мең гектар урман яки республикадагы урманнарның гомуми мәйданының 97,3 проценты аның карамагында тора. Моннан тыш, махсус саклануйы табигать территорияләре (алга таба – МСТТ) җирләрендә урнашкан урманнар бар – 28,7 мең гектар яки 2,3 процент, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә – 1,7 мең гектар яки 0,1 процент, торак пунктлар җирләрендә 3,7 мең гектар яки 0,3 процент, башка категория җирләрендә – 0,6 мең гектар (0,1 процентган кимрәк).

2018 елның 1 гыйнварына, ДУР белешмәләре буенча, Татарстан Республикасы урманнары мәйданының муниципаль берәмлекләр (административ районнар) һәм җирләрнең категорияләре буенча бүленеше турында мәгълүмат 1 нче таблицада китерелде.

1 нче таблица

Урманнар мәйданнарының муниципаль берәмлекләр һәм җирләрнең категорияләре буенча бүленеше турында мәгълүмат

| Т/с | Муниципаль берәмлек яки шәһәр | Муниципаль берәмлекнең яки шәһәрнең мәйданы, мең гектар | Урманчылык (урман паркы) | Урманнар урнашкан җирләрнең категориясе, гектар | | | | | | Урман белән капланган мәйдан, процент |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Барлыгы | Урман фонды | МСТТ | Оборона һәм куркынычсызлык | Торак пунктлар | Башка категорияләр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1 | Әгерже | 179,7 | Әгерже | 45346 | 45346 | | | | | 23,8 |
| | | | Барлыгы | 45346 | 45346 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Азнакай | 214,6 | Азнакай | 36743 | 36743 | | | | | 19,0 |
| | | | Бөгелмә | 8157 | 8157 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 44900 | 44900 | | | | | |
| 3 | Аксубай | 143,9 | Аксубай | 25837 | 25837 | | | | | 21,9 |
| | | | Биләр | 5607 | 5607 | | | | | |
| | | | Нурлат | 954 | 954 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 32398 | 32398 | | | | | |
| 4 | Актаныш | 203,4 | Минзәлә | 19897 | 19897 | | | | | 9,8 |
| | | | Барлыгы | 19897 | 19897 | | | | | |
| 5 | Алексеевск | 207,4 | Әлки | 3 | 3 | | | | | 11,3 |
| | | | Биләр | 24933 | 24933 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 24936 | 24936 | | | | | |
| 6 | Әлки | 172,7 | Әлки | 33009 | 33009 | | | | | 21,0 |
| | | | Биләр | 847 | 847 | | | | | |
| | | | Болгар | 2839 | 2839 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 36695 | 36695 | | | | | |
| 7 | Әлмәт | 242,8 | Әлмәт | 40177 | 40177 | | | | | 28,2 |
| | | | Зәй | 4227 | 4227 | | | | | |
| | | | Кәләй | 32901 | 32901 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 77305 | 77305 | | | | | |
| 8 | Апас | 104,8 | Буа | 4581 | 4581 | | | | | 8,5 |
| | | | Кайбыч | 3371 | 3371 | | | | | |
| | | | Идел буе | 1210 | 1210 | | | | | |
| | | | Тәтеш | 51 | 51 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 9213 | 9213 | | | | | |
| 9 | Арча | 184,4 | Арча | 20075 | 20075 | | | | | 11,9 |
| | | | Саба | 3381 | 3381 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 23456 | 23456 | | | | | |
| 10 | Әтнә | 68,1 | Арча | 912 | 912 | | | | | 3,9 |
| | | | Ислэйтар | 1897 | 1897 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 2809 | 2809 | | | | | |
| 11 | Баулы | 120,5 | Баулы | 19737 | 19737 | | | | | 18,1 |
| | | | Бөгелмә | 3636 | 3636 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 23373 | 23373 | | | | | |
| 12 | Балтач | 109,5 | Арча | 11216 | 11216 | | | | | 10,6 |
| | | | Саба | 1210 | 1210 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 12426 | 12426 | | | | | |
| 13 | Бөгелмә | 140,5 | Әлмәт | 2717 | 2717 | | | | | 19,7 |
| | | | Баулы | 3700 | 3700 | | | | | |
| | | | Бөгелмә | 23022 | 23022 | | | | | |
| | | | Лениногорск | 1059 | 1059 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 30498 | 30498 | | | | | |
| 14 | Буа | 152,8 | Буа | 10305 | 10305 | | | | | 6,6 |
| | | | Тәтеш | 147 | 147 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 10452 | 10452 | | | | | |
| 15 | Югары Ослан | 130,3 | Идел буе | 24879 | 24879 | | | | | 18,4 |
| | | | Барлыгы | 24879 | 24879 | | | | | |
| 16 | Биектау | 157,4 | Ислэйтар | 15285 | 15285 | | | | | 19,0 |
| | | | Шәһәр яны | 13838 | 13838 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Мари (бер өлеше) | 186 | | | 186 | | | |
| | | | Саба | 857 | 857 | | | | | |
| | | | Урманчылык-тан башка | 400 | | | | | 400 | |
| | | | Барлыгы | 30566 | 29980 | | 186 | | 400 | |
| 17 | Чүпрәле | 103,0 | Буа | 3051 | 3051 | | | | | 2,9 |
| | | | Барлыгы | 3051 | 3051 | | | | | |
| 18 | Алабуга | 135,2 | Алабуга | 11805 | 11805 | | | | | 13,5 |
| | | | «Түбән Кама» милли паркы | 9240 | | 9240 | | | | |
| | | | Барлыгы | 21045 | 11805 | 9240 | | | | |
| 19 | Зәй | 184,2 | Әлмәт | 7272 | 7272 | | | | | 28,5 |
| | | | Зәй | 14300 | 14300 | | | | | |
| | | | Кәләй | 5392 | 5392 | | | | | |
| | | | Түбән Кама | 27895 | 27895 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 54859 | 54859 | | | | | |
| 20 | Зеленодольск | 140,2 | Зеленодольск | 26356 | 26356 | | | | | 25,8 |
| | | | Кайбыч | 4827 | 4827 | | | | | |
| | | | Идел буе | 1397 | 1397 | | | | | |
| | | | «Идел-Кама» ДТБТ | 5921 | | 5921 | | | | |
| | | | Урманчылык-тан башка | 62 | | | | | 62 | |
| | | | Барлыгы | 38563 | 32580 | 5921 | | | 62 | |
| 21 | Кайбыч | 99,5 | Кайбыч | 17093 | 17093 | | | | | 17,2 |
| | | | Идел буе | 680 | 680 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 17773 | 17773 | | | | | |
| 22 | Кама Тамагы | 119,9 | Тәтеш | 10921 | 10921 | | | | | 8,3 |
| | | | Барлыгы | 10921 | 10921 | | | | | |
| 23 | Кукмара | 149,0 | Лубян | 12966 | 12966 | | | | | 19,7 |
| | | | Кызыл Йолдыз | 17 | 17 | | | | | |
| | | | Мамадыш | 1520 | 1520 | | | | | |
| | | | Саба | 17972 | 17972 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 32475 | 32475 | | | | | |
| 24 | Лаеш | 209,4 | Лаеш | 19806 | 19806 | | | | | 15,8 |
| | | | «Идел-Кама» ДТБТ | 4170 | | 4170 | | | | |
| | | | Шәһәр яны | 10679 | 10679 | | | | | |
| | | | Мари (бер өлеше) | 545 | | | 545 | | | |
| | | | Урманчылык-тан башка | 73 | | | | | 73 | |
| | | | Барлыгы | 35273 | 30485 | 4170 | 545 | | 73 | |
| 25 | Лениногорск | 181,3 | Бөгелмә | 246 | 246 | | | | | 26,9 |
| | | | Лениногорск | 51778 | 51778 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 52024 | 52024 | | | | | |
| 26 | Мамадыш | 261,3 | Кама | 18431 | 18431 | | | | | 28,1 |
| | | | Кызыл Йолдыз | 11996 | 11996 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Мамадыш | 46254 | 46254 | | | | | |
| | | | Саба | 576 | 576 | | | | | |
| | | | Урманчылыктан башка | 4 | | | | | 4 | |
| | | | Барлыгы | 77261 | 77257 | | | | 4 | |
| 27 | Менделеевск | 74,5 | Алабуга | 4658 | 4658 | | | | | 5,8 |
| | | | «Түбән Кама» милли паркы | 20 | | 20 | | | | |
| | | | Барлыгы | 4678 | 4658 | 20 | | | | |
| 28 | Минзәлә | 192,0 | Минзәлә | 24095 | 24095 | | | | | 11,2 |
| | | | Барлыгы | 24095 | 24095 | | | | | |
| 29 | Мөслим | 146,4 | Азнакай | 1547 | 1547 | | | | | 18,5 |
| | | | Минзәлә | 26555 | 26555 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 28102 | 28102 | | | | | |
| 30 | Түбән Кама | 161,7 | Зәй | 32536 | 32536 | | | | | 26,4 |
| | | | Кәләй | 19 | 19 | | | | | |
| | | | Түбән Кама | 13571 | 13571 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 46126 | 46126 | | | | | |
| 31 | Яңа Чишмә | 131,8 | Аксубай | 3254 | 3254 | | | | | 10,7 |
| | | | Биләр | 22 | 22 | | | | | |
| | | | Зәй | 7834 | 7834 | | | | | |
| | | | Кәләй | 3368 | 3368 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 14478 | 14478 | | | | | |
| 32 | Нурлат | 229,4 | Әлки | 380 | 380 | | | | | 41,3 |
| | | | Биләр | 11620 | 11620 | | | | | |
| | | | Нурлат | 87591 | 87591 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 99591 | 99591 | | | | | |
| 33 | Питрәч | 134,0 | Кызыл Йолдыз | 4 | 4 | | | | | 12,4 |
| | | | Лаеш | 13548 | 13548 | | | | | |
| | | | Шәһәр яны | 2174 | 2174 | | | | | |
| | | | Саба | 1478 | 1478 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 17204 | 17204 | | | | | |
| 34 | Балык Бистәсе | 204,1 | Кама | 30408 | 30408 | | | | | 25,0 |
| | | | Кызыл Йолдыз | 24016 | 24016 | | | | | |
| | | | Лаеш | 751 | 751 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 55175 | 55175 | | | | | |
| 35 | Саба | 109,8 | Кызыл Йолдыз | 216 | 216 | | | | | 24,6 |
| | | | Саба | 28130 | 28130 | | | | | |
| | | | Урманчылык-тан башка | 56 | | | | | 56 | |
| | | | Барлыгы | 28402 | 28346 | | | | 56 | |
| 36 | Сарман | 138,6 | Азнакай | 7813 | 7813 | | | | | 6,0 |
| | | | Түбән Кама | 1326 | 1326 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 9139 | 9139 | | | | | |
| 37 | Спас | 202,2 | Әлки | 4070 | 4070 | | | | | 9,2 |
| | | | Болгар | 16013 | 16013 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 20083 | 20083 | | | | | |
| 38 | Тәтеш | 163,8 | Буа | 630 | 630 | | | | | 15,9 |
| | | | Тәтеш | 26513 | 26513 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | 27143 | 27143 | | | | | |
| 39 | Тукай | 172,9 | Алабуга | 12590 | 12590 | | | | | 13,0 |
| | | | Минзәлә | 1371 | 1371 | | | | | |
| | | | Түбән Кама | 694 | 694 | | | | | |
| | | | «Түбән Кама» милли паркы | 9373 | | 9373 | | | | |
| | | | Барлыгы | 24028 | 14655 | 9373 | | | | |
| 40 | Теләче | 84,4 | Кызыл Йолдыз | 6353 | 6353 | | | | | 14,9 |
| | | | Саба | 6778 | 6778 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 13131 | 13131 | | | | | |
| 41 | Чирмешән | 136,4 | Чирмешән | 36373 | 36373 | | | | | 25,0 |
| | | | Барлыгы | 36373 | 36373 | | | | | |
| 42 | Чистай | 176,6 | Аксубай | 531 | 531 | | | | | 7,5 |
| | | | Биләр | 7746 | 7746 | | | | | |
| | | | Кама | 5293 | 5293 | | | | | |
| | | | Барлыгы | 13570 | 13570 | | | | | |
| 43 | Ютазы | 76,1 | Бөгелмә | 9072 | 9072 | | | | | 11,0 |
| | | | Барлыгы | 9072 | 9072 | | | | | |
| 44 | Казан шәһәре | 61,4 | Шәһәр яны | 3522 | 3522 | | | | | 9,3 |
| | | | Мари (бер өлеше) | 960 | | | 960 | | | |
| | | | Шәһәр урманы «Аккош күле» | 3547 | | | | 3547 | | |
| | | | Барлыгы | 8029 | 3522 | | 960 | 3547 | | |
| 45 | Буа шәһәре | 1,5 | Урманчылык-тан башка | 39 | | | | 39 | | 2,6 |
| 46 | Зеленодольск шәһәре | 3,8 | Урманчылык-тан башка | 141 | | | | 141 | | 3,6 |
| 47 | ТР буенча барлыгы | 6783,7 | - | 1270993 | 1236256 | 28724 | 1691 | 3727 | 595 | 17,5 |

Урман белән капланган мәйданнарның республиканың аерым муниципаль берәмлекләр буенча гомуми проценты төрлечә һәм физик-географик, климат, туфрак шартларына, стихияле күренешләргә һәм кешенең хуҗалык эшчәнлегенә бәйле. Урман үсемлекләре белән капланган мәйданның территориядәге гомуми җир мәйданына карата нисбәте республика буенча уртача алганда 17,5 процент тәшкил итә, районнар буенча бу күрсәткеч чиктән тыш төрле һәм Чүпрәле районындагы 2,9 проценттан алып Нурлат районындагы 41,3 процент чикләрендә тора.

2018 елның 1 гыйнварына ДУР төзелгәндә урманнарның мәйданнарын күрсәтүдә хаталар җибәрелгән.

РСФСР Министрлар Советының 1960 елның 13 апрелендәге 510 номерлы карары нигезендә Идел-Кама тыюлыгы составына аңа тоташып торучы В.И.Ленин исемендәге Идел ГЭС сусаклагычы (хәзерге вакытта Куйбышев сусаклагычы) акваториясенең 500 метрлы полосасы кертелгән. Тыюлыкның аерылгысыз өлеше булып торган сусаклагычның гомуми мәйданы 1310 гектар тәшкил итә һәм ул 2013 елда Идел-Кама тыюлыгында

урманнарны тәртипкә китерү эшләрен уздырганда исәпкә алынды. 2018 елның 1 гыйнварына ДУР төзелгәндә сусаклагыч акваториясе кертелмәгән.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы, шулай ук ДУР белешмәләре буенча, 2018 елның 1 гыйнварына Лаеш районының башка категория җирләрендә урнашкан урманнарның мәйданы 73 гектар тәшкил итә. Ләкин Егорьево авыл җирлегендә исәпләнгән әлеге урман кишәрлеге Лаеш урманчылыгының 2008 елгы урман фонды җирләре составына кертелгән һәм 2014 елда урманчылык урманнарын тәртипкә китергәндә исәпкә алынган.

Шул рәвешле, МСТТ җирләрендә урнашкан ТР урманнарының гомуми мәйданы 30034 гектар (30,0 мең гектар яки 2,4 процент) тәшкил итә, башка категория җирләрдә – 522 гектар (0,5 мең гектар яки 0,1 проценттан ким). 2019 елның 1 гыйнварына ДУР төзелгәндә әлеге хаталар, фактик белешмәләрне исәпкә алып, бетереләчәк.

Моннан тыш, РФ Оборона министрлыгының 2012 ел, 3 апрель, 771 нче һәм 2017 ел, 6 декабрь, 1254 нче боерыклары нигезендә РФ Оборона министрлыгы карары белән урманнарның торак пунктлар җирләренә тапшырылуы сәбәпле, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан урманнарның мәйданнарындагы үзгәрешләр 2019 елның 1 гыйнварына ДУР белешмәләренә кертеләчәк.

2018 елның 1 гыйнварына Министрлык структурасында 31 «Урманчылык» ДКУ, «Урман янгыннары үзәге» ДБУ, «Лубян урман-техника көллияте» ДБҺББУ, 30 «Урман хуҗалыгы» ДБУ эшли, аларның берсендә, атап әйткәндә, «Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы» ДБУ базасында ТР Урман селекция-орлыкчылык үзәге (алга таба – ТР УСОҮ) оештырылды.

«ТР территориясендә урманчылыклар исәбен билгеләү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2008 елның 17 октябрендәге 320 номерлы Рослесхоз боерыгы нигезендә Министрлык карамагында торган урманнардан элеккеге урман хуҗалыклары чикләрендә 30 урманчылык оештырылды. «ТР территориясендә урманчылыклар исәбен билгеләү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2008 елның 17 октябрендәге 320 номерлы Рослесхоз боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 256 номерлы Рослесхоз боерыгы нигезендә Алабуга урманчылыгының Лубян кишәрлеге урманчылыгы базасында, кишәрлек урманчылыгына бүлмичә генә, Лубян урманчылыгы оештырылды. Шул рәвешле «Урманчылык» ДКУ гомуми саны – 31, кишәрлек урманчылыкларының гомуми саны – 122.

«Урманчылык» ДКУ ведомство территориясендә ТР «Урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре – махсуслашкан учреждениеләр оештырылды, алар урманнарны торгызу, саклау чараларын төп башкаручылар булып тора.

Янгын куркынычсызлыгын һәм урманнарны янгыннардан саклауны тәэмин итү максатларында ТР Министрлар Кабинетының 2011 елның 6 июнендәге 455 номерлы карары нигезендә ТР «Урман янгыннары үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе булдырылды.

«Урман янгыннары үзәге» ДБУ урман фонды җирләре территорияләрендә (шул исәптән шартнамәләр төзү шарты белән арендага тапшырылган урман кишәрлекләрендә дә), шулай ук ТР мөлкәтендә торучы урманнарда урман янгыннарын авиация ярдәмендә һәм җирдә ачыклауны, урман янгыннарын профилактикалауны һәм сүндерүне оештыру өчен булдырылган ТР махсус дәүләт учреждениесе булып тора.

Урман янгыннары үзәген булдыру һәм аны кирәкле техника белән тәэмин итү турында оператив кабул ителгән карарның нәтиҗәсе: 2011-2017 елларда урман фонды җирләре территориясендә бер генә янгын очрагы да теркәлмәде.

«Лубян урман-техника көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе урман секторы өчен урта звено белгечләрен әзерләү белән шөгыльләнүче ведомство буйсынуындагы белем бирү йорты булып тора. Белем бирү йорты 1921 елның 9 мартында ачылган, гамәлдә булган чорында учреждениедә «Урман һәм урман-парк хуҗалыгы», «Бакча-парк һәм ландшафт төзелеше», «Икътисад һәм бухгалтерлык исәбе» белгечлекләре буенча 9000 нән артык белгеч әзерләнде.

Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм укыту процессын оештыру максатларында көллияткә 12 966 гектар мәйданда урман кишәрлеге – «Лубян урманчылыгы» ДКУ даими (вакытын чикләмичә) файдалануга тапшырылды.

Көллияттән тыш, төбәктә шулай ук урман хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен кадрлар әзерләү белән шөгыльләнүче Казан дәүләт аграр университеты эшли.

Министрлык буйсынуындагы ведомство учреждениеләреннән тыш, республикада «Урман хуҗалыгы» ДБУ һәм урман торгызуны һәм урман үрчетүне гамәлгә ашыручы затларның, шул исәптән ТРннан читтә, үренте материалларына булган ихтыяҗын канәгатьләндерү максатларында, барыннан бигрәк селекция нигезендә даими урман үрентеләре орлык базасы объектларын оештыру максатларында, 2012 елның 19 гыйнварында ТР УСОҮ ачылды.

Төбәктә шулай ук РФ Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы (алга таба – РФ ТРЭМ) карамагындагы түбәндәге МСТТ урнашкан:

1) «Идел-Кама» дәүләт табигать биосфера тыюлыгы» федераль дәүләт учреждениесе РСФСР Министрлар Советының 1960 елның 13 апрелендәге 510 номерлы карары нигезендә Раифа урман хуҗалыгының Раифа урманчылыгы һәм Лаеш урман хуҗалыгының Саралы урманчылыгы базасында оеша. Тыюлык территориясе биологик төрлелекнең бай булуы белән сыйфатлана, анда Идел аръягы урман экосистемаларының барча спектры бар – ылыслы, катнаш һәм киң яфраклы урманнар, үләнле һәм сфагнумлы сазлыклар, комлы дала фрагментлары, урман күлләренең, кече елгаларның, шулай ук хәзерге вакытта Идел һәм Кама елгаларының төче су экосистемалары.

2) «Түбән Кама» милли паркы РСФСР Министрлар Советының 1991 елның 21 апрелендәге 223 нче карары нигезендә Алабуга наратлыгының һәм Кызыл Тауның урман биләмәләре базасында табигый урман биләмәләрен – нарат һәм чыршы-пихта урманнарын саклау максатында булдырыла. Алабуга наратлыгы территориясендә я бары нарат урманнары, я аз күләмдә каен катнашкан, аеруча югары җитештерүчәнлеге белән аерылып торган наратлыклар үсә. Кызыл Тау – Урта Идел буеның куе ылыслы тайгага хас булган чыршы һәм пихта табигый рәвештә аның урман-дала белән чиктәш көньяк кырыенда үсә һәм Кама елгасының сул як ярына күчә торган бердәнбер урыны.

Казан шәһәренең шәһәр чите чикләрендә җирле әһәмияттәге МСТТ – Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты МКУ «Лебяжье» шәһәр паркы урнашкан. Шәһәр урман паркының урман кишәрлекләре – болар тармакланган яр-сыза челтәрләре, үзләрендә күлләр һәм сазлыклар барлыкка килгән күпсанлы тирән сөзәк чокырлардан торучы уйсулыклар белән сирәкләнгән нигездә нарат һәм юкә урманнары. Күлләрнең ике төркеме аеруча әһәмиятле – Аккош күле һәм Тирән күлләр. Урман паркының территориясе табигый тереклек итү урыннарына якын, бу хәл аның биологик төрлелекне саклаудагы махсус кыйммәтен ассызыклый һәм Казан шәһәрендә һәм тирә-яктагы поселокларда яшәүчеләр өчен мөһим рекреация әһәмиятенә ия.

Россия Оборона министрлыгының Мари урманчылыгы – Россия Оборона министрлыгының «Урман хуҗалыгы һәм табигатьтән файдалану идарәсе» ФДКУ филиалы (элегрәк Суслонгер урманчылыгы) оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан урманнарда урман хуҗалыгын алып бару максатында оештырылды. Хәрби урманчылык урманнарының бер өлеше ТР территориясендә, Казан шәһәре янәшәсендә урнашкан.

Татарстан Республикасы территориясенең урманчылыклар (урман парклары), урман үсү зоналары, урманлы районнар күрсәтелгән административ бүленеше Татарстан Республикасы Урман планына 1 нче кушымтада күрсәтелде.

## 1.2. Табигать-климат үзенчәлекләре, шул исәптән төп климат күрсәткечләренең үзгәрүе

ТР Көнчыгыш-Европа тигезлегенең көнчыгышында, ике зур елга – Идел һәм Кама тоташкан урында төньяк киңлекнең $47^0$ һәм $54^0$ һәм $54^0$ һәм $57^0$ арасында урнашкан. ТР башкаласы – Казан шәһәре Мәскәү шәһәреннән көнчыгышка таба 797 км ераклыкта тора.

Республиканың гомуми мәйданы 6783,7 мең гектар, 67,8 мең кв.км яки РФ территориясенең якынча 0,4 процентын һәм Идел буе федераль округы (алга таба – ИФО) территориясенең якынча 7 процентын тәшкил итә. Территориянең максималь озынлыгы – төньяктан көньякка таба 290 км һәм

көнбатыштан көнчыгышка таба 460 км. Татарстанның чит ил дәүләтләре белән чикләре юк.

Татарстан территориясе елга үзәнлекләренең куе челтәрләре белән тармакланган калкулыклы-киртләчле тигез җирдән гыйбарәт. Әлеге тигез җирне Идел һәм Кама елгаларының киң үзәнлекләре өч өлешкә бүлә: Идел алды, Кама алды һәм Кама аръягы. Максималь биеклеге 276 метр булган Идел алды Идел буе калкулыгының төньяк-көнчыгыш өлешен алып тора. Кама алдының көнчыгыш өлешенә төньяктан Иж елгасы үзәнлеге аерган Можга һәм Сарапул калкулыкларының көньяк очлары кереп тора. Иң биек урыннар биредә 243 метрга җитә. Көнчыгыш Кама аръягындагы Бөгелмә калкулыгы Татарстанда иң биек дип санала (381 метрга кадәр). Иң тәбәнәк рельеф Көнбатыш Кама аръягы өчен характерлы (нигездә 200 метрга кадәр).

Туфраклар күп төрле – төньякта һәм көнбатышта соры урман һәм көлсу туфраклардан башлап республиканың көньягындагы төрле кара туфрак төрләре булуы белән аерылып тора. Татарстан территориясендә өч төрле туфрак районын бүлеп карыйлар:

1) Төньяк (Кама алды) – ачык соры урман (29 процент) һәм кәсле-көлсу (21 процент) туфраклар аеруча нык таралган, алар нигездә субүләр платоларда һәм тау битләренең югарыгы өлешендә урнашкан. 18,3 процентны соры һәм куе соры урман туфраклары алып тора. Калкулыкларда һәм үрләрдә кәсле туфрак очрый. 22,5 процентны юдырылган туфраклар били, тугай туфраклары – 6-7 процент, сазлык җире – якынча 2 процент. Кайбер районнарда (Балтач, Кукмара, Мамадыш) эрозия көчле, территориянең 40 процентында диярлек эрозия күзәтелә.

2) Көнбатыш (Идел алды) – төньяк өлешендә урман-дала (51,7 процент), соры һәм куе соры (32,7 процент) туфраклар өстенлек итә. Мәйданның зур өлешен көлсу һәм селтеле кара җирләр били. Районның югары өлешләрендә ачык соры һәм кәсле-көлсу туфрак ята (12 процент). Тугай туфраклары – 6,5 процент, сазлык җирләре 1,2 процент алып тора. Районның көньяк-көнбатышында башлыча кара җирләр (селтеле туфраклар) өстенлек итә.

3) Көньяк-көнчыгыш (Кама аръягы) – Чишмә елгасыннан көнбатышка таба селтеле һәм гади кара туфрак өстенлек итә, Кече Чирмешән елгасының уң як яр буе куе соры туфрактан тора. Чишмә елгасыннан көнчыгышка таба – соры урман һәм кара туфрак, районның төньяк өлешендә – селтеле кара туфрак өстенлек итә. Калкулыкларда – урман-дала туфрагы, иңкүлекләрдә – кара җир ята.

Татарстанның иң зур су объектлары – 4 сусаклагыч, алар республиканы төрле максатларда су ресурслары белән тәэмин итә. Болар:

1) Куйбышев – 1955 елда төзелә, Татарстанда гына түгел, Европада да иң зур, Урта Иделдән агып төшкән суны ел сезонына карап көйләп тора.

2) Түбән Кама – 1978 елда төзелә һәм су узелына тәүлеклек һәм атналык су бүлүне тәэмин итә.

3) Зәй – 1963 елда төзелә, ГРЭСны техник яктан тәэмин итә.

4) Карабаш – 1957 елда төзелә, нефть чыгару һәм сәнәгать предприятиеләрен су белән тәэмин итү өчен хезмәт итә.

Республика территориясендә 731 гидортехника корылмасы, 550 буа, 115 чистарту корылмасы, 11 саклагыч дамба бар.

Иң зур елгалар – Идел (республика территориясе буйлап 177 км) һәм Кама (380 км), шулай ук Каманың ике кушылдыгы – Нократ (60 км) һәм Агыйдел (50 км), елына гомуми 234 млрд.куб.метр агымсу (барлык елгаларның гомуми агымында 97,5 процентын) тәэмин итә. Алардан тыш, республика территориясе буйлап тагын якынча 500 кечкенә елга һәм күпсанлы инешләр ага. Су ресурсларының зур запаслары зур ике объект – Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларында тупланган. Республикада шулай ук 8 меңнән артык зур булмаган күл һәм буа исәпләнә.

Елгаларның гидро-энергетик потенциалы Кама елгасында тулысынча йөкләнеш алмаган Түбән Кама ГЭСында гамәлгә ашырыла, ул елына якынча 1,8 млрд. кВт·сәг эшләп чыгара (проект буенча – елына 2,7 млрд. кВт·сәг). Республиканың җир астында җир асты суларының шактый запасы бар – көчле минераллашканнан башлап тозлылыгы аз һәм төче сулар.

Республика чикләрендә климат аермалыклары чагыштырмача зур түгел. Җылы чорның озынлыгы (территория буйлап һава температурасы тотрыклы рәвештә $0^{o}$C тан югары торганда) 198-209 көн, салкын чор – 156-167 көн чикләрендә. Диңгез һәм океан йогынтысыннан еракта урнашуга бәйле рәвештә республика территориясе һава массаларының көнбатыштан күчү дәрәҗәсенең түбән булуы һәм климат континентальлегенең көчәюе белән сыйфатлана, ул кышның озынаюында, фасылларның күчеш чорларының кыскаруында, җәй башында һәм азагында салкын булу куркынычының артуында һ.б. чагыла, һаваның уртача тәүлеклек температурасының +$5^{o}$C билгесе аша күчүе язын – апрель уртасына, ә көзен октябрь уртасына туры килә. Беренче суыклар 10-28 сентябрьдә, соңгылары 10-21 майда күзәтелә. Температураның +$10^{o}$C тамгасыннан тотрыклы күчүе язын – май аеның беренче декадасына, көзен сентябрьнең икенче декадасына туры килә. Язын соңгы салкын һәм көзге беренче салкын даталары арасында суык булмаган чорның уртача озынлыгы үзгәрү территория буенча 106 көннән 150 көнгә кадәр тәшкил итә.

Кайбер елларда уртача күрсәткечләрдән тайпылышлар 30-40 көн һәм аннан да күбрәк булырга мөмкин.

Табигать-климат шартлары, тулаем алганда, урман үсемлекләре үсү өчен кулай, ләкин кайбер елларда табигать шартларының уртача күрсәткечләрдән кисәк тайпылуы – орлыкларга шытып чыгу һәм шытымнарга күтәрелеп китү шартларын начарайта торган корылык чорлары, язын була торган соң һәм көзен була торгын иртә суыклар актив вегетация чорын шактый кыскарта.

Әйтик, мисал өчен, 2010 елгы аномаль корылык Куйбышев сусаклагычында су дәрәҗәсенең кимүенә китерде, эчә торган суның сыйфатына һәм навигациягә чиктән тыш тискәре йогынты ясады. Саеккан су

ярты гасырдан артык су астында яткан торак пунктлар калдыкларын һәм коммуникацияләрне ачты. Сусаклагычта суның дәрәҗәсе бары тик 2012 елда гына тулысынча үз хәленә кайтты. Шулай ук корылык аркасында күпчелек районнарда күршедәге тагын да урманлырак төбәкләрдәге янгыннардан җил белән килгән төтен күзәтелде.

Төбәкнең бар территориясе аша үтүче зур елгаларның суы елгаларның комлы ярларында үсә торган ылыслы агачларның төп массасы өчен җитди куркыныч нәтиҗәләрне булдырмаска мөмкинлек бирде, ләкин республиканың төньяк-көнчыгыш өлешендә өлгергән һәм картайган чыршы урманнары тулаем корыды, ә ахырдан аларны корткычлар зарарлады. ТРның көньяк-көнчыгыш өлешендә 2010 елгы корылыктан иң күп зыян күргән токымнар –каен һәм усак булды, 2010 елның декабрь аенда булган бозлавык та хәлне кискенләштерде, әлеге табигать күренешләре нәтиҗәсендә каен һәм усак урманнары күпләп корый башлады һәм тиз арада ликвидлыгын югалтты.

## 1.3. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үзенчәлекләре

2017 елда ТРда төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча Россиядәге уртача тенденцияләрне арттыра торган тотрыклы уңай динамика күзәтелде, төбәк традицион рәвештә РФнең лидер төбәкләре исәбенә керә. ТР Икътисад министрлыгының хисап белешмәләре буенча, икътисад үсешенә төп өлешне сәнәгать җитештерү, авыл хуҗалыгы һәм сәүдә кертә.

Сәнәгать җитештерүе үсеше 2016 ел дәрәҗәсенә карата 101,8 процент тәшкил итте, төяп озатылган продукция күләме – 2254,4 млрд.сум. Сәнәгать структурасында эшкәртү производствосы өстенлек итә – гомуми күләмнең 69,2 проценты. Эшкәртү производстволарыннан төяп озатылган продукция күләмендә иң зур өлеш традицион рәвештә транспорт чаралары һәм җиһазлары, химия, нефть продуктлары җитештерүгә туры килә.

2017 елда авыл хуҗалыгы продукциясенең күләме 2016 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 5,2 процентка артты һәм 256,1 млрд сум тәшкил итте. Авыл хуҗалыгы җитештерүендә төбәк бөртекле культуралар, шикәр чөгендере һәм бәрәңге үстерү, шулай ук ит, сөт һәм күкәй җитештерү юнәлешендә махсуслаша.

2017 ел йомгаклары буенча ваклап сәүдә итү әйләнеше 843,9 млрд сум яки 2016 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 102,8 процент тәшкил итте. Ваклап сәүдә итү әйләнеше буенча 2017 елгы гыйнвар-ноябрь йомгаклары буенча Татарстан РФ субъектлары арасындагы рейтингта 8 нче урында, ИФО төбәкләре арасында 1 нче урында тора.

Республика предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүчеләрнең уртача айлык хезмәт хакы 2017 елда 2016 ел дәрәҗәсенә карата 6,2 процентка артты һәм 32418,9 сум тәшкил итте.

Республиканың хезмәт базарында тотрыклы вазгыять саклана. 2017 елның декабре азагына халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт

учреждениеләрендә 11,8 мең эшсез граждан яки эшче көчләрнең 0,58 проценты исәптә торган (2016 елның декабре азагына – 0,71 процент).

Төбәктәге демографик вазгыять уңай динамикалы. 2017 ел йомгаклары буенча республикада туучылар саны вафат булучылар санынннан артып китте. Халыкның табигый үсеше 4240 кеше тәшкил итте.

### 1.3.1. Халыкның гомуми саны

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең ТР буенча территориаль органы (Татарстанстат) белешмәләре буенча, 2018 ел башына ТРда халыкның гомуми саны 3 894 284 кеше тәшкил итә. Халыкның тыгызлыгы 57,40 кеше/кв.км. Халык саны буенча Татарстан РФ субъектлары арасында 8 нче урында тора. Татарстан –күпмилләтле республика, 2010 елда Бөтенроссия халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, төбәк территориясендә 173 милләт вәкиле яши. Милләтләр составы буенча 43 муниципаль берәмлекләрнең 32сендә татарлар күпчелекне тәшкил итә, руслар – 10, һәм бер районда халыкның күпчелек өлешен чуашлар тәшкил итә. 10 районда татарлар саны милләтен күрсәтүчеләрнең гомуми исәбеннән 80-90 процентка артып китә. Татарстан Республикасында аз санлы төп халыклар яшәми.

### 1.3.2. Шәһәр халкы

Татарстанстат белешмәләре буенча, 2018 ел башына төбәкнең шәһәр халкы саны 2 990 569 кеше (76,79 процент) тәшкил итә. ТРда икътисадтагы төп җитештерүләрнең, мәгариф учреждениеләренең шәһәр агломерацияләрендә тупланусы һәм туучылар саны артуга бәйле рәвештә, урбанизация процессы, ягъни авыл халкына карата шәһәр халкының өлеше арту дәвам итә.

### 1.3.3. Авыл халкы

Татарстанстат белешмәләре буенча 2018 ел башына авылларда яшәүчеләр саны 903 715 кеше (23,21 процент) тәшкил итә. 2010 елда Бөтенроссия халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча Татарстанда салалар һәм авыллар саны 3 073 берәмлек тәшкил итә. 2010 елда, уртача алганда, бер авыл торак пунктына 304 кеше туры килә, 2002 елда – 321. ТРда беркем дә даими яшәми торган 49 авыл торак пункты бар. Алдагы халык исәбен алу (2002 ел) белән чагыштырганда, алар саны 13 берәмлеккә яки 36,1 процентка арткан.

Республиканың аеруча зур авыл торак пунктларына түбәндәге район үзәкләре керә: Актаныш районы – Актаныш авылы (8,9 мең кеше), Питрәч районы – Питрәч авылы (8,1 мең кеше), Мөслим районы – Мөслим авылы (7,3 мең кеше) һәм Казан шәһәренең шәһәр яны районнарында ике авыл

торак пункты – Биектау районының Биектау авылы (9,6 мең кеше) һәм Зеленодольск районының Осиново авылы (8,7 мең кеше).

### 1.3.4. Халык саны 100 мең кешедән артып китә торган торак пунктлар

2018 елның 1 гыйнварына Татарстанның иң зур торак пункты булып аның башкаласы – миллион кешеле Казан шәһәре тора (237942 кеше яши). 2010 елда халык исәбен алу белешмәләре буенча, Казанда руслар (48,6 процент) һәм татарлар (47,6 процент) яши, калган өлеше чуашларга, украиннарга, мариларга, башкортларга, удмуртларга һәм башка милләт вәкилләренә туры килә.

Казаннан тыш, республикада 100 меңнән артык халкы булган тагын 3 шәһәр бар – болар: Яр Чаллы (532472 кеше яши), Түбән Кама (237998 кеше яши), Әлмәт (155988 кеше яши) шәһәрләре – төбәкнең машина төзү һәм нефть эшкәртү буенча төп җитештерү комплекслары тупланган үзәкләр.

Бу шәһәрләрдән тыш, Татарстанда 50 меңнән артык халкы булган тагын 5 шәһәр һәм халкы 10 мең кешедән артык булган 19 торак пункты исәпләнә.

### 1.3.5. Халык эшли торган хуҗалык тармаклары

Татарстанстат тикшеренүе нәтиҗәләре буенча, 2018 елның гыйнвар-февралендә төбәкнең икътисад тармагында эшләүче хезмәткәрләр саны 1954,4 мең кеше яки республика халкының гомуми санының 50,2 процентын тәшкил итә. Эшләүчеләр саны буенча ИФО төбәкләре арасында Татарстан – алдынгыларның берсе.

Эшләүче кешеләрнең мәшгульлек өлкәләре буенча бүленеше турында сүз барганда, Татарстан – сәнәгать төбәге, дип ныклы ышаныч белән әйтергә мөмкин, Татарстан халкының күп өлеше җитештерү производстволарында мәшгуль, биредә татарстанлыларның 20 процентыннан артыгр252 хезмәт куя. Төбәкнең халык эшли торган иң зур икътисадый тармакларына өчесен кертергә була. Болар – Мәгариф өлкәсе, монда төбәктә яшәүчеләрнең гомуми санының 12 проценты эшли, югары белем бирү йортлары гына да 24 һәм әле тагын 43 филиал бар. Күчемсез мөлкәт белән алыш-биреш, арендалау һәм хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә халыкның 11 проценты эшли. Төзелеш темплары тотрыклы рәвештә үскән һәм торак йортлар даими рәвештә эксплуатациягә кертелгән чорда икътисад секторында эшчеләр көченә ихтыяҗ бар. Күмәртәләп-ваклап сәүдә итү; автотранспорт чараларын, мотоциклլар, көнкүреш эшләнмәләрен һәм шәхси кулланылыштагы предметларны ремонтлау өлкәләре эшләүчеләрнең гомуми санының 11 процентын эш урыннары белән тәэмин итә.

Татарстан Республикасында яшәүче эшләүчеләрнең гомуми санының 4 проценты, Татарстанстат белешмәләре буенча, авыл, урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү тармаклары өлешенә туры килә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елга ахыргы хисап белешмәләре буенча, урманчылык һәм урман әзерләү кебек эшчәнлек төрләрендә төбәктә 4,4 мең кеше эшли, әлеге өлкәдә эшләүче белгечләрнең зур булмаган мондый күләме төбәктә урманнарның күп булмавы һәм производстволарның автоматлаштырылуы белән аңлатыла.

## 1.4. Урманнар мәйданнарының административ районнар һәм җирләрнең категорияләре буенча бүленеше турында мәгълүмат

Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләргә бүленеш 43 административ район, 3 торак пункт буенча гамәлгә ашырылган, барлык административ районнарның территорияләрендә куеча төрлечә булган урманнар үсә, алар җирләрнең түбәндәге категорияләрендә урнашкан: урман фонды җирләрендә, МСТТ җирләрендә, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә, торак пунктлар җирләрендә, башка категория җирләрендә.

### 1.4.1. Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә бүленеше турында мәгълүмат

Элек-электән Татарстан Республикасында урманчылыкларның чикләрен аеру территориянең хуҗалыктан файдалану мөмкинлегенә, торак пунктларга якын урнашуына һәм урман кишәрлекләрен урман әзерләүче һәм урман эшкәртүче оешмалар тарафыннан үзләштерүнең икътисадый перспективаларына карап гамәлгә ашырылган. Шуңа күрә Татарстан Республикасы урманчылыкларының чиге барлык очракларда да диярлек муниципаль берәмлекләр чикләренә туры килми һәм урманчылыкның гомуми мәйданын үзгәртү урманнарның берничә административ районга бүленгән мәйданын үзгәртүгә китерә. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда урманчылыклар арасындагы чик, Алабуга урманчылыгында Лубян кишәрлеге урманчылыгыннан «Лубян урманчылыгы» ДКУ оештырудан тыш, үзгәрешсез калды.

2 нче таблицада урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарның административ районнар буенча бүленеше турында мәгълүмат һәм элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата нисбәте күрсәтелде.

2 нче таблица

**Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарның административ районнар буенча бүленеше һәм элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата нисбәте**

| Т/с | Административ район (Торак пункты) | 2009 елның 1 гыйнварына гомуми мәйданы, гектар | 2018 елның 1 гыйнварына гомуми мәйданы, гектар | Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата нисбәте, процент |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Әгерҗе | 45346 | 45346 | 100 |
| 2 | Азнакай | 43539 | 44900 | 103.1 |
| 3 | Аксубай | 32170 | 32398 | 100.7 |
| 4 | Актаныш | 19528 | 19897 | 101.9 |
| 5 | Алексеевск | 24782 | 24936 | 100.6 |
| 6 | Әлки | 36716 | 36695 | 99.9 |
| 7 | Әлмәт | 76527 | 77305 | 101.0 |
| 8 | Апас | 7967 | 9213 | 115.6 |
| 9 | Арча | 22920 | 23456 | 102.3 |
| 10 | Әтнә | 2616 | 2809 | 107.4 |
| 11 | Баулы | 22668 | 23373 | 103.1 |
| 12 | Балтач | 11668 | 12426 | 106.5 |
| 13 | Бөгелмә | 30117 | 30498 | 101.3 |
| 14 | Буа | 9884 | 10452 | 105.7 |
| 15 | Югары Ослан | 24879 | 24879 | 100 |
| 16 | Биектау | 31183 | 29980 | 96.1 |
| 17 | Чүпрәле | 3051 | 3051 | 100 |
| 18 | Алабуга | 11850 | 11805 | 99.6 |
| 19 | Зәй | 54468 | 54859 | 100.7 |
| 20 | Зеленодольск | 32508 | 32580 | 100.2 |
| 21 | Кайбыч | 17773 | 17773 | 100 |
| 22 | Кама Тамагы | 10921 | 10921 | 100 |
| 23 | Кукмара | 32422 | 32475 | 100.2 |
| 24 | Лаеш | 31916 | 30485 | 95.5 |
| 25 | Лениногорск | 52123 | 52024 | 99.8 |
| 26 | Мамадыш | 77279 | 77257 | 100 |
| 27 | Менделеевск | 4658 | 4658 | 100 |
| 28 | Минзәлә | 24392 | 24095 | 98.8 |
| 29 | Мөслим | 27197 | 28102 | 103.3 |
| 30 | Түбән Кама | 46175 | 46126 | 99.9 |
| 31 | Яңа Чишмә | 14429 | 14478 | 100.3 |
| 32 | Нурлат | 99211 | 99591 | 100.4 |
| 33 | Питрәч | 17003 | 17204 | 101.2 |
| 34 | Балык Бистәсе | 55084 | 55175 | 100.2 |
| 35 | Саба | 28346 | 28346 | 100 |
| 36 | Сарман | 8798 | 9139 | 103.9 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 37 | Спас | 20050 | 20083 | 100.2 |
| 38 | Тәтеш | 27143 | 14655 | 100 |
| 39 | Тукай | 14213 | 14655 | 103.1 |
| 40 | Теләче | 12999 | 13131 | 101.0 |
| 41 | Чирмешән | 36373 | 36373 | 100 |
| 42 | Чистай | 13592 | 13570 | 99.8 |
| 43 | Ютазы | 9044 | 9072 | 100.3 |
| 44 | Казан шәһәре | 885 | 3522 | 398.0 |
| Барлыгы: | | 1226413 | 1236256 | 100.8 |

2009 елның 1 гыйнварына башка категория җирләрдә 10481 гектар мәйданда урман үскән. Әлеге урманнарның иң зур өлеше төрле авыл хуҗалыгы формированиеләрендә исәпләнә, алар үзгәртеп корылган, ә администрацияләү хосусый яки башка юридик затларга тапшырылган. Элеккеге колхозларда исәпләнгән урман кишәрлекләренең бер өлеше урман фонды җирләренә кертелгән. Апас (15,6 процентка арткан), Әтнә (7,4 процентка арткан), Балтач (6,5 процентка арткан), Буа (5,7 процентка арткан) районнарында урман фонды мәйданнарының кисәк артуы шуннан килә, биредә урманнар күп түгел, әмма алга киткән авыл хуҗалыгы хисабына авыл хуҗалыгы биләмәләреннән файдаланучылар күп. Казан шәһәрендә яшәүчеләр саны арту шәһәр чикләренең артуына һәм шәһәр чикләрендәге урман фонды җирләренең, шәһәр белән турыдан-туры чиктәш Биектау (3,9 процентка) һәм Лаеш (4,5 процентка) районнарындагы урман фонды җирләре мәйданын киметү хисабына, 2637 гектарга артуына китергән.

## 1.4.2. Торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә бүленүе турында мәгълүмат

Торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманнарның гомуми мәйданы 3727 гектар тәшкил итә.

Иң зур өлешен 3547 гектар мәйданлы «Лебяжье» шәһәр урманы биләп тора. Казан шәһәре читендәге урман кишәрлеге бер үк вакытта җирле әһәмияттәге МСТТ булып тора. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата «Лебяжье» шәһәр урманының мәйданы, аерым урман кишәрлекләрен Казан шәһәре җирләренә күчерү хисабына, 96,4 процент тәшкил итә.

Буа шәһәре читендә һәм Зеленодольск шәһәре читендә урнашкан урман кишәрлекләренең мәйданнары, тиешенчә, 39 гектар һәм 141 гектар, элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата үзгәрешсез.

### 1.4.3. Оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә бүленеше турында мәгълүмат

Оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан гомуми мәйданы 1691 гектардагы урман кишәрлекләре Мари урманчылыгына карый. Мари урманчылыгының гомуми мәйданы 26455 гектар тәшкил итә. Урманчылык территориясенең 93 проценттан артык өлеше Мари Иле Республикасы чикләрендә һәм 7 проценты ТР чикләрендә урнашкан. Казан шәһәре читендә 960 гектар, Биектау районында 186 гектар, Лаеш районында 545 гектар мәйданда урманнар урнашкан. Оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан, муниципаль берәмлекләргә бүленгән урманнарның мәйданы элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата – үзгәрешсез.

### 1.4.4. Махсус сакланучы территорияләр һәм объектлар җирләрендә урнашкан урманнар мәйданының элеккеге Урман планы күрсәткечләренә мөнәсәбәтле рәвештә бүленеше турында мәгълүмат

Республика территориясендә федераль әһәмияттәге ике МСТТ бар, алар биш муниципаль берәмлектә урнашкан.

3 нче таблицада МСТТ җирләрендә урнашкан урманнарның административ районнар буенча бүленеше турында мәгълүмат һәм элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата нисбәте күрсәтелде.

3 нче таблица

МСТТ җирләрендә урнашкан урманнарның административ районнар буенча бүленеше һәм элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата нисбәте

| Т/с | Административ район | 2009 елның 1 гыйнварына гомуми мәйданы, гектар | 2018 елның 1 гыйнварына гомуми мәйданы, гектар | Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата нисбәте, процент |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Алабуга | 8999 | 9240 | 102,3 |
| 2 | Зеленодольск | 5921 | 5921 | 100 |
| 3 | Лаеш | 4170 | 4170 | 100 |
| 4 | Менделеевск | - | 20 | - |
| 5 | Тукай | 9539 | 9373 | 98,3 |
| | Барлыгы: | 28629 | 28724 | 100,3 |

МСТТ җирләре чикләрендә гомуми мәйданы 11401 гектар «Идел-Кама» ДТБТ урнашкан, шул исәптән Зеленодольск районында 5921 гектар (100 процент) һәм Лаеш районында 4170 гектар яки элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата – 100 процент. Тыюлык составына керүче 1310 гектар мәйданлы сусаклагыч акваториясен исәпкә алып, 2018 елның 1 гыйнварына тыюлыкның ДУР белешмәләренә кертелмәгән гомуми мәйданы 11401 гектар тәшкил итә, ул 2019 елның 1 гыйнварына ДУР төзелгәндә исәпкә алыначак.

«Түбән Кама» милли паркы 18633 гектар мәйдан били, ул элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата 100,5 процент тәшкил итә, шулардан Алабуга районында – 9240 гектар (102,3 процент), Тукай районында – 9373 гектар (98,3 процент) һәм Менделеевск районында – 20 гектар. 2013 елда милли парк чикләрен билгеләү эшләре барышында муниципаль берәмлекләр буенча урман кишәрлекләренең бүленеше тәгаенләштерелде һәм 18398 гектар мәйданы билгеләнде. ТР Арбитраж суды карары нигезендә милли паркның мәйданы 2015 елда – МСТТ составына «КАМАЗ» ҖЧҖнең элеккеге җирләрен кертү хисабына 188 гектарга, 2017 елда 43 гектарга арткан. Шул рәвешле «Түбән Кама» милли паркының гомуми мәйданы 2009 - 2018 елларда 95 гектарга арткан.

## 1.5. Башлангыч белешмәләр алу чыганаклары турында мәгълүмат

Чираттагы 2019 - 2028 еллар чорына Татарстан Республикасы Урман планы эшләгәндә кулланылган башлангыч белешмәләр алу чыганаклары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 2 нче кушымтада бирелде.

## 1.6. Урманнар үсә торган районнарга бүленеш

Урманнар үсә торган районнарга бүленеш – урманнарны табигый шартлары белән аерылып торган, урман хасил итүче токымнарның таралуын, урманнарның төрләрен, составын, урманнарның җитештерүчәнлеген һәм урман торгызу эшләрен билгели торган өлешләргә территориаль бүленеше. Урман үсә торган районнарга бүленеш урман хуҗалыгы җитештерүен махсуслаштыру һәм зональ-типологик нигездә аны оештыру өчен табигый нигез буларак урман үсемлекчелегенең географик төрлелеген һәм аның тереклек итү шартларын күрсәтә. Ул территорияләр бүленешенең түбәндәге өстәмә кече дәрәҗәләрен үз эченә ала: зоналар һәм районнар. Аның максаты – урманнарның һәм урман хуҗалыгының урнашуында зона үзенчәлекләрен исәпкә алу.

РФ ТРЭМның «РФ урман үсү зоналары исемлеген һәм РФ урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерыгы белән расланган урманлы районнарга бүленеш нигезендә ТР территориясе РФ Европа өлешенең урман-дала районына һәм ылыслы-

киң яфраклы зонаның РФ Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районына кертелгән. Урман районнарының визуаль чиге Идел, Кама, Шилнә елгалары буйлап уза, республиканы көнбатыштан көнчыгышка таба су ярдәмендә урман районнарына бүлә.

РФ Европа өлешендәге урман-дала районында – 821,8 мең гектар урман яки республика урманнарының гомуми мәйданының 64,6 проценты, РФ Европа өлешенең ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районында – 449,2 мең гектар урман (35,4 процент). Урман-дала районында агач материалының гомуми запасы 129708,2 мең куб.метр (61,1 процент) тәшкил итә, бу исә ылыслы-киң яфраклы урманнар районы запасын арттыра, ул 82630,9 мең куб.метр яки гомуми запастан 38,9 процентны тәшкил итә.

Республикада саклаучы урманнарның гомуми мәйданы – 605,9 мең гектар, ул төбәктәге урманнарның 47,7 процентын тәшкил итә. Саклаучы урманнарның шактый зур мәйданда булуы барлык республика буенча таралып урнашкан аерым-аерым торучы, эрозиягә каршы көрәш функцияләрен үтәүче һәм кырларны коры җилләрдән һәм дымны тиз югалтудан саклаучы урман кишәрлекләренең (кечкенә урманнар) күп санда булуы, үсеш алган автомобиль юллары челтәре, авыл җирлекләренең күпсанлы төркемнәре, шулай ук федераль дәрәҗәдәге Идел, Кама, Нократ кебек елгаларга керә торган күләмле гидрология фонды белән аңлатыла. РФ Европа өлешенең ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районында саклаучы урманнар 59,9 процент тәшкил итә, ул РФ Европа өлешенең урман-дала районындагы саклаучы урманнарның гомуми өлеше артуга китерә – төбәктәге урманнарның гомуми мәйданында – 41,0 процент. Моңа Татарстанның төньяк өлешендәге федераль әһәмияттәге ике МСТТ, шулай ук республика башкаласына якында кулланыш урманнары булмаган Шәһәр яны, Зеленодольск урманчылыкларының урнашуы сәбәпче.

Резерв урманнарына кертелгән урманнар республикада юк.

Урманлы мәйдан районнарга бүленми диярлек һәм республика буенча уртача алганда 93,6 процент тәшкил итә. Урманлы мәйданнарның иң аз өлеше «Идел-Кама» ДТБТында урнашкан (81,1 процент), чөнки тыюлык составына акватория керә, урманчылыклар арасында урманлы мәйданнарның иң аз өлеше – Әлмәт урманчылыгында (85,5 процент), бу хәл төбәктәге нефть чыгару комплексында линияле объектлар челтәренең үсеш алуына бәйле. Урманлы мәйданнарның иң зур өлеше Кама урманчылыгында (97,2 процент) урнашкан, әлеге урманчылык Кама елгасы буйлап тоташ урман биләмәләреннән тора.

Урманнарның урманлы районнар һәм урман үсү зоналары буенча бүленеше Татарстан Республикасы Урман планына 3 нче кушымтада бирелде.

## 1.7. Гамәлдәге бүленешкә анализ һәм урманнар мәйданын һәм урманнар составын максатчан билгеләнеше һәм саклаучы урман категорияләре буенча бүлү динамикасы

ТР урманнары максатчан билгеләнеше буенча саклаучы һәм эксплуатация урманнарына бүленгән. Татарстанда резерв урманнары юк. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы белешмәләре белән чагыштырганда, мәйданнарның максатчан билгеләнеш төрләре һәм саклаучы урман категорияләре буенча бүленеше, барлыкка килгән үзгәрешләр турында тулырак мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 4 нче кушымтада бирелде.

Республикадагы барлык урманнарның гомуми мәйданы 1271,0 мең гектар тәшкил итә, алар арасында саклаучы урманнар – 605,9 гектар (47,7 процент), эксплуатация урманнары өлеше 665,1 мең гектар яки төбәктәге урманнарның барлык мәйданының 52,3 процентын тәшкил итә.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы белешмәләре буенча төбәктәге барлык урманнарның мәйданы 1271,1 мең гектар тәшкил итә, 2018 ел белешмәләре белән чагыштырганда мәйданнар аермасы 0,1 мең гектар, бу түбәндәге сәбәпләр буенча килеп чыга:

1. РФ Хөкүмәте карары нигезендә автомобиль юлларын реконструкцияләү һәм нефть эшкәртү комплексы объектларын һәм нефть химиясе заводлары төзү максатларында Кама, Түбән Кама урманчылыклары составыннан 0,2 мең гектар мәйдандагы урман фонды җирләре сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләренә, оборона, куркынычсызлык җирләренә һәм башка махсус билгеләнештәге җирләргә күчерелде.

2. Чикләрне тәгаенләү нәтиҗәсендә һәм ТР Арбитраж суды карары нигезендә «Түбән Кама» милли паркының мәйданы 0,1 мең гектарга артты.

Төбәктәге саклаучы урманнарның мәйданы 23,2 мең гектарга яки урманнарның барлык мәйданында 1,9 процентка артты. Төбәктә су объектлары һәм автомобиль юллары челтәрләре киң, шуңа бәйле рәвештә, 2009 елдан башлап урманнарны тәртипкә китерү эшләрен уздырган чорда, урманнарның гомуми мәйданы 45,0 мең гектар булган бер өлеше Су саклау зоналарында урнашкан урман категориясенә кертелде һәм гомуми файдаланудагы тимер юллар, гомуми файдаланудагы федераль автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы, РФ субъектлары мөлкәтендә торучы автомобиль юллары буйлап урнашкан Саклаучы урман полосалары категориясенә кертелгән урманнарның мәйданы 19,8 мең гектарга артты. Саклаучы урманнарның әлеге категорияләрен бүлеп чыгару эксплуатация урманнарының 23,3 мең гектарга кимүенә китерде. Нәкъ шушы сәбәпле Дәвалау-савыктыру җирлекләренең һәм курортларның санитар саклау (тау-санитар) округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында урнашкан урман категорияләренә кертелгән урманнар – 0,4 мең гектар, Эрозиягә каршы урманнар – 1,9 мең гектар, Дала, ярым-дала, урман-дала, урман-

тундра зоналарында, далаларда, тауларда урнашкан урманнар – 21,2 мең гектар, Су объектлары буйлап урнашкан тыюлык урман полосалары – 5,4 мең гектар, балыкларның уылдык чәчү урыннарын саклаучы урман полосалары 14,2 мең гектар кимеде.

МСТТ урнашкан урман категориясенә кертелгән урманнарның гомуми мәйданы 29,6 мең гектар били. Урманнарның иң күп өлеше (97,0 проценты) федераль әһәмияттәге Идел-Кама ДТБТ һәм «Түбән Кама» милли паркы чикләрендә урнашкан, 3,0 проценты – урман фонды җирләрендәге төбәк әһәмиятендәге МСТТ чикләрендә.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата категорияләрнең мәйданы 1,0 мең гектарга арткан. Моңа «Түбән Кама» милли паркы мәйданы чикләрен тәгаенләштерү һәм су баса торган болыннарны кертү хисабына 0,1 мең гектарга арттыру сәбәп булып тора, бу хакта элегрәк әйтеп үтелде. Шулай ук Буа урманчылыгы урман фонды җирләре составында ТР Министрлар Кабинетының 2014 елның 22 апрелендәге 266 номерлы карары нигезендә 0,9 мең гектар мәйданлы «Маршалл тавыгы яшәү урыны» төбәк әһәмиятендәге табигать ядкәре аерып чыгарылды, урман кишәрлекләре МСТТ урнашкан урман саклык категориясенә кертелде, чөнки МСТТ оештырылганчы урман кишәрлекләре эксплуатация урманнарына карый иде.

13,8 мең гектар мәйданда фәнни яки тарихи әһәмияткә ия булган урманнар бүлеп чыгарылды, барлык урман кишәрлекләре дә урман фонды җирләрендә урнашкан, элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы белешмәләре белән чагыштырганда, категория мәйданы 0,4 мең гектарга артты. Әлеге саклык категориясенә кертелгән урманнарның артуы Зәй урманчылыгында «Борков дачасы» табигать ядкәре мәйданы чикләрен тәгаенләштерү хисабына барлыкка килде, нәтиҗәдә МСТТ 1,0 гектарга артты. Эксплуатация урманнарының бер өлеше, ТАССР Министрлар Советының 1991 елның 23 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә, Зәй урманчылыгында 9 гектар бүлеп чыгарылган «Язгы адонисны саклау буенча Өргәнче ботаник заказнигы» ДТЗ чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләре һәм, ТР Министрлар Кабинетының 1997 елның 15 сентябрендәге 698 номерлы карары нигезендә, Арча урманчылыгында 407 гектарда бүлеп чыгарылган «Аю урманы» табигать ядкәре Фәнни яки тарихи әһәмияткә ия булган урманнар категориясенә кертелде.

Торак пунктлар – Казан шәһәре («Лебяжье» шәһәр урманы), Буа шәһәре, Зеленодольск шәһәре җирләрендә урнашкан урманнар Шәһәр урманнары саклаучы категориясенә кертелде. Шәһәр урманнарының гомуми мәйданы 3,7 мең гектар тәшкил итә. 2009-2018 еллар чорында шәһәр урманнарының мәйданы Казан шәһәре Башкарма комитетының «Лебяжье» шәһәр паркы карый торган Тышкы төзекләндерү комитеты МКУ тарафыннан җирле әһәмияттәге МСТТ составыннан «Лебяжье» шәһәр урманы

урманнарының 0,2 мең гектар мәйданлы бер өлешен бүлеп чыгару хисабына кимеде.

Татарстан Республикасында Урман-парк зоналары һәм Яшел зоналар 1945-1986 елларда ТАССР Министрлар Советы карарлары нигезендә зур торак пунктлар тирәли урман фонды җирләрендә һәм оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә бүлеп чыгарылган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары нигезендә, 2010 елдан башлап, урман фонды җирләрендә урнашкан Урман-парк зоналарының һәм Яшел зоналарның чикләре һәм мәйданнары үзгәрешләргә дучар булды, тулырак мәгълүмат 4 нче таблицада бирелде. Урманнарның максатчан билгеләнеше буенча бүленеше, МСТТ урнашуы буенча 2 нче карта-схема Татарстан Республикасы Урман планына 1 нче кушымтада күрсәтелде.

4 нче таблица

Урманнарның бүленеше, Урман-парк зоналарына, Яшел зоналарга кертелгән урманнарның мәйданнарын үзгәртү динамикасы турында мәгълүмат

Мәйданы, га

| № | Урманчылык, урман паркы | 2009 елның 1 гыйнварына | | 2018 елның 1 гыйнварына | | 2009-2018 еллар чорына үзгәрешләр (+/-) | | Яшел зоналарны һәм Урман паркы зоналарын бүлеп чыгару, аларның чикләрен һәм мәйданын үзгәртү нигезләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Урман-парк зоналары | Яшел зоналар | Урман-парк зоналары | Яшел зоналар | Урман-парк зоналары | Яшел зоналар | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнар | | | | | | | | |
| 1 | Әгерҗе | 219 | 0 | 219 | 0 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |
| 2 | Азнакай | 1533 | 3191 | 1533 | 3191 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 6 август, 30 нчы карары; |
| 3 | Әлмәт | 13473 | 0 | 1347 7 | 0 | + 4 | 0 | ТР Министрлар Кабинетының 2016 ел, 26 апрель, 714-р боерыгы |
| 4 | Баулы | 1119 | 2813 | 1119 | 2813 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 26 август, 30 нчы карары; |
| 5 | Болгар | 0 | 2170 | 0 | 2170 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Бөгелмә | 4313 | 0 | 4313 | 0 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 6 август, 30 нчы карары. |
| 7 | Буа | 614 | 0 | 614 | 0 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |
| 8 | Алабуга | 3141 | 0 | 3141 | 0 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |
| 9 | Зәй | 0 | 3897 | 0 | 4165 | 0 | + 268 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары; ТР Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 гыйнвар, 165-р боерыгы; ТР Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 399-р боерыгы |
| 10 | Зеленодольск | 13061 | 1189 7 | 1278 5 | 11616 | - 276 | - 281 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 6 август, 30 нчы карары; ТР Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 апрель, 638-р боерыгы |
| 11 | Кама | 802 | 1787 | 802 | 1787 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |
| 12 | Лаеш | 0 | 2145 8 | 1431 | 21458 | +143 1 | 0 | ТР Министрлар Кабинетының 2011 ел, 18 апрель, 543-р боерыгы; ТР Министрлар Кабинетының 2016 ел, 29 март, 514-р боерыгы; ТР Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 апрель, 646-р боерыгы; |
| 13 | Лениногорск | 988 | 1740 | 988 | 1740 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 06 август, 30 нчы карары |
| 14 | Мамадыш | 325 | 0 | 325 | 0 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Минзәлә | 658 | 544 | 658 | 544 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |
| 16 | Түбән Кама | 3420 | 1055 | 3420 | 1055 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 26 август, 30 нчы карары |
| 17 | Идел буе | 5072 | 4328 | 5351 | 4610 | + 279 | + 282 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 26 август, 30 нчы карары; ТР Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 апрель, 638-р боерыгы; ТР Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 1329-р боерыгы |
| 18 | Шәһәр яны | 28730 | 0 | 2731 3 | 0 | - 1417 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1968 ел, 26 август, 30 нчы карары; ТР Министрлар Кабинетының 2011 ел, 18 апрель, 543-р боерыгы; ТР Министрлар Кабинетының 2016 ел, 29 март, 514-р боерыгы; ТР Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 апрель, 646-р боерыгы; ТР Министрлар Кабинетының 2017 ел, 3 август, 1872-р боерыгы; |
| 19 | Тәтеш | 0 | 522 | 0 | 522 | 0 | 0 | ТАССР Министрлар Советының 1960 ел, 30 апрель, 264 нче карары |
| 20 | Урман фонды җирләрендә барлыгы | 77468 | 5540 2 | 7748 9 | 55671 | + 21 | + 269 | - |
| Оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан урманнар | | | | | | | | |
| 21 | Мари | 595 | 961 | 595 | 961 | 0 | 0 | РСФСР Министрлар Советының 1960 ел, 12 март, 1294-р боерыгы |
| 22 | ТР буенча барлыгы | 7806 3 | 5636 3 | 7808 4 | 56632 | + 21 | + 269 | - |

Урманчылыкларда Урман паркы һәм Яшел зоналарның мәйданын һәм чикләрен үзгәрткәндә проект документациясе төзелде, ул ТР дәүләт хакимиятенең башкарма һәм карар чыгару органынараслауга җибәрелер алдыннан тиешле рәвештә Урман хуҗалыгы федераль агентлыгында килештерелде. Урман паркы зоналарының һәм Яшел зоналарның чикләрен үзгәртү федераль һәм төбәк инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, шулай ук җирләрне алга таба торак пунктларына кертү максатында башкарылды.

2010 - 2018 елларда Урман паркы зоналарының һәм Яшел зоналарның чикләре Әлмәт, Азнакай, Зәй, Зеленодольск, Лаеш, Түбән Кама, Шәһәр яны, Идел буе урманчылыклары үзгәртелде. Әлмәт, Лаеш, Шәһәр яны урманчылыкларында Урман паркы зоналары һәм Яшел зоналар составына керүче компенсация кишәрлекләрен сайлаганда, аларның мәйданы Урман паркы зоналары һәм Яшел зоналар составыннан чыгарыла торган кишәрлекләрнең мәйданнары артуга китерде. Шул сәбәпле Урман паркы зоналарына кертелгән урманнарның мәйданы – 21 гектарга, Яшел зоналарга кертелгәннәренең мәйданы 1 гектарга артты.

1990 елда Зәй урманчылыгы территориясендә Кама Аланы поселогы янәшәсендә төзелә торган Татарстан атом электр станциясенә техник хезмәт күрсәтү максатларында Зәй шәһәре – Кама Аланы поселогы тимер юлы төзелде. 1993 елда Зәй урман хуҗалыгында урманнарны тәртипкә китерү нәтиҗәсендә тимер юлның һәр ягы буйлап 500 метр киңлегендә гомуми мәйданы 2639 гектарлы урман полосалары, шул исәптән элегрәк Яшел зоналар категориясендә торган урманнарның бер өлеше – 268 гектар (Зәй кишәрлеге урманчылыгының 2, 8, 9, 17 квартал өлешләре) – урманнарның Тимер юллар буендагы саклагыч полосалар категориясенә кертелде. Җәмәгатьчелек фикере басымы астында Татарстан АЭС төзелеше туктатылды, тимер юл полотносы эксплуатациягә тапшырылганчы ук сүтелде.

Зәй шәһәре-Кама Аланы ш.т.п. тимер юлы булмауга бәйле рәвештә, Зәй урманчылыгының элегрәк «Тимер юллар буендагы саклагыч полосалар» буларак бүлеп чыгарылган урманнарын, шул исәптән Зәй шәһәре тирәли Яшел зоналарга кертелгән 268 гектар мәйданлы урман кишәрлекләрен, 2016 елның 20 июнендәге 1 нче киңәшмәнең беркетмәсендә әлеге урман кишәрлекләрен, урманнарның тимер юллар буендагы саклагыч полосалар бүлеп чыгарылганчыга кадәр (1985 елда урманнарны тәртипкә китерү белешмәләре буенча), саклагыч категориягә кертү турында карар кабул ителде.

Төбәктә урманлы мәйданнар 1188,6 мең гектар тәшкил итә, элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда республиканың урман үсә торган җирләре 8,2 мең гектарга яки 0,69 процентка артты, шул рәвешле ТРда урман үсә торган җирләрнең гомуми мәйданы 17,48 процент тәшкил итә.

2009-2018 елларда урман культураларының мәйданы 2,2 процентка (7,0 мең гектарга) артты, күп очракта бу тоташмаган урман культураларын

урманлы мәйданга күчерү хисабына башкарылды. Шулай ук 1,1 мең гектар һәлак булган үсентеләр мәйданының һәм агачлар киселгән урыннарның 1,9 мең гектарга артуы күзәтелә, әлеге хәлләр 2010 елгы корылыктан соң уздырылган санитария таләпләрен саклау максатларында мәҗбүри интенсив агач кисүләр белән бәйләп аңлатыла. Әрәмәлек мәйданнарын урманлы мәйданнарга кертү нәтиҗәсендә ачык һәм ташландык урыннарның мәйданы 1,3 мең гектарга кимеде.

Саклаучы (яр-сыза, кыр саклагыч) урманнар утыртканда, ябык тамыр системалы үсентеләр куллану тамырлану дәрәҗәсенең уртача нормадан югарырак булуын гарантияли, киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булганда төбәктә урманнар артачак һәм 2029 ел азагына 17,6 процент тәшкил итәр дип күздә тотыла.

Тулаем алганда, төбәктә саклагыч урманнар зур әһәмияткә ия, чөнки төбәктә агач материалы әзерләү максатларында арендага алучылар тарафыннан урманнардан файдалану киң таралыш тапмаган, ә зур автомобиль юллары челтәре, күпсанлы торак пунктлар, үсеш алган авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать төбәкнең гомуми экологик фонына зур басым ясый һәм якын киләчәктә саклаучы урманнарның мәйданнарын киметү мөмкин түгел.

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда Урман паркы зоналарының һәм Яшел зоналарның чикләрен, әлеге категория урманнарының гомуми мәйданнарын киметмичә, тагын үзгәртергә туры киләчәк, чөнки гамәлдәге законнар нигезендә Урман паркы зоналарында һәм Яшел зоналарда планлаштырылган барлык федераль һәм төбәк инвестиция программаларын гамәлгә ашыру мөмкин түгел.

## 1.8. Махсус сакланучы табигать территорияләре чикләрендә урнашкан урманнар турында мәгълүмат

МСТТ урнашкан урманнарның хокукый режимы Россия Федерациясе Урман кодексының (алга таба – РФ УК) 103 статьясы нигезендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә. МСТТ урманнарын үзләштерү биотөрлелекне, тирәлек хасил итү, су саклау, саклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм файдалы башка функцияләрне саклау максатларында, мондый файдалануны саклаучы урманнарның максатчан билгеләнеше һәм алар башкара торган файдалы функцияләр белән бергә гамәлгә ашыру мөмкинлеге шартын үтәп, бер үк вакытта урманнардан файдаланып гамәлгә ашырыла. РФ ТРЭМның 2007 ел, 16 июль, 181 нче боерыгы нигезендә «МСТТ урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яңадан торгызу үзенчәлекләре» расланды.

Төбәктә МСТТ оештыруның һәм аларның эшләвенең төп максаты флора һәм фаунаның биологик күптөрлелеген, табигый системаларны, аларның төп биологик функцияләрен төгәл итеп һәм билгеле бер территория кишәрлегендә саклаудан гыйбарәт. МСТТ комплексын оештырудан тыш,

әлеге максатка ирешү өчен Татарстан Республикасында даими рәвештә Кызыл Китап нәшер ителә. Сирәк төрләрне саклауга һәм ачыклауга юнәлдерелгән берничә экспедиция проектын гамәлгә ашыру барышында 2016 елда Татарстан Республикасының өченче Кызыл Китабы дөнья күрде һәм аңа 612 төр кертелде. Шуларның 224е – хайваннар, 340ы – үсемлек, 48е – гөмбә.

Үсемлекләрнең һәм хайваннарның сирәк төрләренең төп өлеше республиканың барлык территориясендә булдырылган МСТТ чикләрендә күзәтелә.

Татарстан Республикасында федераль әһәмияттәге МСТТ чикләрендә урнашкан урманнарга Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгының һәм «Түбән Кама» милли паркының 28724 гектар мәйдандагы урманнары кертелгән. Күрсәтелгән объектлар РФ ТРЭМ карамагында тора.

2 федераль МСТТннан тыш, республика урманнары чикләрендә төрле профильле төбәк МСТТ челтәре оештырылды. Урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан МСТТ 14136,1 гектар мәйданда – 24 дәүләт табигать тыюлыгы, 15069,08 гектар мәйданлы 30 табигать ядкаре кертелде.

Төбәк әһәмиятендәге МСТТ исемлегенә кертү өчен урман фонды җирләре составында проектлана торган урман кишәрлекләренең исәбе – 10 данә, гомуми мәйданы – 6844,8 гектар.

Шулай ук республикада 6 данә күләмендә, гомуми мәйданы 226 070 гектарлы Дәүләт аучылык тыюлыклары оештырылды, алар аучылык фаунасының тереклек итү урыннарын саклау, шулай ук кыргый хайваннарның исәбен арттыру максатларында булдырылды. Аучылык тыюлыкларына караган урман фонды җирләре чикләрендә урнашкан урманнарның мәйданы – 70 985,2 гектар, ул төбәктәге урманнарның гомуми мәйданының 5,6 процентын тәшкил итә.

Казан шәһәре чикләрендә мәйданы 3547 гектарлы «Лебяжье» шәһәр урманы урнашкан, шундагы мәйданның 3299 гектары җирле әһәмияттәге «Лебяжье» шәһәр паркы МСТТ кертелгән, ә 25 гектары төбәк әһәмиятендәге «Дубки массивы» табигать ядкаренә карый.

Идел-Кама тыюлыгы территориясе биотөрлелеге белән сыйфатлана, анда Идел аръягы урман экосистемаларының барча спектры бар – ылыслы, катнаш һәм киң яфраклы урманнар, үләнле һәм сфагнумлы сазлыклар, комлы дала фрагментлары, урман күлләренең, кече елгаларның, шулай ук хәзерге вакытта Идел һәм Кама елгаларында җайга салынган төче су экосистемалары.

Идел-Кама тыюлыгы территориясендә барлыгы лимфа тамырлы 830 үсемлек теркәлгән, мүкләр – 170, суүсемнәр – якынча 600, лишайниклар – 240, гөмбәләр – 810, имезүчеләр – 56, кошлар 230 (шул исәптән якынча 140 – оя коручы), сөйрәлүчеләр – 6, җир-су хайваннары – 10, балыклар – 40 төр.

Тыюлык ике административ районда урнашкан аерымланган ике кишәрлектән тора. Раифа кишәрлеге (Зеленодольск районы) – көньяк тайга урыны, кайбер өлешләрендә үсемлекләрнең дала төрләре аларны кысрыклап

чыгара бара. Күп төрле нарат урманнары, имәнлекләр, катнаш урманнар, юкәлекләр, каенлыклар, усаклыклар, тугайда үсә торган зирек урманнары бар. Саралы кишәрлеге (Лаеш районы) – Идел һәм Кама елгалары тоташкан урында барлыкка килә торган урында табигый урман биләмәсе, нарат һәм юкә урманнарыннан һәм зур булмаган дала үсемлекләре кишәрлекләреннән тора («Лысая гора»).

Тыюлык режимын тәэмин итү өчен тыюлык тирәли ТР Министрлар Кабинетының 1995 ел, 21 июнь, 407 нче карары нигезендә саклык зонасы оештырылган. Тыюлыкның саклык зонасы 2 км кадәр ераклыкка җәелгән, саклык зонасы чикләренең тасвирламасы Идел-Кама Дәүләт табигать тыюлыгы турында нигезләмәдә бәян ителә.

2013 елда, 20 елга беренче мәртәбә, урманнарны тәртипкә китерү эшләре кысаларында тыюлык территориясендә урманнарның сан һәм сыйфат күрсәткечләре тәгаенләштерелде, гомуми запаслар һәм токымнар буенча урманнарның бүленеше турында мәгълүмат яңартылды.

Тыюлыкның гомуми мәйданы 10,1 мең гектар тәшкил итә, шуның урманлы мәйданы 9,2 мең гектар яки Татарстан территориясенең урманлы барлык мәйданының 0,8 процентын тәшкил итә. Урманлы җирләр мәйданыннан ылыслы урманнар өлешенә – 48,4 проценты, яфраклы йомшак токымнар өлешенә 50,0 проценты туры килә. Ләкин тыюлыкта агач күләменең гомуми запасы 3089,6 мең м³ була торып, ылыслы токымнар өлешенә 1644,9 мең куб.метр (53,2 проценты) туры килә, шуның 99,2 проценты наратка туры килә. Йомшак яфраклы токымнардан агач материалы запасы буенча юкә өстенлек итә – 873,9 мең куб.метр

Яшь төркемнәре буенча мәйданнарның бүленеше түбәндәгечә: яшь агачлар мәйданның 1 процентыннан азрак өлешен били, урта яшьтәге агачлар – 16,4 процент, өлгереп килүчеләр – 14,7 процент, өлгергән һәм картайган – 68,9 процент. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы белешмәләре белән чагыштырганда (яшь агачлар – 17,9 процент, урта яшьтәге – 54,0 процент, өлгереп килүче – 9,7 процент, өлгергән һәм картайган – 18,4 процент), агачларның уртача яше кисәк үсеп китүе күзәтелә, ул хәзерге вакытта 105 ел тәшкил итә, бу исә 2013 елда урманнарны тәртипкә китерү материалларында күрсәтелгән тыюлык режимын тайпылмыйча үтәү нәтиҗәсе булып тора.

2017 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте ярдәмендә, Россия Федерациясе ТРЭМ белән берлектә, ак барс популяциясен торгызу максатларында ак барсларны үрчетү һәм үстерү буенча төбәкара үзәк оештырылырга тиешле урын билгеләнде, ул Идел-Кама тыюлыгының Саралы кишәрлеге булды, автомобиль юлларыннан һәм торак пунктлардан ерак тора, шуңа бәйле рәвештә антропоген басымга азрак дучар ителә. Планлаштырыла торган үзәкнең төп максаты яңа туган барслар өчен табигый шартлар тудырудан һәм иректә яшәү өчен кирәкле төп күнекмәләрне тәрбияләүдән гыйбарәт. Красноярск крае Хөкүмәте белән алдан килешү буенча, яшь мәчеләр билгеле бер яшенә җиткәч тереклек итүенең табигый

ареалына – Саян-Шушенск тыюлыгы территориясенә җибәреләчәк. Әлеге максатларга ирешү өчен 2018 елда Кызыл Китапка кертелгән хайванның барлык үзенчәлекләрен һәм гадәтләрен исәпкә ала торган үзәк проектын эшләү планлаштырыла.

«Түбән Кама» милли паркы Татарстан Республикасының төньяк-көнчыгышында Көнчыгыш Кама алды һәм Көнчыгыш Кама аръягы чикләрендә, Кама елгасы һәм аның кушылдыклары булган Тойма, Криуша, Танай, Шилнә үзәнлегендә урнашкан. Паркның төп максаты ТРның уникаль табигать комплексларын, флора һәм типологиясе буенча иң бай урман биләмәләрен һәм тугайлыктагы болын бергәлекләрен саклаудан һәм торгызудан һәм алардан фәнни, рекреация, мәгърифәт һәм мәдәният максатларында файдаланудан гыйбарәт.

Түбән Кама сусаклагычы ярдәмендә милли паркның территориясе мөстәкыйль аерымланган өлешләргә – Алабуга кишәрлеге урманчылыгына һәм Чаллы кишәрлеге урманчылыгына бүленә.

Милли парк территориясендә җирле табигый, тарихи-мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, дифференциацияләнгән махсус саклык режимы билгеләнгән, аның нигезендә тыюлы, махсус сакланыла торган, рекреацион, хуҗалык билгеләнешендәге тиешле функциональ зоналар бүлеп чыгарылган.

Милли парк составына кертелгән территория чикләрендә түбәндәге табигый-ландшафт комплексларын бүлеп чыгарырга мөмкин: урман биләмәләре – Кызыл Тау (Чаллы кишәрлеге урманчылыгы), Зур Наратлык, Кече наратлык, Танай урманы (Алабуга кишәрлеге урманчылыгы), тугай-болынлы – Кама елгасы тугаенең Алабуга һәм Танай өлешләре (алар тиешле торак пунктлар исеме белән аталган), кече елгаларның үзәннәре һәм торак пунктлар территорияләре.

2016-2017 елларда уздырылган урманнарны тәртипкә китерү (ревизия чоры 24 ел тәшкил итте) милли паркның биоресурслары торышы турында актуаль картинаны күрсәтә. Милли паркның территориясенең 90,3 процентында урман үсә, 16 826 гектар агач материалы запасының 3766,4 мең куб.метры туры килә, бер гектарга уртача запас күрсәткече 326 куб.метр тәшкил итә һәм агач материалы запасының гомуми күләменнән иң зур өлеше наратка туры килә – 72,4 процент. 2009 елда, үсентеләрнең уртача запасы гектарына 232 куб.метр булганда, нарат милли парктагы агач материалы күләменең 60 процентын алып тора иде, агачларның уртача яше – 78 ел, тыюлык режимын саклаган очракта милли парктагы агач материалы күләмен алга таба үстерү турында сүз алып бару мөмкин.

«Махсус сакланучы табигать территорияләре турында» 1995 ел, 14 март, 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Махсус сакланучы табигать территорияләренең аерым категорияләренең саклык зоналарын оештыру, аларның чикләрен билгеләү, мондый зоналар чикләрендә җир кишәрлекләрен һәм су объектларын саклау һәм алардан файдалану режимын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында»

2015 ел, 19 февраль, 138 нче карары нигезендә «Түбән Кама» милли паркы чикләренә тоташып торучы җир кишәрлекләрендә һәм су өслегендә МСТТ тискәре антропоген йогынтыларны бетерү өчен, шулай ук кыйммәтле культура ландшафтларын һәм табигый комплексларны, микобиотаның, үсемлекләрнең һәм хайваннарның сирәк төрләре яши торган урыннарны, милли парк чикләрендә урнашкан тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау өчен җайга салына торган хуҗалык эшчәнлеге режимы белән саклык зонасын оештыру планлаштырыла.

Милли паркның проектлана торган саклык зонасы «Түбән Кама» милли паркының табигый тышкы чикләрен юдыра торган Түбән Кама сусаклагычы акваториясе өлешләрен һәм башка милекчеләрнең җирләрен үз эченә ала. Проектлана торган саклык зонасының киңлеге милли паркның барча тышкы периметры буйлап 1000 метр тәшкил итә. Шулай ук планлаштырыла торган саклык зонасы составына милли парк эчендәге урыннар да керә: Алабуга урманчылыгы буенча – гомуми мәйданы 318879 кв.метр 50 кишәрлек, Чаллы кишәрлеге урманчылыгы буенча – гомуми мәйданы 448725 кв.метр 110 кишәрлек.

Проектлана торган саклык зонасының мәйданы районнар буенча түбәндәгечә тәшкил итә: Тукай районы – 59409494 кв.метр, шул исәптән эчке кишәрлекләр – 448725 кв.метр 110 кишәрлек; Алабуга районы – 100348360 кв.метр, шул исәптән эчке кишәрлекләр – 318879 кв.метр 50 кишәрлек; Менделеевск районы – 19847326 кв.метр; Түбән Кама районы – 10306793 кв.метр; Яр Чаллы шәһәре – 1943282 кв.метр; Алабуга шәһәре – 12264440 кв.метр; «Түбән Кама» милли паркы буенча барлыгы – 20411969 кв.метр; шулардан су фонды – 75449611 кв.метр.

«Түбән Кама» милли паркының саклык зонасы чикләрен раслау өчен проектны кызыксыну белдергән хакимият һәм җирле үзидарә органнары белән коллегиаль фикер алышулар рәвешендә килештерү процедурасы уздырыла.

МСТТ чикләрендә урнашкан урманнар турында белешмәләр Татарстан Республикасы Урман планына 5 нче кушымтада бирелде.

### 1.9. Урман планын эшләүнең методологик һәм методик үзенчәлекләре

Татарстан Республикасы Урман планын эшләүнең методологик һәм методик үзенчәлекләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 6 нчы кушымтада бирелде.

## II. Элеккеге Урман планы гамәлдә булган чорда урманнардан файдалануны оештыруга, урманнарны саклау, торгызу буенча чараларның үтәлүенә һәм урманнарның сыйфатламаларын үзгәртүгә бәяләмә

### 2.1. Урманнардан файдалану төрләре буенча урманнардан файдалануда планлаштырылган күләмнәргә ирешүне бәяләү

Урманнардан хуҗалык тармакларының төрле ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм соралган һәм зарури продуктларны алу максатларында юридик затлар һәм халык тарафыннан файдалану шулай ук урманнарны саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс керемнәренең төп чыганаклары булып тора.

Урманнардан файдалану төрләре Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында билгеләнгән, төбәктә барлык төрләр буенча диярлек теге яки бу күләмдә урманнардан файдаланыла. Татарстан Республикасы Урман планы гамәленең киләсе чорында түбәндәге төрләр буенча файдалану планлаштырыла: агач материалы әзерләү, агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру, авыл хуҗалыгы алып бару, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру, рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру, урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү, җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү, урман материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре башкару, файдалы казылма ятмаларын өйрәнү, сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү, дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясының 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка эшләр.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда урманнардан файдалануның планлаштырылган һәм фактик күләмнәре турында тулырак мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 7 нче кушымтада күрсәтелде.

Агач материалы әзерләү максатларында урманнарны арендага алучылар берничә урманчылыкта урнашкан, болар: Әгерҗе, Әлмәт, Зәй, Кызыл Йолдыз.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорга агач материалы әзерләү нәтиҗәсендә урманнардан файдалануның планлаштырылган күләме 22715,7 мең куб.метр тәшкил итте, урманнардан файдалану нәтиҗәсендә әзерләнгән агач материалының фактик күләме – 6871,2 мең куб.метр.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю, асылда яңа ел бәйрәмнәре өчен 600 мең данә күләмендә чыршы әзерләү планлаштырылган

иде, 2009 елдан башлап 2017 елга кадәр 252,9 мең төрле эш башкарылды. Агач булмаган урман ресурсларының башка төрләрен җыю һәм сату планлаштырылмады һәм башкарылмады.

Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру 15 урманчылыкта гамәлгә ашырыла, әлеге максатларда урманнардан файдалануның гомуми күләме элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле вакытында 1331520 гектар яки планлаштырылган 2809304 гектарның 47,4 процентын тәшкил итте. Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру максатларында ел саен файдаланыла торган урманнарның мәйданы арта бара һәм 2017 елда файдалану күләме элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында планлаштырылганның 59,5 процентын тәшкил итте.

Төбәктә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне үзләштерү күләме җитәрлек булмауга бәйле рәвештә авыл хуҗалыгын алып бару максатларында урманнардан файдалану күренеше таралмаган. Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалануның иң зур өлеше бары тик күпсанлы умартачылар тарафыннан умартачылык өчен генә файдаланыла. Әлеге эшчәнлек төре буенча урманнардан файдалану күләме элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда 6638,3 гектар яки планлаштырылганның 38,5 процентын тәшкил итте. 2018 елның 1 гыйнварына авыл хуҗалыгын алып бару максатларында файдаланыла торган урманнарның гомуми мәйданы 2054,4 гектар яки урман фонды җирләренең гомуми мәйданының 0,17 процентын тәшкил итә.

Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдалану 2017 ел белешмәләре буенча 4 урманчылыкта (Зеленодольск, Лаеш, Лубян, Саба) гомуми 74337,8 гектар мәйданда алып барыла, бу исә элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында планлаштырылганнан 6,2 процентка артык, әлеге файдалану төре буенча урманнардан файдалануның гомуми күләме элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда 558682,7 гектар яки планның 79,8 процентын тәшкил итте.

Лубян урманчылыгындагы урман кишәрлекләре көллият студентларына белем бирү процессын оештыру максатларында «Лубян урман-техника көллияте» ДБҺББУга даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 апрель, 580-р номерлы боерыгы нигезендә, Казан дәүләт аграр университеты студентларына белем бирү базасын оештыру, гамәли дәресләр уздыру, эш күнекмәләре алу максатларында, «Шәһәр яны урман хуҗалыгы» һәм «Саба урман хуҗалыгы» дәүләт учреждениеләре базаларында укыту-тәҗрибә хуҗалыклары оештырылды. Әлеге максатларда Министрлык күрсәтмәсе нигезендә Зеленодольск, Лаеш, Саба урманчылыклары урман кишәрлекләре даими (вакытын чикләмичә) файдалануга тапшырылды, биредә ТР УСОҮ, дендрология бакчасы, шулай ук Татарстан урман сынау станциясе

тарафыннан 1970 елларда нигез салынган агачларны эзлекле кисү буенча сынаулар уздыру өчен урман кишәрлекләре урнашкан.

Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру нигездә зур шәһәр агломерацияләренә якын урнашкан җирләрдә алып барыла (Шәһәр яны, Лаеш, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск урманчылыклары). Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда урманнардан файдалануның гомуми күләме 20092,9 гектар булган, бу исә планлаштырылганның 93,6 процентын тәшкил итә.

Урман үсемлекләренең (үрентеләрнең, чәчкеннәрнең), утырту материалының гомуми күләме 237522 мең данә планлаштырылган иде, ләкин фактик күләме 134724,9 мең данә (56,7 процент) генә тәшкил итте, әлеге күләм урман торгызу фондын агач утырту материалы белән тәэмин итү өчен җитәрлек.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү эшләре нигездә төбәкнең барлык көньяк-көнчыгыш өлешендә (Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә, Зәй, Кәләй, Лениногорск, Нурлат, Чирмешән урманчылыкларында) тизләнеш белән гамәлгә ашырыла. Бу максатларда урманнардан файдалануның гомуми күләме элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда 102073,5 гектар яки планлаштырылганның 309,2 процентын тәшкил итте, ә 2017 елда 12083,5 гектар булды, шулай ук планлаштырылган күләмнең 108,6 процентка артуына китерде.

Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, диңгез портлары һәм терминаллар, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдалану күләме 2009-2018 еллар чорында шулай ук планлаштырылган күләмнән 1516,5 процентка артып китте һәм 3760,9 гектар тәшкил итте, ә 2017 ел дәвамында артым дәрәҗәсе элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында планлаштырылганнан 316,2 процентка артты һәм 153,7 гектар тәшкил итте.

Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен 62846,5 гектар мәйданда урман файдаланылды, бу исә планлаштырылганның 42,9 процентын тәшкил итә.

Агач материалын һәм башка төрле урман ресурсларын эшкәртү эше элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда 15 гектар мәйданда планлаштырылды, ләкин әлеге чорда файдалану күләме 276,5 гектар яки планлаштырылганның 1843,3 процентын тәшкил итте.

Урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү, җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү, дини эшчәнлек башкару кебек урманнардан файдалану төрләре, РФ УК 6 статьясының 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка төрләр элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында планлаштырылмады, ләкин ул гамәлдә булган чорда гомуми файдалану күләме, тиешенчә, 255,6 гектар, 493,4 гектар, 104,2 гектар, 51083,5 гектар тәшкил итте.

Урманнардан файдалануның гомуми планлаштырыла торган күләме нисбәтен үлчәү берәмлекләре (алга таба – үлч. бер.) төрле булуга бәйле рәвештә фактик күрсәткечләр белән чагыштыру мөмкин түгел, ләкин шунысы тәгаен: бары тик эшчәнлекнең өч төре буенча гына урманнардан файдалануның фактик күләме планлаштырылганнан артып китте.

## 2.2. Урманнарны фактик үзләштерүгә һәм агач материалы алуның мөмкин булган күләменә анализ

Максатчан билгеләнеш төрләре буенча ТР урманнары эксплуатация һәм саклык урманнарына бүленгән, шуңа күрә төбәк урманнарында агач материалы әзерләү, булган чикләүләргә бәйле рәвештә, агач кисүнең мөмкин булган барлык төрләре буенча алып барыла.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда агач кисү төрләре һәм хуҗалык секцияләре буенча агач материалы алуның фактик һәм мөмкин булган күләме мәгълүматлары Татарстан Республикасы Урман планына 8 нче кушымтада бирелде.

Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында агач әзерләүнең гомуми планлаштырылган күләме 22715,7 мең куб.метр тәшкил итте, агач кисүнең барлык төрләре буенча агач материалы әзерләүнең фактик күләме, шул исәптән урман кишәрлекләрен арендага алучы затлар көче белән, 6871,2 мең куб.м яки агач әзерләүнең гомуми планлаштырылган күләменең 30,2 процентын тәшкил итте. Әзерләнгән агач материалының гомуми күләменнән, өлгергән һәм картайган агачларны кисү барышында – 1917,8 мең куб.метр (планның 13,5 проценты), урманнарны тәрбияләү максатында агач кисүдә – 2055,6 мең куб.метр (планның 33,6 проценты), зарарланган һәм һәлак булган агачларны кискәндә – 2333,0 мең куб.метр (планның 218,9 проценты), урман, урман эшкәртү инфраструктурасы һәм урман инфраструктурасы оештыруга бәйле булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә агачларны кискәндә, барлык урманчылыклар буенча 564,8 мең куб.метр (планның 43,7 проценты) әзерләнде.

Әзерләнгән агач материалының гомуми планлаштырылган күләменнән, өлгергән һәм картайган агач кисү барышында 14237,9 мең куб.метр әзерләү планлаштырылды, агач әзерләүнең фактик күләме 1917,8 мең куб.метр яки өлгергән һәм картайган агачларны кискәндә файдалану өчен исәпләнгән диләнке мәйданының 13,5 процентын тәшкил итте. Өлгергән һәм картайган агачларны кисү барышында әзерләнгән агач материалының гомуми күләменнән ылыслылар өлешенә 216,6 мең куб.метр туры килә, исәпләнгән диләнкене үзләштерү мәйданы – 33,6 процент, яфраклы каты агач материалы әзерләү күләме 46,7 мең куб.метр тәшкил итә, бу исәпләнгән диләнкенең 4,9 проценты дигән сүз, яфраклы йомшак агач материалын әзерләү күләме – 1654,5 мең куб.метр яки исәпләнгән диләнкенең 13,1 проценты. Өлгергән

һәм картайган агачларны кисү барышында әзерләнгән агач материалы күләменең иң зур күрсәткече – 210,5 мең куб.метр (Әгерҗе урманчылыгы), биредә республиканың урманнарны агач материалы әзерләү максатында файдаланучы зур биш арендаторының икесе урнашкан, шулай ук өлгергән һәм картайган агачларны кисү буенча агач материалы әзерләүнең зур Нурлат урманчылыгында – 206,5 мең куб.метр, Саба урманчылыгында – 180,2 мең куб.метр Өлгергән һәм картайган агачларны кисү буенча файдалану өчен исәпләнгән диләнкене үзләштерүнең иң зур күрсәткече Кама урманчылыгында – 51,5 процент, иң түбән күрсәткеч Бөгелмә урманчылыгында – 2,9 процент. Хуҗалык итү ягыннан аеруча кызыктыргыч булуы сәбәпле, өлгергән һәм картайган агачларны кисү буенча ылыслы хуҗалык секциясе – 33,6 процентка, яфраклы йомшак агачлар буенча – 13,1 процентка, ә яфраклы каты, урман булдыручы төп яфраклы каты токымнарга – имән һәм өрәңгегә ихтыяҗ булмау сәбәпле, 4,9 процентка үзләштерелгән.

Өлгергән һәм картайган агачларны кисү өчен файдалануга исәпләнгән диләнкене үзләштерүнең шундый түбән күрсәткечләренә, барыннан элек, берничә сәбәп бар. Аларның берсе – агач материалы әзерләү максатларында арендага алынган урман кишәрлекләренең аз санда булуы (урман фонды җирләре мәйданнарының 4 проценты), чөнки Татарстан урманнары һәркайда торак пунктлар һәм су объектлары, автомобиль трассалары буйларында аерым-аерым, барыннан элек, саклык һәм тирәлек булдыру кыйммәтенә ия булган урман кишәрлекләрендә тәкъдим ителә. Икенче сәбәп булып торак пунктларны һәм сәнәгать объектларын газлаштыру тора, ул төбәк буенча уртача 90 проценттан артып китә, бу уңайлы шартларда яшәргә мөмкинлек бирә, әмма түбән сортлы утын агачына ихтыяҗны киметә. Шулай ук «Урман хуҗалыклары» – Министрлык карамагындагы бюджет учреждениеләренең арендага алынмаган территорияләрдә өлгергән һәм картайган агачларны кисүгә законлы хокукы булмау файдалану өчен исәпләнгән диләнкене тулысынча үзләштерү мөмкинлеген бирми.

Урманнарны тәрбияви кисүләр вакытында әзерләнгән агач материалы күләме 2055,6 мең куб.метр тәшкил итте, шул исәптән ылыслы утыртмалар өлешенә 1078,1 мең куб.метр (52,4 процент) туры килә, яфраклы каты токымнар 75,0 мең куб.метр (3,6 процент) тәшкил итә, яфраклы йомшак токымнар – 902,4 мең куб.метр яки урманнарны тәрбияви кисүләр вакытында әзерләнгән агач материалының гомуми күләменең 44,0 проценты. Саба һәм Кама урманчылыкларында тәрбияви кисүләр вакытында агач материалы әзерләү күрсәткечләре 317,0 мең куб.метр һәм 185 мең куб.метр тәшкил итә, ул урманчылыклар арасында иң зур күрсәткеч булып тора.

Зарарланган һәм һәлак булган агачларны кискәндә әзерләнгән агач материалының фактик күләме, Лениногорск, Шәһәр яны, Лубян урманчылыкларыннан тыш, Татарстан Республикасының барлык урманчылыкларда диярлек элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында планлаштырылган күләмнән күп тапкырлар артып китте, бу 2010 елгы корылык һәм бозлану нәтиҗәсе булды, алардан, барыннан элек,

төбәкнең төньяк өлешендә – урман булдыручы токымнардан чыршы, көньяк-көнчыгыш өлешендә – каен һәм республиканың үзәк өлешендә имән зыян күрде. Әгәр 2010 елда санитария максатларында агач кисү вакытында агач материалы әзерләү күләме 135,9 мең куб.метр тәшкил итсә, 2012 елда, зәгыйфьләнгән агачлар массакүләм корый башлагач, әзерләнгән агач күләме 241,4 мең куб.метр тәшкил итте, үсеш 2014 елга чаклы дәвам итте, ә аннары кими башлады. Ләкин Мамадыш, Әгерже, Азнакай, Нурлат, Зәй, Бөгелмә урманчылыкларында табигать күренешләре нәтиҗәсендә зыян күргән һәм санитария-савыктыру чараларын үткәрүгә мохтаҗ булган урман кишәрлекләре бу урманчылыкларда санитар-савыктыру чараларының югары, еллык күләме турында сөйләргә җирлек бирә.

Урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын һәм урман инфраструктурасы оештыруга бәйле булмаган объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә агачларны кискәндә агач материалын әзерләү, нигездә, урманнардан башлыча җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү буенча эшләр башкару максатларында файдаланылган Әлмәт (145,1 мең куб.метр), Кәләй (101,4 мең куб.метр), Лениногорск (59,7 мең куб.метр), Чирмешән (74,0 мең куб.метр) кебек урманчылыкларда линияле объектларның саклык зоналарындагы агачларны кисү нәтиҗәсендә гамәлгә ашырылды.

## 2.3. Урманнарны саклау, урманнарны янгыннардан саклауны оештыру чаралары

Ел саен республика Хөкүмәте ТР территориясендә урманнарны янгыннардан саклау өлкәсендә эш оештыру буенча чаралар планын бастырып чыгара. 2018 елда ТР Министрлар Кабинетының үз буйсынуындагы барлык ведомстволарның урманнарда янгын куркынычсызлыгын бозу очракларын бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын пропагандалау чараларын гамәлгә ашыру өчен оештыру-техник эшчәнлеген җайга сала торган «2018 елда урманнарны янгыннардан саклау чаралары турында» 2018 ел, 27 апрель, 299 нчы карары гамәлдә. Карар нигезендә, Министрлык, ТР Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларыннан килгән зыянны бетерү буенча РФ министрлыгының ТР буенча баш идарәсе һәм ТР Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы арасында хезмәттәшлек алып барыла.

«Урман янгыннары үзәге» ДБУ базасында төзелгән диспетчерлык идарәсенең төбәк пункты, шулай ук III типтагы биш Янгын сүндерү-химия станциясе (алга таба – ЯХС), II типтагы унсигез ЯХС төбәк урманнарында янгын белән бәйле хәлне тикшереп торуны тәэмин итә.

Янгын турында хәбәр алганнан соң 3 сәгать эчендә янгын чыгу урынына килеп җитү бурычын хәл итү өчен ЯХС территорияләренең хезмәт

күрсәтү зоналарын арттыру ихтыяҗы бар. Әлеге максатлардан чыгып 2022 елда Түбән Кама һәм Нурлат урманчылыкларында II типтагы өстәмә ике ЯХС төзергә кирәк.

РФ УК 53 статьясы нигезендә, Министрлык, элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урман фонды җирләрендә урман янгыннарын кисәтүгә, аерым алганда, 34221 километр озынлыгында янгынга каршы минераллаштырылган полосалар булдыруга, 65823,1 километр озынлыгында янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистартуга һәм яңартуга юнәлдерелгән чаралар комплексын үткәрде, бу элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында күрсәтелгән күләмнәрнең 149,5 процентын һәм 98,2 процентын тәшкил итә. Бу чаралар нигездә торак пунктлар янында һәм автомобиль трассалары буйларында үткәрелде.

Урманнарны янгыннардан саклау өчен урман юлларын төзү буенча башкарылган эшләр күләме – 293,4 километр, урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын төзәтү һәм реконструкцияләү – 1901 километр, бу 125,9 процент һәм 95,1 процент тәшкил итә.

Янгыннарны кисәтү максатларында чыбык-чабык, урман түшәмәсен, коры үләнне һәм урмандагы тиз кабынучан башка материалларны яндыру 3600 гектар мәйданда башкарылды, ул планның 90,0 процентын тәшкил итә.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында урман ызаннарын чистарту, янгынга каршы өзеклекләрне карап тоту планлаштырылмады, әмма 1320 километр мәйданда эш башкарылды.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булганда урманнарны янгыннан саклау буенча уздырылган чараларның гомуми саны, шулай ук киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына планнар Татарстан Республикасы Урман планына 9 нчы кушымтада бирелде.

Әлеге бүлектә, киләсе бүлекләрдә һәм Татарстан Республикасы Урман планы кушымталарында киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына билгеләнгән барлык чаралар РФ ТРЭМның «Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә РФ субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган РФнең аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча чаралар исемлеген раслау турында» 2018 ел, 13 июнь, 257 номерлы боерыгына нигезләнеп аталды.

## 2.4. Урманнарны саклау чаралары

Татарстанда урманнарның торышына тискәре йогынты ясаучы факторларны күзәтүне, урманчылыкларның оператив хисаплары һәм урман патологиясе буенча агымдагы тикшеренү мәгълүматлары буенча, Министрлык, шулай ук урман патологиясе буенча дәүләт мониторингы һәм урман патологиясе буенча тикшеренүләр нигезендә «Рослесозащита» ФБУ филиалы – «ТР Урман саклау үзәге» гамәлгә ашыра.

Урман патологиясе буенча тикшеренүләр, урман патологиясе буенча дәүләт мониторингы мәгълүматлары һәм урманнарны үзләштерү проектлары нигезендә санитария-савыктыру чараларын планлаштыру һәм үтәү гамәлгә ашырыла.

Татарстан территориясендә агачларның зәгыйфьләнүенә һәм һәлак булуына китерүче төп факторлар булып тискәре һава шартлары йогынтысы, урман авырулары, энтомокорткычлар белән зарарлану тора.

Төп санитария-савыктыру чаралары буенча элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булганда 10349,5 гектарда эш башкарылды – агачларны чүпләрдән чистарту, ликвид булмаган агачларны җыештыру, санитария максатларында тоташтан агач кисү – 93937,4 гектар, санитария максатларында тоташтан агач кисү – 7026,9 гектар, санитария максатларында сайлап агач кисү – 51072,8 гектар. Моннан тыш, профилактика, шул исәптән биотехник чаралар, шулай ук зарарлы организмнарның чыганакларын химик һәм микробиологик алымнар белән локальләштерү һәм бетерү чаралары үткәрелде. Татарстан Республикасы Урман планы гамәленең киләсе чорына, бөҗәк ашаучы кошлар һәм башка хайваннарның тереклек һәм үрчү шартларын яхшырту максатларында, республиканың барлык урманчылыкларында профилактик чаралар үткәрү ниятләнә. Әлеге максатларда урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларында диләнкеләрне чикләү һәм кисү вакытында сакланырга тиешле буфер зоналарының зурлыгын күрсәтеп, биологик төрлелек объектлары билгеләнде.

Биологик төрлелек объектларына куышлы, зур кош оялары булган агачлар, зур кырмыска оялары керә. Әлеге объектларны саклап калу бөҗәк ашаучы кошлар һәм хайваннарның яшәү урыннарын саклау юлы белән корткычлар санын киметү мөмкинлеген бирәчәк.

Буфер зоналары чикләрен саклаудан тыш, культивацияләнә торган токымнар белән катыштыру схемасына куаклыклар кертү юлы белән, нектарлы үлән үсемлекләрен чәчү планлаштырыла, бу табигый энтомофаг функцияләрен башкарырга сәләтле бөҗәк ашаучы кошлар һәм хайваннар өчен азык базасын арттыру мөмкинлеген бирәчәк.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында урманнарны яклау буенча уздырылган чаралар буенча башкарылган эшләрнең гомуми күләме, шулай ук киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына планнарда каралган эш күләме Татарстан Республикасы Урман планына 10 нчы кушымтада бирелде.

## 2.5. Урманнарны торгызу чаралары

Төбәктә урманнарны торгызу эшләре урман утырту, катнаш урман торгызу һәм урманның табигый яңарышына булышлык күрсәтү (киселгән мәйданнарда кыйммәтле агач токымнарының тиз арада яңадан үсүен тәэмин итүче шартлар тудыру) ысулы белән үткәрелә. Татарстан Республикасы

Урман планы гамәленең киләсе чорында урманнарны торгызу ысуллары элеккечә калачак.

Урман үсү шартларына карап, Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның элеккеге чорында культивацияләнә торган токымнар сыйфатында ТРда түбәндәге агач токымнары файдаланылды: нарат – 54 процент, чыршы – 23 процент, карагай – 3 процент, имән – 5 процент, корычагач – 1 процент, каен – 9 процент, тирәк – 4 процент, юкә – 1 процент.

Урман культураларын утыртканда токымнарны катыштыру күп еллар дәвамында классик схема нигезендә башкарыла, урман кишәрлекләреннән барлык төбәк территориясендә файдаланырга мөмкин булганлыктан, утырту фәкать механик ысул белән генә башкарыла.

Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорында токымнарны катыштыруның төп схемаларыннан тыш, катыштыру схемасына туфракны күләгәләүче һәм ашлаучы, утыртылган үсентеләрнең биологик төрлелеген арттырырга сәләтле куаклар кертү күздә тотыла. Шундый куакларның берсе – сары акация (сары сәрви), 1963 елда В.С. Шумаков үткәргән тикшеренүләр нигезендә ул нарат өчен, урман түшәмәсен азот һәм көл элементлары белән баетып, ачылыгын киметеп, туфракның өске актив катламының нитратлашу һәм аммонийлашу сәләтен көчәйтеп, аның минераллар белән баюын тизләтүче булып тора. Моның нәтиҗәсе нарат үрентеләренең уртача диаметрларын арттыру, шулай ук, яфраклы йомшак агачлар, әйтик, каен белән катнашудан аермалы буларак, урман культураларының сыдырылудан зыян күрүенә юл куймау булырга тиеш.

Сары акациянең нарат үсешенә һәм сакланышына уңай йогынтысыннан тыш, куакның суты бар, бу исә бөҗәкләр санын арттырачак, һәм, нәтиҗәдә, бөҗәк ашаучы кошлар һәм хайваннарның азык базасын тулыландырачак һәм энтамофаглар санын арттыру һәм урман корткычлары саны артуны кисәтүче фактор булып торачак.

Кайбер урманчылыкларда урман булдыручы төп токым – усак. Аның үзагачы тулысынча кулланыла һәм сатыла, ә хуҗалык алып бару урманнарны карап тоту һәм торгызу чаралары ярдәмендә югары продуктлы усак үрентеләрен максатчан үстерүгә нигезләнә. Шуңа күрә төбәктә нарат, чыршы, карагай, имән, корычагач, каен, усак, тирәк, юкә хуҗалык итүдә иң кирәкле токымнар булып санала.

Үрентеләр үстерү эшләре, урман питомнигының эш проекты нигезендә урманчылыкларның «Урман хуҗалыгы» ДБУ беркетелгән даими питомникларда, шулай ук ябык тамыр системалы чәчкеннәрнең ТР УСОҮ уздырыла.

Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның элеккеге чорында үстерелгән стандарт утырту материалы (чәчкен) саны 120764,3 мең данә тәшкил итте, шул исәптән ябык тамыр системасы белән – 60 000 мең данә, ә үрентеләр – 35108,6 мең данә.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында урманнарны ясалма торгызу 16369,0 гектар мәйданда үткәрелде, бу

планлаштырылганның 75,3 процентын тәшкил итә, тик кирәкле мәйданнарга ясалма рәвештә агач утырту өчен шул да җитәрлек, чөнки өлгергән һәм картайган агачларны кисү каралган диләнкеләр мәйданы, төбәк буенча уртача алганда, 13,0 процент тәшкил итте.

Урман культураларының уңышлы ялганып китүе һәм үсеше агротехник тәрбияләүгә һәм аның үз вакытында башкарылуына бәйле. Урман культураларын агротехник тәрбияләү 147615 гектар мәйданда үткәрелде.

Үрентеләр составында хуҗалык итү өчен кыйммәтле агач токымнары өлешен арттыру максатында яшь урманнарда сирәкләү һәм чистарту эшләре урманнарны кисүдә үрентеләрнең үсеше өчен аеруча мөһим чара булып тора. Республикада әлеге чаралар ел саен кимендә 7 мең гектар мәйданда үткәрелә, ә элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында башкарылган эшләр күләме 73683,6 гектар булды, ул элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы планлаштырылган күләмнең 84,5 процентын тәшкил итә.

Өлгерү яшенә кадәрге иң яхшы агачларның үсешен көчәйтү өчен уңай шартлар тудыру максатында, элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында сайлап һәм тоташтан агач кисү 52750,3 гектар мәйданда үткәрелде, бу элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында каралган күләмнең 56,7 процентын тәшкил итә.

Урманны тәрбияләү максатларында агач кисү буенча башкарылган эшләр күләменең план күрсәткечләреннән тайпылу 2011-2017 елларда барлык урманчылыклар территорияләрендә урманнарны тәртипкә китерү эшләрен уздыруга бәйле, ул, законнарга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, 2009 елның 1 гыйнварына элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында каралган әлеге эш төрләре күләменә төзәтмәләр кертүгә йогынты ясады.

Төбәктә урманнар санын арттыру – ТР Хөкүмәте һәм Министрлык үз алдына куйган мөһим максатларның берсе. Төбәктә урманнар санын арттыру әлеге максатка ирешү омтылышының көчле булуын күрсәтә, 2009 елның 1 гыйнварына ул 17,4 процент, ә 2018 елның 1 гыйнварына 17,5 процент тәшкил итә.

2010 елда ТР УСОҮ оештыру турында карар кабул ителде, ә 2012 елда Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы һәм ТР Хөкүмәте җитәкчелеге ярдәме белән планнарны гамәлгә ашыруга ирешелде һәм Лесхоз поселогындагы Саба урманчылыгы базасында УСОҮ ачылды.

УСОҮ ябык тамыр системалы утырту материалын һәм ылыслы агач токымнарының генетик үзлекләре яхшыртылган орлыкларын җитештерү буенча заманча технологияләрдән файдаланып эш алып барыла торган, дөньякүләм дәрәҗәдәге югары технологияле, инновацияле комплекстан гыйбарәт. Корылманың гомуми мәйданы 11,3 гектар тәшкил итә, аңа гомуми мәйданы 1 гектарлы 4 теплица, 2,24 гектар мәйданда автомат күләгәләү системасы булган 8 өлгертү кыры, 1,08 гектар мәйданда автомат күләгәләү системасы булмаган 5 өлгертү кыры, шулай ук ылыслы агачлар орлыкларын максатчан чәчү буенча югары нәтиҗәле механизм керә.

Ябык тамыр системалы утырту материалының ялганып үсеп китү сәләте бик югары. Саклагыч агачлыклардан файдалану тәҗрибәсе коры һава шартларында да хәтта ябык тамыр системалы үрентеләрнең яхшы үсеп китүен күрсәтте.

Ябык тамыр системалы үрентеләр кулланып ел саен ТРның эш башкару өчен уңайсыз авыл хуҗалыгы җирләрендә 2200-2500 гектар мәйданда эрозиягә каршы саклагыч агачлар утыртыла, шул исәптән бу эш 670-700 гектар мәйданда чокыр-өем террасалары корып, текә ярларны террасалау юлы белән башкарыла. ТР буенча саклагыч агачларны һәм урман культураларын булдыруга ел саен, тулаем алганда, ябык тамыр системалы 8,2-8,5 млн. данә утырту материалы кулланыла. Утырту материалының бер өлеше ТР торак пунктлар территориясен төзекләндерүдә файдаланыла.

«Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы» ДБУ орлыкларны үз көче белән әзерли, шул ук вакытта 20 тонна күркә эшкәртә. Орлыкларның сыйфатын ТР УСОҮ каршында төзелгән орлык лабораториясе хезмәткәрләре тикшереп тора. Әзерләнгән орлыкларның сыйфатын конкрет анализлау өчен, орлыклар «Рослесозащита» ФБУ филиалының Татарстан урман-орлык станциясенә җибәрелә. Әзерләнгән орлыклардан 95 проценттан артыгы сыйфатның беренче классына туры килә.

Ябык тамыр системалы утырту материалы буенча эш тәҗрибәсен акрынлап үстереп, лаборатория хезмәткәрләрен җәлеп итеп, үсемлекләрне – агач токымнарын, декоратив куаклар һәм хәтта чәчәкләрне микроклонлау юлы белән үрчетү буенча масштаблы эш планлаштырыла. ТР урманнарында агачларның продуктивлыгын арттыру максатларында аеруча перспектив, тиз үсүче, тулы үзагачлы, авыруларга чыдам агач үсентеләрен сайлап алу һәм үрчетү ТР УСОҮ эшчәнлегендә мөһим юнәлеш булып тора.

Ябык тамыр системалы ылыслы агач токымнары чәчкеннәрен үстерү буенча ТР УСОҮ төзү инвестиция проектын гамәлгә ашыруда тупланган эш тәҗрибәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Урман планы гамәленең киләсе чорында ТРда имән чәчкеннәрен үстерү һәм имән чикләвеге саклау буенча орлыкчылык комплексы төзү планлаштырыла.

РФдә имәнлек мәйданнарын арттыру, имән үстерү, аны микроклонлау юлы белән үрчетү, кыйммәтле агач токымнарын маркировкалау технологияләрен үстерү орлыкчылык комплексын оештыруның төп максаты булып тора. Әлеге үзәк ябык тамыр системалы имән чәчкеннәрен үстерүне һәм имән чикләвегенең федераль фондын һәм РФ субъектларының иминият фондын саклау мөмкинлеген тәэмин итәчәк, халыкара фәнни хезмәттәшлекне һәм укытуны гамәлгә ашырачак, имән үстерү буенча белем һәм тәҗрибә бергә кушылган, халыкара һәм бөтенроссия җитештерү, фәнни һәм белем бирү мәйданчыгы булачак.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында урманнарны яңадан торгызу буенча уздырылган чараларның гомуми күләме, шулай ук киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына план

күләмнәре Татарстан Республикасы Урман планына 11 нче кушымтада бирелде.

## 2.6. Урман үрчетү һәм җирләрне рекультивацияләү чаралары

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына җирләрне рекультивацияләү чаралары планлаштырылмады һәм үткәрелмәде. Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына урманнан файдаланучылар тарафыннан, урманнарны үзләштерү һәм җирләрне рекультивацияләү проектлары нигезендә, аренда шартнамәләре вакыты узганнан соң, үз акчалары хисабына башкарылачак.

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорында урман үрчетү чаралары планлаштырылмады һәм үткәрелмәде. Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына урман үрчетү күләме Татарстан Республикасы Урман планына 12 нче кушымтада бирелде.

## 2.7. Урманнар мәйданының һәм агач материалы запасының урман хасил итүче төп токымнар һәм куаклыклар буенча бүленеше

Максатчан билгеләнеш төрләре буенча бүлеп, 2018 елның 1 гыйнварына төбәктәге барлык урманнар мәйданының һәм агач материалы запасының бүленеше Татарстан Республикасы Урман планына 13 нче кушымтада бирелде.

Республикада урманнар үскән җирләрнең гомуми мәйданы 1188,6 мең гектар тәшкил итә, әлеге мәйданда агач материалының гомуми запасы 212,3 млн.куб.метр, күрсәткечләр элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы мәгълүматларыннан 7,2 мең гектарга һәм 13,9 млн.куб.метрга артып китә.

ТРның урман хасил итүче төп токымнары: нарат, чыршы, имән, өрәңге, юкә, каен, усак. Карама һәм пихта еш кына катнаш урманнарда ярдәмчел токым булып тора. Карагай, корычагач һәм тирәк өстенлек иткән урманнар – утыртылган урманнар. Соры зирек, кара зирек, агач тал, куак талы нигездә дымлы, керергә читен булган урыннарда үсә, тик төп урман хасил итүче токымнар белән бергә утыртылган урманнар составында да очрый. Утыртып үстерелгән кКедр урманы «Идел-Кама» дәүләт табигать биосфера тыюлыгында (ДТБТ) очрый.

Мәйданы һәм запасы буенча, республика урманнары нигездә – яфраклы йомшак токымнардан тора, алар өлешенә урманлы территорияләрнең 706,3 мең гектары һәм 128,6 млн.куб.метр агач материалы туры килә, бу төбәктәге гомуми урман запасының 60,6 процентын тәшкил итә. Әмма ләкин Арча, Әгерҗе, Ислейтар, Зеленодольск, Шәһәр яны, Лубян урманчылыкларында, «Идел-Кама» ДТБТ, «Түбән Кама» милли паркында ылыслы токымнар, башлыча нарат, агач материалының 40 процентын һәм аннан да артыгын тәшкил итә, ә республика буенча ылыслы

урманнар үсә торган җирләрнең гомуми мәйданы – 280,6 мең гектар, агач материалының гомуми запасы – 57,5 млн.куб.метр.

Яфраклы каты токымнар республика буенча, гомумән алганда, нигездә – ярдәмче агач токымнары, ләкин Буа, Кайбыч, Идел буе һәм Тәтеш урманчылыкларында аларның гомуми составтагы өлеше 30 процентны һәм аннан артыгракны тәшкил итә. Бу урманчылыклар Идел алдында урнашкан, урман-дала туфрагы белән беррәттән, анда соры урман һәм кара туфрак типлары да очрый. Төбәктәге яфраклы каты токымнар үсә торган урманнарның гомуми мәйданы – 194,6 мең гектар, агач материалының гомуми запасы – 26,1 млн.куб.метр.

Төбәктә агачларның уртача яше 53 ел тәшкил итә, саклагыч урманнарда бу күрсәткеч – 59 ел, эксплуатация урманнарында – 48 ел.

2018 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлар буенча, ТР урманнары җирләрендә агач материалының төп ике токымы өстенлек итә. 47,9 млн.куб.метр (47856,6 мең куб.метр) агач материалы запасы булган нарат һәм агач материалының гомуми запасы 47,9 млн.куб.метр (47943,3 мең куб.метр) булган юкә.

Нарат, саклагыч урманнарга каравы сәбәпле, агач материалы әзерләүгә бәйле хуҗалык эшләре чикләнгән яки бөтенләй тыелган урманчылыкларда төп агач токымы булып тора, моны наратның уртача яшендәге аерма да – 14 ел – раслый, яклагыч урманнарда уртача яшь – 63 ел, эксплуатация урманнарында – 49 ел. Төбәктәге 17,7 мең гектар мәйданда нарат урманнары өлгергән һәм картайган агачларга кертелгән. Болар белән берлектә нарат республикада һәрвакыт ясалма урман торгызу эшләре вакытында төп агач токымы булды, шуңа күрә яшь наратлы мәйданнар – 63 мең гектар, уртача яшьтәге утыртмалар 94,4 мең гектар тәшкил итә, агач материалының запасы – 26,6 млн.куб.метр (55,5 процент).

2011 елгы урман корылышы инструкциясе расланганчыга кадәр, республиканың нигездә юкәле барлык урманнары агач материалы әзерләү тыелган махсус саклаучы урман кишәрлекләренә кертелде, ул яшь төркеме буенча агач материалы запасы бүленешендә юкә урманнарының гомуми үсешенә йогынты ясады. Өлгергән һәм картайган юкә урманнарының запасы 27,6 млн.куб.метр (57,6 процент) тәшкил итә, бу агачларның барлык токымнары төрләре арасында иң югары күрсәткеч, ә юкәнең уртача яше – 74 ел һәм урманнарның максатчан билгеләнешенә бәйле рәвештә кискен аерылып тормый.

Каен һәм усак өстенлек иткән урманнар республиканың барлык районнарында очрый һәм 210,4 мең гектар һәм 238,8 мең гектар тәшкил итә, каенның агач материалы запасының гомуми күләме – 35,3 млн.куб.метр, усакныкы – 41,6 млн.куб.метр. Токымнар киселгән урыннарда һәм урман үсмәгән башка мәйданнарда ясалма рәвештә тыкшынудан тыш та яхшы яңара, бер төр агачлардан торган урманнар буларак та, төбәктә очрый торган барлык токымнар белән бергә катнаш урманнарда да үсә ала.

Яфраклы каты урманнарның гомуми мәйданында имән һәм өрәңге урманнарының гомуми агач запасы 25,8 млн.куб.метр күләмендә 191,0 мең гектар (98,2 процент) мәйдан били. Әлеге токымнарның барлык агач материалы диярлек түбән товарлыклы һәм аңа утын рәвешендә генә ихтыяҗ бар. 1978-79 еллардагы салкыннар, Татарстанның кайбер районнарында һава температурасы минус 50°С кадәр төшү нәтиҗәсендә, яфраклы каты токымнар суыктан ярылып, аеруча нык зыян күргән. Имәннең уртача яше – 62, өрәңгенеке 35 ел булуын, шулай ук төбәк торак пунктларын газлаштыруның артуын исәпкә алып, төп урман хасил итүче токымнарның катнашу өлешендә яфраклы каты токымнар күләме арта барачак.

Чыршылар өстенлек иткән урманнар нигездә ясалма үстерелгән һәм башлыча төбәкнең төньяк өлешендә, РФ Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районында 72,5 мең гектар мәйданда үсә. Әгәр якындагы елларда 2010 елгы корылыкка тиңдәш табигать аномалияләре булмаса, төбәктәге урманнар составында чыршының өлеше артачак.

## 2.8. Урманнар мәйданының агач токымы төркемнәре һәм яшь төркемнәре буенча бүленеш динамикасы

Оборона һәм куркынычсызлык зоналарында урнашкан урманнардан тыш, урманнар мәйданының урман хасил итүче төп токымнар буенча агач токымнары һәм яшь төркемнәре буенча бүленеше Татарстан Республикасы Урман планына 14 нче кушымтада бирелде.

Төбәкнең урман хасил итүче төп токым урманнары (оборона һәм куркынычсызлык зоналарында урнашкан урманнардан тыш) гомуми мәйданы 2018 елның 1 гыйнварына 1180,1 мең гектар тәшкил итә, агач материалының гомуми запасы – 211987 мең куб.метр. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында шул ук күрсәткечләр, тиешенчә: 1179,7 мең гектар һәм 197244 мең куб.метр, урманнарда агачлар ешаю һәм агач материалының артуы барлык урманчылыкларда диярлек күзәтелә.

Әмма Әлмәт, Кәләй, Нурлат урманчылыкларында тискәре тенденцияләр күзәтелә, әйтик Чирмешән урманчылыгында урманнар үскән җирләрнең мәйданы – 0,6 мең гектарга, ә агач материалының күләме 168,9 мең куб.метрга кимегән. 2010 ел ахырында Татарстанның көньягында бозлы яңгыр явып узды, ул агачларга 3 сантиметрга кадәр калынлыктагы боз катуга китерде. Төбәкнең көньяк өлешендәге урманчылыкларда төп урман хасил итүче токым аеруча зыян күрде – 2010 елгы корылыктан һәм бозлы яңгырдан соң табигый рәвештә торгызу мөмкин булмаган каен урманнары корый башлады, бу барлык өч урманчылыкта диярлек зыян күргән һәм һәлак булган агачларны кискәндә әзерләнгән агач материалының гомуми күләме элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында планлаштырганнан артып китте (Татарстан Республикасы Урман планына 8 нче кушымта).

Барлык хуҗалык секцияләрендә яшь төркемнәре буенча мәйданнарның бүленеше түбәндәгечә: яшь үсентеләр өлешенә мәйданнарның – 19,5

проценты, урта яшьтәге агачлар өлешенә – 35,3 проценты, өлгереп килүче агачлар өлешенә – 15,7 проценты, өлгергән агачлар өлешенә – 23,2 проценты, картайган агачлар өлешенә 6,3 проценты туры килә. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы мәгълүматларына нигезләнеп, яшь төркеме буенча мәйданнарның бүленеше түбәндәгечә: яшь үсентеләр – 26,3 процент, урта яшьтәгеләр – 35,5 процент, өлгереп килүчеләр – 15,5 процент, өлгергәннәр – 19,5 процент, картайганнар – 3,2 процент.

Республика буенча, гомумән алганда, үсентеләрнең уртача яше акрынлап арту (бу шулай ук Татарстан Республикасы Урман планына 15 нче кушымтада билгеләп үтелде) һәм файдалану өчен билгеләнгән диләнкедән тулысынча өлгермәгән һәм картаймаган агачларны кисүгә исәпләнгән диләнкене (Татарстан Республикасы Урман планына 8 нче кушымта) фактик үзләштерү хисабына, өлгергән һәм картайган агач материалларының үсеше күзәтелә.

Барлык төр токымнарда яшь үсентеләрнең гомуми мәйданы һәм запасы кимүе, ә өлгергән һәм картайган агачларда бу күрсәткечләрнең артуы күзәтелә. Яфраклы йомшак урманнарда өлгергән һәм картайган агачлар төркеменә караучы урманнарның мәйданы 63,4 мең гектарга артты, агач материалының гомуми күләме – 17263,4 мең куб.метр, яфраклы йомшак яшь үсентеләр мәйданы 28,7 мең гектарга кимеде, ә агач материалының күләме кимү 1059,8 мең куб.метр тәшкил итте. Яфраклы каты һәм ылыслы агачларда охшаш хәл күзәтелә, әмма аерма – азрак.

2018 елның 1 гыйнварына агач токымнары төркемнәре буенча мәйданнар бүленеше түбәндәгечә: ылыслылар – 27,1 процент, яфраклы каты токымнар – 12,3 процент, яфраклы йомшак токымнар – 60,6 процент. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы мәгълүматлары буенча, агач токымнары төркеме буенча мәйданнарның бүленеше түбәндәгечә: ылыслылар – 27,3 процент, яфраклы каты токымнар – 11,6 процент, яфраклы йомшак токымнар – 61,1 процент. Ылыслы урманнар гомуми мәйданының кимүе, барыннан элек, 2010 елгы корылык нәтиҗәсендә республиканың төньяк өлешендә чыршы урманнарының коруына бәйле. Яфраклы каты токымнар табигый картайган юкә урманнарының өрәңге урманнары белән өлешчә алмашынуы хисабына мәйданнарын арттырды, ләкин өрәңге агач материалы сатылмау төбәкнең урман кишәрлекләрендә урта таксация күрсәткечләрендә токым күләменең алга таба арту тенденциясе турында сөйләргә мөмкинлек бирә.

### 2.9. Урманнар мәйданының яшь төркемнәре кисемендә тыгызлыгы, бонитет классы буенча үзгәрүе

2018 елның 1 гыйнварына төп урман хасил итүче токымнар буенча урманнар үскән җирләрнең гомуми мәйданы – 1181,5 мең гектар, бу элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы күрсәткечләренә карата 100,7 процент тәшкил итә. Әлеге мәйданнан ылыслы урман хасил итүче токымнарга – 23,8

процент, яфраклы каты токымнарга 16,4 процент туры килә, яфраклы йомшак токымнар өлеше мәйданның 59,8 процентын тәшкил итә. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы мәгълүматлары буенча төп урман хасил итүче токымнарда урман үсә торган мәйданнар нисбәте түбәндәгечә булды: ылыслылар – 24,5 процент, яфраклы каты токымнар – 16,4 процент, яфраклы йомшак токымнар – 59,1 процент.

Үзгәрешләр динамикасы 2010 елгы корылык нәтиҗәсендә чыршылар, пихталар кору сәбәпле, ылыслы токымнар кимү хисабына яфраклы йомшак токымнарның гомуми мәйданы артуны күрсәтә, бу мәйданда шытымлы токымнар – каен, усак өстенлек алуына китерде.

Уртача яше арту белән бергә, урманнарның тыгызлыгы (тулылык коэффициенты) кими, 2009-2018 еллар чорында ылыслы хуҗалыклар буенча тыгызлыгы 0,8 - 1,0 тәшкил иткән урманнар мәйданы 11,4 процентка кимеде, яфраклы каты токымнар – 2,8 процентка, яфраклы йомшак токымнар – 34,1 процентка, үз чиратында тыгызлыгы 0,3 - 0,5 тәшкил иткән урманнарның мәйданы уртача 4,5 процентка артты.

2018 елның 1 гыйнварына төбәкнең ылыслы хуҗалыкларында бонитетның уртача классы – IIгә тигез һәм аннан да югары, мондый урманнарның мәйданы 258,5 мең гектар яки нарат өстенлек итү хисабына ылыслы урманнар гомуми мәйданының 98,6 процентын тәшкил итә. Яфраклы йомшак токымнар үстерүче хуҗалыкта да II һәм югарырак бонитетлы үсентеләр өстенлек итә, аларның гомуми мәйданы – 561,4 мең гектар яки, каен өстенлек итүче агачлар хисабына, яфраклы йомшак төп урман хасил итүче токымнар үсә торган мәйданның 80,6 процентын тәшкил итә. Яфраклы каты токымнардан иң зур мәйданны имән өстенлек итүче кишәрлекләр били, анда уртача бонитет IIIкә тигез, мондый кишәрлекләр өлеше 48,0 процент тәшкил итә. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы мәгълүматлары белән чагыштырганда, бонитетлар буенча мәйданнар бүленештә кискен тирбәлешләре күзәтелми.

## 2.10. Утыртылган урманнарның таксация сыйфатламалары үзгәрү

Оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан урманнардан тыш, 2009 елның 1 гыйнварына һәм 2018 елның 1 гыйнварына уртача таксация күрсәткечләре мәгълүматлары Татарстан Республикасы Урман планына 15 нче кушымтада китерелде.

2018 елның 1 гыйнварына урманнар үскән җирләрнең мәйданы, оборона һәм куркынычсызлык җирләрендә урнашкан урманнардан тыш, 1187,2 мең гектар тәшкил итә, бу элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы мәгълүматларына карата 100,7 процент тәшкил итә. Урманнар үскән җирләрнең мәйданнары арту турыдан-туры билгеләнеше буенча кулланылмаган авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар каплауга, урман үскән мәйданга урман культураларын вакытында күчерергә мөмкинлек бирүче стандарт параметрдагы чәчкеннәр һәм үсентеләр куллануга бәйле.

Башка категорияләрдәге урман белән капланган җирләр мәйданының кардиналь үзгәрүе гомуми мәйданы 10481 гектар урман кишәрлекләрен урман фонды җирләренә кертүгә бәйле.

Агачларның уртача яше 53 ел тәшкил итә, 2009 ел мәгълүматлары буенча бу күрсәткеч 49 ел иде. Урманнар үскән мәйданнарның уртача запасы гектарына 187 куб.метр тәшкил итә, ә өлгергән һәм картайган агачларда – гектарына 228 куб.метр, 2009 елда бу күрсәткечләр гектарына тиешенчә 172 һәм 214 куб.метр булган. Агач материалының уртача яше һәм уртача күләме арту өлгергән һәм картайган агачларны кисү өчен билгеләнгән диләнкеләрне файдаланмау турында сөйли, әлеге күрсәткечләр Татарстан Республикасы Урман планына 8 нче кушымтада китерелде.

Бонитетның уртача классы I,6, уртача чагыштырмача тыгызлык – 0,67 тәшкил итә, запас буенча урта үсеш – гектарына 3,5 куб.метр. Татарстан Республикасы буенча әлеге күрсәткечләр элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы мәгълүматлары белән чагыштырганда нык үзгәрешләргә дучар булмады.

Урманнарның уртача таксация составы түбәндәгечә билгеләнде: 2Б 2Ос 2Лп 2С 1Д 1Кл. 10 ел элек булган мәгълүматлар белән чагыштырганда, составтан агачларның гомуми массасының 5 процентын тәшкил иткән Чыршы чыгарылды, моңа 2010 елгы корылыктан соң республиканың чыршы урманнары оя-оя булган төньяк өлешендә (Саба, Мамадыш, Алабуга, Әгерҗе урманчылыкларында) – Россия Федерациясе Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы (катнаш) урманнар районының көньяк чигендә массакүләм кору сәбәп булды, чөнки нәкъ менә монда чыршы таралу ареалының көньяк чиге уза, шуңа күрә токым температура үзгәрешләренә аеруча бирешүчән. 2009 ел мәгълүматлары белән чагыштырганда, урманнарның уртача составына бер берәмлек юкә урынына өрәңге кертелде. Төбәктә составында төрле санда өрәңге үскән урманнар һәркайда бар. Нигездә, өрәңге имән һәм юкә урманнарында өстәмә токым булып тора. Әмма башка токымнардан аермалы буларак, өрәңгенең товар буларак кызыксындырмый диярлек, ә каен, усак запаслары утынга булган ихтыяҗны тулысынча канәгатьләндерә. Шул рәвешчә, гомуми урта составта өрәңге күләме алдагы елларда артачак кына.

## 2.11. Урманнарның зәгыйфьләнү, начарлану һәм һәлак булу сәбәпләре

Төрле табигый һәм антропоген факторлар йогынтысында урманнарның коруын, зәгыйфьләнүен һәм һәлак булуын мониторинглау республикада ел саен ТР Урманны саклау үзәге белән берлектә Министрлык тарафыннан җир өстендәге һәм дистанцион алымнар белән үткәрелә. Эшләр башкару максаты булып алга таба урман саклау һәм башка урман хуҗалыгы чараларын планлаштыру өчен, урманнар торышын даими тикшереп тору, үсентеләрнең патологик үзгәрешләрен ачыклау тора. 2009-2018 елларга хисап материаллары нигезендә (2018 ел мәгълүматлары беренче квартал өчен

бирелде) урманнарның зәгыйфьләнүе, начараюы һәм һәлак булуы сәбәпләре турында төп мәгълүматлар бар.

Коруына урман янгыннары сәбәпче булган урманнар ачыкланмады. ТР Урман янгыннары үзәгенең тотрыклы эше, кирәкле җиһазлар һәм техника белән тәэмин ителгән ЯХС челтәре төбәктә урман янгыннарына бәйле вазгыятьне махсус контрольдә тоту мөмкинлеген бирәчәк.

Һава торышы һәм туфрак-климат факторлары аркасында 16824,8 гектар мәйданда урманнарның зәгыйфьләнүе билгеләп үтелә, моның төп сәбәпләре – корылык һәм аннан соң җил аударган утыртмалар. Шунысын әйтергә кирәк, 2009 елда әлеге сәбәп нибары 2,0 процент очракта гына урманнарның коруына сәбәпче булды, 2010 елда – 1,9 процент. 2010 елгы аномаль корылык нәтиҗәләре 2011 елдан башлап ачык күренә башлады, урманнарның коруы берничә ел дәвамында күзәтелә һәм ел саен 35 процент очракта урманнарның зәгыйфьләнүенә сәбәпче була. Моннан тыш, 24,7 процент очракта һава торышы шартлары төбәктә урманнар һәлакәтенең иң киң таралган сәбәпчесе булып тора. Хисап чорында һава торышы һәм туфрак-климат факторлары аркасында һәлак булган урманнарның гомуми мәйданы 280,4 гектар тәшкил итә.

Урман авырулары һава шартларына турыдан-туры бәйләнгән, агачлар һава торышында кискен үзгәрешләр нәтиҗәсендә зәгыйфьләнә. Ялган трутовик һәм тамыр губкасы төбәктә үсентеләргә зыян сала торган төп авырулар булып тора. Республикада авырулар йогынтысында урманнарның төрле дәрәҗәдә кору мәйданы 20276,8 гектар, бу элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорында зыян күргән гомуми мәйданнарның 51,6 процентын тәшкил итә һәм төбәктә үсентеләр коруга төп сәбәпче булып тора, моннан тыш авырулар 2009 елдан башлап 3631,1 гектар мәйданда яки элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында мәйданнарның 39,6 процентында агачлар һәлакәтенә сәбәпче булды.

Һава шартлары һәм урман авырулары йогынтысында 1388,2 гектар мәйданда бөҗәкләр зыян салды. Төп корткыч – 2010 елгы корылыкка дучар булган чыршы урманнарына зыян салучы кабыгашар-типограф.

Һава шартлары, корткычлар һәм урман авырулары Лениногорск, Шәһәр яны һәм Лубян урманчылыкларыннан тыш, барлык башка урманчылыкларда зарар күргән һәм һәлак булган агачларны кисү күләмнәре артуга китерде. Ликвид агач материалы элеккеге Татарстан Республикасы Урман планында планлаштырылган күләмнән 1267,4 мең куб.метрга (118 процентка) артты (Татарстан Республикасы Урман планына 8 нче кушымта).

Татарстанда агачларны зарарлаучы кыргый җәнлек-җанварлар – пошилар, кабаннар һәм кондызлар.

Хайваннар урманнарның зәгыйфьләнү яки кору сәбәпчесе була, кыргый җәнлек-җанварлар зарарлаганнан соң 1,2 гектар мәйданда агачларның һәлак булу фактлары ачыкланды. Арча, Азнакай, Әгерҗе, Зәй, Мамадыш, Минзәлә, Тәтеш урманчылыкларында җәнлек-җанварлар

санының аеруча артуы күзәтелә. Кондызлар кече һәм урта диаметрлы арзанлы агач токымнарын кимерә, кондызларның төп азыгы – тал, зирек, усак. Кабан дуңгызларының җир казуы урман культураларының тамыры ялганып үсеп китүенә тискәре йогынты ясый һәм еш кына үсентеләрнең һәлак булуына китерә.

Су объектлары тирәсендәге кондызлардан һәм имән чикләвегенә өстенлек бирүче кабан дуңгызларыннан тыш, төбәктә поши урманнарның төп дошманы булып тора. Ул урман торгызу эшләрендә кулланыла торган төп токымнарга – наратка, аерым очракларда чыршыга, имәнгә шактый зыян сала, яшь агачларның очларын зарарлый, ә бу исә авырулар артуга китерә һәм продуктивлык дәрәҗәсен киметә. Моннан тыш, усак кайрысы белән тукланып, яшь агачларның гына түгел, урта яшьтәге агачларның да авыру йоктыруына сәбәпче була, бу шулай ук агач материалы ликвидлылык дәрәҗәсенең түбәнәюенә китерә.

ТР Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан ел саен кыргый хайваннарны исәпкә алу уздырыла һәм киләсе ау чорына аулауга, шул исәптән пошиларга да, административ районнар буенча квоталар бирелә. 2018 елда маршрутлап исәпкә алу белешмәләре буенча, Татарстанда 8416 баш поши исәпләнә, бу 2017 ел белән чагыштырганда 107 башка һәм 2009 ел белән чагыштырганда 2816 башка күбрәк. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәленең ун еллык чорында пошилар саны 50,3 процентка артуы күзәтелә. Үз чиратында 2018 елның 1 августыннан 2019 елның 1 августына кадәр ТР Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан 485 баш поши ату рөхсәт ителгән.

Шул рәвешле төбәктә 1000 гектар урманга пошилар саны 6,6 баш тәшкил итә һәм җәнлек-җанварлар саны елына уртача 5 процентка арта, бу тояклы хайваннарны атуның еллык күләме кимүен күрсәтә. Төбәктә 1000 гектарга пошиларның оптималь баш санын 2-3 исәбендә калдыру өчен киләсе 5 елда ел саен кимендә 1000 пошины атарга кирәк, бу урман культуралары зарарлануның кимүенә китерәчәк.

Алдагы Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында хайваннар тарафыннан зыян китерелгән төбәк урманнарының гомуми мәйданы 399,7 гектар яки зыян салынган урманнарның гомуми мәйданының 1,0 процентын тәшкил итә.

Урманнарга антропоген йогынты кешенең яшәеш эшчәнлегенең тәэсир итә торган теләсә кайсы төреннән гыйбарәт. Төбәктә антропоген йогынты локаль, төбәк һәм хәтта федераль характерда – республика буенча берничә федераль автомобиль трассасы уза. Төбәк сәнәгый яктан үскән булуы сәбәпле, Казан, Чаллы, Түбән Кама сәнәгать узеллары да шактый йогынты ясый, аларда сәнәгать предприятиеләренең төп массасы тупланган. Урман хуҗалыгы һәм авыл хуҗалыгы эшчәнлеге вакытында урманнарның яки аерым торучы агачларның зарарлануы шулай ук урманнарның зәгыйфьләнүенең яки коруының антропоген сәбәпчеләре булып тора.

Әмма әйтергә кирәк, антропоген факторлар өлешенә зарарланган утыртмалар мәйданнарының нибары 0,5 проценты туры килә (918,1 гектар) һәм бары 0,2 процент очракта гына урманнарның һәлак булуына сәбәпче була. Ләкин шунысын билгеләп узарга кирәк, зарарланган утыртмалар мәйданының (37,1 гектар) нибары 0,1 проценты гына антропоген факторлар өлешенә туры килә. Хуҗалык буенча файдаланылышы чикләнгән саклагыч урманнарның зур өлеше, урман хуҗалыгын алып бару культурасын саклау – урманга антропоген йогынтыны киләсе ун елда арттырмаска мөмкинлек бирүче факторлар.

Республика урманнарының санитар торышына тискәре йогынты ясаган патоген булмаган факторлар 304,8 гектар мәйданда теркәлде, шул исәптән төр эчендәге көчлерәк агачларның көчсезрәкләрен зәгыйфьләндерүе аркасында – 126,1, төрләр арасындагы көчлерәк агачларның көчсезрәкләрен зәгыйфьләндерүе аркасында – 178,7 гектар. Патоген булмаган факторлар агачларга сизелерлек йогынты ясамый, кору дәрәҗәсенә карап, нигездә, урманнар мәйданының күп дигәндә 10 процентында күзәтелә, агачларның 96,5 проценты әлеге факторлардан зыян күргән. Татарстан Республикасында патоген булмаган факторлардан урманнарның һәлак булуы теркәлмәде. 2019 елда һәм аннан соңгы елларда урманнарның патоген булмаган факторлардан начараю ихтималы юк.

Урманнарның зәгыйфьләнү, начараю мәйданнары һәм һәлак булу сәбәпләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 16 нчы кушымтада бирелде.

## III. Урман ресурсларын һәм урманнарның тирәлек булдыру, су саклау, саклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы функцияләрен, урман продукциясе базарларын һәм урманнарны үзләштерүнең киләчәген бәяләү

### 3.1. Урман ресурсларын бәяләү һәм алардан халыкның үз ихтыяҗлары өчен файдалану мөмкинлеге турында, шулай ук Россия Федерациясенең аз санлы төп халыклары тарафыннан урманнардан файдалану турында мәгълүмат

Татарстан Республикасында халыкның үз ихтыяҗлары өчен урман ресурсларыннан файдалану нормативлары «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 ел, 22 май, 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасында халык үз ихтыяҗлары өчен урман ресурсларыннан агач материалы әзерләү максатларында файдалана.

Гражданнар кирәк очракта үз ихтыяҗлары өчен түбәндәгеләрне әзерли ала:

1. 25 елга бер тапкыр йорт һәм каралты-кура төзелеше өчен 100 куб.м кадәр агач материалын;
2. 10 елга бер тапкыр йорт һәм каралты-кура ремонты өчен 50 куб.метр кадәр агач материалын;
3. Елына бер тапкыр корылмаларны җылыту өчен хуҗалыкка 20 куб.метр кадәр агач материалын;
4. 10 елга бер тапкыр авыл хуҗалыгы эшчәнлеген алып бару өчен түләүсез файдалануга тапшырылган урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар төзү һәм төзәтү өчен 20 куб.метр кадәр агач материалын.

Халыкның үз ихтыяҗлары өчен агач материалын әзерләү максатларында республиканың барлык урманчылыкларда төрле интенсивлык белән кисүнең өлгергән һәм картайган агачларны, шулай ук зарарланган һәм һәлак булган агачларны кисү кебек төре башкарыла.

Халыкның үз ихтыяҗларыннан чыгып, агач материалы әзерләү максатларында файдалануы өчен агач материалының ихтимал күләме фактик күләмнәрдән күп тапкырлар артып китә. Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында халыкның үз ихтыяҗлары өчен агач материалы әзерләүнең гомуми күләме 19614,6 гектар гомуми мәйданда 1450,0 мең куб.метр тәшкил итте, агач материалының гомуми бәясе 44311,7 мең сум булды.

Халык үз ихтыяҗлары өчен агач материалын аеруча зур күләмдә Кама урманчылыгында әзерләгән – 170,1 мең куб.метр, Биләр урманчылыгында – 121,3 мең куб.метр, Нурлат урманчылыгында – 121,2 мең куб.метр, әлеге урманчылыкларда эксплуатация урманнарына караган тоташ урман биләмәләре өстенлек итә.

Төбәк территориясен газлаштыру колачының даими үсешен, торак йортларны кирпечтән төзүгә күчү тенденциясен, 22-ТРЗ номерлы ТР законында күрсәтелгән урман ресурсларыннан берничә тапкыр файдалану мөмкинлеген исәпкә алып, халыкның агач материалын әзерләү максатларында үз ихтыяҗлары өчен агач материалын куллану күләме киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында, элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чор мәгълүматлары белән чагыштырганда, кимиячәк һәм ел саен 70 мең куб.метрдан артмаячак.

Моннан тыш, «Шәхси ихтыяҗлар өчен агачларны сату-алу шартнамәләре буенча гражданнарга түләү ставкаларын билгеләү турында» 2017 ел, 27 февраль, 9-1/нпс номерлы Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары белән агачларның аерым токымнары буенча бәясе биш тапкыр арттырылган яңа ставкалар билгеләнде, бу шулай ук өлгергән һәм картайган агачларны кисү күләмнәре кимүнең гомуми тенденциясе кимүгә китерә, әмма сату-алу шартнамәләре буенча агач материалы сатудан керемнәр кимүенә китерми.

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында халыкның үз ихтыяҗлары өчен урман ресурсларыннан файдалануы агач материалын әзерләү максатыннан тыш планлаштырылмый.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең төп аз санлы халыкларының бердәм исемлеге турында» 2000 ел, 24 март, 255 нче карарында расланганнар исәбендә Татарстан Республикасында төп аз санлы халыклар яшәми һәм алар урманнардан файдаланмый.

### 3.2. Инвестиция проектлары турында мәгълүмат

Төбәк икътисадына этәргеч бирү, чит ил капиталын җәлеп итү, эш урыннары булдыру, шулай ук инвестиция программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә 2007 елның 20 ноябрендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы («Алабуга» СҖТ МИЗ) ачылды. МИЗ территорияләре компания-резидентларның җитештерү процессын гамәлгә ашыру мәйданчыгы булып тора, алар өчен кирәкле инфраструктура оештырыла, шулай ук салым ташламалары бар.

Нәкъ менә шушы мәйданчыкта 2010 елның 18 августында «Hayat Holding» компанияләре төркеменә керүче «Kastamonu Entegre» төрек җитештерүчесенең ярдәмче компаниясе «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ резидент статусын алды, ул МДФ, йомычкадан эшкәртелмәгән плитәләр, ламинацияләнгән паркет, фанералар, җиһазлар һәм ишек панельләре җитештерә. Заводның беренче чираты 2014 елның 29 сентябрендә, икенче чираты 2016 елның 24 июнендә ачылды.

Завод сатып ала торган агач материалының тулаем күләме 1,3 млн $м^3$ агач материалы тәшкил итә. Агач материалы җитештерү өчен ылыслы, яфраклы токым чимал булып хезмәт итә, география ягыннан уңайлы

урнашуы аркасында чимал Татарстан Республикасыннан, Киров өлкәсеннән, Удмуртиядән, Пермь краеннан китертелә. Министрлыкның ведомство карамагындагы урман хуҗалыклары тарафыннан ел саен 522,0 мең куб.метр күләмендә агач материалы китертү планы үтәлә.

Урман ресурсларын эшкәртү сәнгатенең чималга ихтыяҗы һәм тәэмин ителеше турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 17 нче кушымтада китерелде. Җитештерелә торган продукция күләмнәре һәм кулланыла торган урман ресурсларының күләмнәре, шул исәптән башка төбәкләрдән агач материалы импортын исәпкә алып, күрсәтелде.

### 3.3. Агач материалын һәм башка урман продукциясен сату базарлары

Татарстан Республикасы Урман планы эшләнгән ел алдыннан килә торган елда һәм эшләнә торган Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорында сату базары һәм башка урман продукциясе турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 18 нче кушымтада бирелде.

### 3.4. Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм аларны җыю, азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю, чәер әзерләү өчен файдалану

Татарстан Республикасында элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда урманнардан азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю, чәер әзерләү өчен файдалану планга кертелмәде һәм киләсе чорга да планлаштырылмый.

Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм аларны җыю, ә атап әйткәндә яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршы яки башка ылыслы агачларны кисү киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына ел саен 15,5 мең данә агач күләмендә планлаштырыла.

### 3.5. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатында файдалану

2018 елның 1 гыйнварына рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында Министрлык тарафыннан 1403,0 гектар мәйданда 539 данә шартнамә төзелде, моннан тыш, 222,7 гектар мәйданда 40 кишәрлек даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылды, ягъни рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдаланыла торган урманнарның гомуми мәйданы төбәктәге урманнарның гомуми мәйданының 0,13 процентын тәшкил итә.

Урманнардан файдалануның мондый төре республиканың барлык урманчылыкларында рөхсәт ителгән, шуңа күрә урманнарның рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдалану өчен ихтимал булган

кулланылмаган гомуми потенциалы 1234,6 гектар тәшкил итә. Әмма ләкин әлеге максатларда файдаланыла торган урман кишәрлекләренең 90 проценты диярлек эре шәһәрләр янындагы биш урманчылыкта (Әлмәт, Зеленодольск, Лаеш, Түбән Кама, Шәһәр яны) урнашкан һәм 2019-2029 елларга киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына рекреация эшчәнлеген башкару максатларында файдаланыла торган урман кишәрлекләре санын арттыруны нәкъ менә шушы урманчылыкларда башкару ниятләнә. Урманнарның рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдалану ихтималы булган һәм киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында аңа ихтыяҗ зур булачак потенциалы 182,7 мең гектар тәшкил итә.

## 3.6. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль законның 27 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары нигезендә расланган Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, хайваннар дөньясыннан файдалану өчен аучылык хуҗалыклары юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга гомуми кулланылыштагы аучылык җирләрендә урнашкан урман һәм җир кишәрлекләре чикләрендә бирелә, республикада аларның мәйданы 26 процент тәшкил итә. Дәүләт аучылык фондын саклау, яңадан торгызу, рациональ файдалану, исәпкә алу максатларында, республика территориясендә 96 аучылык хуҗалыгы оештырылды. Аулау оештырыла торган җәнлек-җанварларны комплекслы саклау максатларында 6 Дәүләт аучылык заказнигы оештырылды.

Урман фонды чикләрендә урнашкан урманнар кулланучыларга урман кишәрлекләрен арендага алу шартнамәләре нигезендә аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру максатларында бирелә. 2018 елның 1 гыйнварына аучылык хуҗалыгы өлкәсендә 178 120 гектар мәйданда эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен Министрлык тарафыннан 22 шартнамә төзелде.

Бүген әлеге максатларда файдаланыла торган урманнар, нигездә, урманнарның ешлыгы коэффициенты иң зур булган һәм төбәктә аулана торган хайваннарның төп төрләре – кабан дуңгызы, поши, кыр кәҗәсе, куян, көртлек, бөҗыр, кыр тавыгы күп булган районнарда урнашкан.

Төбәктә аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек тыелган урманнар мәйданы 370,2 мең гектар тәшкил итә. Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек алып бару рөхсәт ителгән һәм мөмкин булган урманнарның файдаланылмаган гомуми потенциалы 656,0 мең гектар тәшкил итә.

## 3.7. Урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару максатларында файдалану

Татарстан Республикасында урманнардан авыл хуҗалыгын алып бару максатларында файдалану фәкать умартачылык белән бәйле. Татарстан Республикасында урманнардан печән чабу яки терлек көтү максатларында файдалану юк, чөнки фермер хуҗалыклары әлеге максатларда авыл хуҗалыгы җирләреннән файдалана, шул исәптән гражданнар мәнфәгатьләрендә. Татарстан Республикасы Урман планын эшләү елы алдыннан килгән елда авыл хуҗалыгын алып бару максатларында файдаланылган урманнарның гомуми мәйданы 2058,3 гектар тәшкил итә. Нигездә урман булмаган агачлыклар, юкә, өрәңге урман биләмәләре, болын һәм көтүлек җирләре читендәге мәйданнар файдаланыла. Авыл хуҗалыгы алып бару максатларында урманнарның файдаланылмаган потенциалы төбәкнең көньяк өлешендә – катнаш урман биләмәләре белән беррәттән, эшкәртелә торган күп санлы кырлар һәм печән чабу өчен кулланыла торган болыннар биләгән урман-дала зонасында тупланган. Барлык шушы факторларны һәм мәгълүматларны исәпкә алып, урманнар алга таба да умартачылык өчен генә файдаланыр дип фаразлана, ә авыл хуҗалыгын алып бару максатларында файдалану өчен мөмкин булган урманнарның файдаланылмаган гомуми потенциалы 3895 гектар тәшкил итә.

## 3.8. Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылма ятмаларны эшкәртү эшләрен башкару, сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын, шулай ук гидротехника корылмаларын, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга порталы, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу вакытында әлеге максатларда урманнардан файдалануның фактик күләме планлаштырганнан күп тапкырлар артып китте. Ел саен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларны эшкәртү өчен 12114,4 гектар мәйданда урманнар файдаланыла, сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү өчен 153,7 гектар мәйданда урманнар файдаланыла.

Тулаем төбәк продуктының 20 проценттан артыгын тәэмин итүче төп производство булып нефть табу тора. Нефть – төбәктә табыла торган төп файдалы казылма байлык, разведка ясалган ятмаларның нибары яртысының гына эшкәртелүен исәпкә алып, урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларны эшкәртү өчен файдалану күләме ел саен арта барачак.

Урманнарның җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен файдаланудагы ихтимал булган бөтен

потенциалы төбәкнең көньяк-көнчыгыш өлешендә, нефть ятмаларының разведка ясалган запаслары тупланган районда урнашкан, анда әлеге максатларда файдалану өчен ихтимал булган урманнарның мәйданы 390,0 мең гектар тәшкил итә.

Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һәм эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдалануның фактик күләмнәре планлаштырган мәгълүматлар белән чагыштырганда артыграк булуга карамастан, төбәктә әлеге максатларда файдаланыла торган нибары 29 урман кишәрлеге бар, нигездә алар эре шәһәрләр чикләрендә – Әлмәт, Зеленодольск, Түбән Кама, Шәһәр яны урманчылыклары урманнарында урнашкан, әлеге максатларда файдалану өчен күздә тотылган урманнарның төп потенциалы нәкъ менә шул урманчылыкларда урнашкан.

## 3.9. Урманнардан файдалануның башка төрләре өчен урманнар потенциалын бәяләү турында мәгълүмат

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорында урманнардан файдалануның өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү тора. Торак пунктларның һәм нефть чыгару объектларының үсеш алган челтәре линияле объектларның – электр үткәргеч линияләр, юллар, торба үткәргечләрнең үсеш алган челтәрен күздә тота. Линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү максатларында файдалану өчен ихтимал булган урманнар республиканың барлык урманчылыкларында бар.

Агач материалы әзерләү максатларында нигездә Әгерҗе, Әлмәт, Зәй, Кызыл Йолдыз урманчылыкларындагы урманнардан файдалану күздә тотыла, анда әлеге максатларда урман кишәрлекләреннән гамәлдәге файдаланучылар бар. Соңгы 4 елда, урман кишәрлекләреннән агач материалы әзерләү максатларында файдалану күләме арту күзәтелмәде, урманнардан агач материалы әзерләү максатларында файдалану күләме Татарстан Республикасы Урман планы гамәленең киләсе чорына элеккеге дәрәҗәсендә булачак. Әмма агач материалы әзерләү максатларында файдалану өчен урманнарның кулланылмаган потенциаль мәйданы 459,6 мең гектар тәшкил итә, ә киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында урманнардан файдалануның фаразланган күләме бу мәйданның 15 процентыннан артмаячак, бу түбән сортлы агач материалының күп булуы, нигездә, саклык функцияләрен башкарган таркау урман кишәрлекләре белән бәйле.

## 3.10. Транспорт юллары төзү, аларны ремонтлау һәм карап тоту ихтыяҗы турында мәгълүмат

Татарстан Республикасының тимер юл линияләрен, гомуми кулланылыштагы федераль һәм төбәк автомобиль трассаларын, муниципалитетара юлларны, шулай ук ел әйләнәсе кулланылышта булган күп сандагы грунт юлларын үз эченә алган юл челтәре илдә иң нык үсеш алганнардан берсе санала.

Барлык төр юллар урман хуҗалыгын алып бару, шул исәптән агач материалын ташу, янгынга каршы патруль, шулай ук башка урман хуҗалыгы чараларын гамәлгә ашыру максатларында файдаланыла.

Татарстан Республикасы юлларының гомуми озынлыгы (торак пунктлар чикләрендәге юллардан тыш) 24492,9 км тәшкил итә. Тимер юллар – 1889,0 км (7,7 процент), каты түшәмәле автомобиль юллары – 13380,8 км (54,6 процент), грунт юллары – 9223,1 км (37,7 процент).

Республиканың барлык урманчылыкларында бөтен юлларның озынлыгы 1000 гектар урманга 10 километрдан ким түгел, аларга урманнар буйлап узучы юллар гына түгел, гомуми кулланылыштагы юллар да карый, чөнки юллар шулай ук урман хуҗалыгы максатларында файдаланыла, бу күрсәткеч төбәк урманнарында транспорт йөрү мөмкинлегенең зур булуы турында сөйли.

Юллар челтәрен алга таба үстерү максатында республика Хөкүмәте күп кенә чаралар күрә, аерым алганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2022 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары үз эченә берничә кече программаны, шул исәптән, «2014 - 2022 елларга автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклау» программасын ала.

Программа нигезендә, ел саен 52 километр гомуми кулланылыштагы федераль автомобиль юллары реконструкцияләнә, 200 километр муниципаль һәм муниципальара юллар төзәтелә һәм карап тотыла, шулай ук 81 километр каты түшәмәле яңа юллар кулланылышка кертелә.

2018 елда Мәскәү-Владимир-Түбән Новгород-Чабаксар-Казан югары тизлекле пассажир магистрален төзи башларга ниятләнә, ул 2023 елда сафка бастырылыр дип көтелә, аның 48 километр озынлыгындагы линиясе ТР территориясеннән узачак. Югары тизлекле магистраль линияне эксплуатацияләүнең башлангыч этабында пассажирлар ташу ниятләнә, киләчәктә линия йөк ташу өчен кулланылачак.

Әлеге максатларда Зеленодольск урманчылыгында гомуми 557 гектар мәйданда урман кишәрлекләреннән файдалану ниятләнә.

Урман фонды җирләрендә ел саен 111,3 километр озынлыктагы грунт өслекле яңа юллар төзү планын исәпкә алып, элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорының соңгы елында юллар челтәре 1000 гектар урманга уртача 21 километр тәшкил итәчәк. МСТТ һәм

торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманнарда Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына яңа юллар төзү планлаштырылмый.

Урман һәм урман эшкәртү инфрастрктурасы объектларының, урманнарда урман инфраструктурасы оештыруга бәйле булмаган объектларның урнашу урыны, урманнарны үзләштерүдә транспорттан файдалану мөмкинлеге, транспорт юллары белән тәэмин ителүнең 3 нче карта-схемасы Татарстан Республикасы Урман планына 1 нче кушымтада бирелде. Урманнарга транспорт керү мөмкинлеге, транспорт юллары белән тәэмин ителү турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Урман планына 19 нчы кушымтада бирелде.

### 3.11 Урманнарның экологик потенциалын, тирәлек булдыру, су саклау, саклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы функцияләрен бәяләү

Урманнарның экологик потенциалын, мохит булдыру, су саклау, саклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы функцияләрен бәяләү Татарстан Республикасы Урман планына 20 нче кушымтада бирелде.

Экологик потенциал урманның тирәлек булдыру, ландшафт-саклау, ландшафт-тотрыклыландыру һәм хуҗалык-экологик функцияләренең уртак нәтиҗә бирүе дигәнне аңлата.

Экологик потенциалны бәяләүгә өстенлекле токымнар буенча бонитет классы, уртача тыгызлык һәм уртача еллык үсеш кебек таксация күрсәткечләре кертелде; исәпләүләр урманнар үскән мәйданда тиешле урманнарның токым составын һәм өлешен исәпкә алып үткәрелде.

Экологик потенциалны бәяләү – 2017 ел, 30 июнь, 20-р номерлы Россия Федерациясе ТРЭМ боерыгы белән расланган «Парник газларын йоту күләмен микъдари билгеләү буенча методик күрсәтмәләр» нигезендә үткәрелде. Урманнарның потенциалы шартлы берәмлекләрдә чагылдырыла, акча эквивалентына күчерелә. Бәяләү универсаль һәм вакыт динамикасында тиешле күрсәткечләрне чагыштырырга мөмкинлек бирә.

Әмма тоташтан кисүләр һәм корткычлар зарарлау, авырулар аркасында агачларның һәлак булуы арту сәбәпле, идарә ителә торган урманнарда углерод киму дәрәҗәсе артуын билгеләп үтәргә мөмкин.

Урман функциясенең иң мөһим күрсәткече –туфракның юылуына юл куймау, ягъни урманнар кар һәм яңгыр суларының туфракны һәм грунтны юдыруына каршы тора, әһәмиятле туфрак саклау факторы булып тора. Урманның су-җайга салу функциясе өслектәге агынтылар күләме артуны булдырмаудан гыйбарәт, әйтик, 2017 елда республика урманнарының өслектәге агынтыларны булдырмау күләме гектарына 136,5 куб.метр тәшкил итте, су-җайга салу функциясеннән икътисадый нәтиҗә – 17,8 млрд.сум.

2017 елда урманнарның санитария-гигиена функциясе түбәндәгечә чагылды: кислород бүлеп чыгару – 9508,7 мең тонна, зарарлы матдәләрне

йоту – 17828,0 мең тонна, тузан йоту – 102024,0 мең тонна, фитонцидлар бүлеп чыгару – 3,2 мең тонна.

Төбәк урманнары, нигездә, рекреация һәм саклау функцияләрен башкаручы яклагыч урманнарга карый. Шуңа бәйле рәвештә урманнардан файдалануның яклагыч урманнарда тыелган кисүләргә бәйле булмаган юнәлешләре зур әһәмияткә ия. Бу урманнарны рекреация максатларында файдалану булырга мөмкин.

Рекреация урманнары дип ял һәм туризм, эстетик һәм танып-белү ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кулланылучы табигать ресурслары атала.

Рекреация урманнары төп ике төркем функцияләрне башкарырга тиеш: мохитне саклау һәм рекреацион. Рекреацион функцияләр – ул кешенең физик һәм рухи көчләрен торгызучы, аның тере табигать белән аралашуга ихтыяҗын канәгатьләндерүче функцияләр.

Әмма, артык зур рекреация басымы нәтиҗәсендә урман мохитенең ихтимал бозылуын булдырмау һәм урманнарның санитария-гигиена, башка файдалы функцияләрен саклау максатында, урманнардан файдаланганда урманнарны һәм урман ресурсларын саклау һәм аларны арттыруга юнәлтелгән гамәлдәге нормаларны һәм кагыйдәләрне катгый үтәү зарур.

# IV. Татарстан Республикасы Урман планының, чаралар башкаруның максатлары һәм бурычлары һәм Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорга план күрсәткечләре

## 4.1. Татарстан Республикасы Урман планының икътисад, экология һәм социаль өлкәләрдәге бурычлары һәм максатлары

Татарстан Республикасы Урман планы урманны планлаштыру документы булып тора (РФ УК 85 статьясы), анда урманны планлаштыруның максатлары һәм бурычлары билгеләнә, ТР территориясендәге урманчылыклар, урман-парклар чикләрендә урнашкан урманнарны планлаштырылган үзләштерүне гамәлгә ашыру буенча чаралар тәгаенләнә. Урманнардан файдалану, аларны саклау, саклау, торгызу өлкәсендә планлаштыру төбәкнең тотрыклы үсешен тәэмин итүгә юнәлтелгән.

Татарстан Республикасы Урман планының төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

1) төбәк урманнары белән нәтиҗәле идарә итү;

2) җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен урманнардан рациональ, күп максатлы, өзлексез, аларның ярлылануына юл куймыйча файдалануны тәэмин итү;

3) төбәкнең экологик хәлен яхшырту өчен урманнарның экологик потенциалын саклау, аларның тирәлек булдыру, су саклау, саклык, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы функцияләрен саклау буенча чаралар үткәрү;

4) урманнардан файдалануның төрләре өчен урманнарны үзләштерүгә (РФ УК 25 статьясы нигезендә), шулай ук урманнарны саклауга һәм торгызуга юнәлтелгән планлы үзләштерүне гамәлгә ашыру буенча чаралар әзерләү.

5) Татарстан Республикасы урман сәнәгате комплексын алга таба үстерү һәм камилләштерү өчен алшартлар тудыру;

6) төбәк икътисадының урман секторы социаль өлкәсен яхшырту һәм хезмәткәрләрнең тормый дәрәҗәсен яхшыртуны тәэмин итү.

Эшләнгән Татарстан Республикасы Урман планы бурычлары түбәндәгеләр:

1) Татарстан территориясендә табигать ресурслары һәм экология өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;

2) халыкның экологик иминлеген, әйләнә-тирә мохитне саклауны, урман ресурсларыннан рациональ файдалануны, урманнарның биологик төрлелеген саклау һәм төбәк территориясендә аларның потенциалын арттыруны тәэмин итү;

3) төбәк урманнарының экологик потенциалын саклау буенча планлаштырылган чараларны әзерләү;

4) урманнардан файдалану мөмкинлекләрен анализлау, аларны фактик үзләштерүне бәяләү һәм шулар нигезендә, Татарстан Республикасы Урман

планын гамәлгә ашыру чорына төбәк урманнарыннан файдалануның перспектив юнәлешләрен һәм төрлечә файдалану өчен урманнарны планлы үзләштерү зоналарын эшләү;

5) урман хуҗалыгын алып баруның, ресурслар һәм кадрлар белән тәэмин итүнең оптималь төбәк системасын оештыруны планлаштыру;

6) урманнарның тирәлек булдыру, су саклау, санитария-гигиена һәм башка файдалы функцияләрен икътисадый бәяләү;

7) Татарстан Республикасы Урман планы чараларын гамәлгә ашыруның икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү.

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорында Министрлык тарафыннан өстенлекле максатларны һәм бурычларны гамәлгә ашыру өчен төбәктәге урманнар ешлыгын арттыру чараларын, шул исәптән 1900 елдан 2017 елга кадәр гомуми мәйданы 141 мең гектарлы Министрлык тарафыннан булдырылган кыр саклагыч урманнарны исәпкә алып, гамәлгә ашыру планлаштырыла. Әлеге урман кишәрлекләренең, файдаланучылар кишәрлекләренең чикләрен, урманнарның хәзерге торышын билгеләп исәпкә алу әлеге урманнарның «статус»ын билгеләргә, шулай ук урман кишәрлекләре турындагы мәгълүматларны ДУР белешмәләренә кертергә мөмкинлек бирәчәк, бу исә Татарстан Республикасында урманнар үсү дәрәҗәсен күрсәтәчәк, ул кимендә 19,0 процент тәшкил итәчәк.

Кисү вакытына юанлыгы җитәрлек һәм югары бонитетлы агачлар формалаштыру мөмкинлеген бирә торган урман хуҗалыгы чараларын вакытында һәм сыйфатлы уздыру хисабына агачларның продукция бирүен арттыруга ирешү планлаштырыла, бу хәл бер гектарга агачларны кисү күләмен арттырырга, шулай ук зәгыйфьләнгән, тотрыклылыгын, яшәргә сәләтен югалта баручы агачларны яшь, үсешен һәм максатчан функцияләрен саклаучы урманнарга алмаштыру максатларында яңарту һәм формасын үзгәртү өчен агач кисү мөмкинлеген бирәчәк. Шулай ук продукция бирүен арттыру өчен нәселдәнлек үзлекләре яхшыртылган үсентеләр файдалану планлаштырыла. Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чоры тәмамланганда әлеге күрсәткечне 6,1 процентка кадәр җиткерү каралган.

Татарстан Республикасының яңа Урман планының көтелгән нәтиҗәсе: элеккеге Татарстан Республикасы Урман планын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең фактик күрсәткечләрен, шулай ук киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына бирелгән максатчан фараз күрсәткечләрен ачыклау.

## 4.2. Урманнарның экологик потенциалын саклау, климат үзгәрешләренә яраклаштыру һәм урманнарның тотрыклыгын арттыру буенча планлаштырыла торган чаралар

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Урман планының стратегик максатлары – төбәк урманнарының экологик потенциалын саклау, экологик хәлне яхшырту һәм төбәк халыкының һәм

территорияләренең экологик иминлеген тәэмин итү, урман экосистемаларын саклау һәм торгызу, урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә табигатьтән рациональ һәм тотрыклы файдалануны тәэмин итү.

Төбәктәге урманнарга төп антропоген йогынты факторлары булып сәнәгать җитештерүе калдыклары, гидрологик режимның үзгәрүе, рекреация басымы тора, алар, үз чиратында, турыдан-туры климат үзгәрешләренә тәэсир итә, шул исәптән уртача тәүлеклек температура артуына китерә, бу исә әлеге шартларга яраклашмаган үсемлекләр үсешенә тискәре йогынты ясый.

Әмма, һичшиксез, әйләнә-тирә мохитнең пычрануы – табигатькә антропоген йогынтының бер төре, ул тискәре, ә төзәтелмәслек үзгәрешләргә китерә. Сәнәгатьнең, аеруча химия һәм эшкәртү сәнәгатенең, энергетиканың, транспортның тиз үсеше, авыл хуҗалыгын интенсификацияләү табигатькә глобаль йогынты ясый башлады. Әйләнә-тирә мохитнең пычрану күләме шулкадәр зур ки, табигатьнең үзлегеннән чистарыну процесслары кеше хуҗалык эшчәнлегенең озон өслеге бозылу, грунт сулары үзгәрү һәм башка төрле климат үзгәрешләре кебек хәвефләрнең төзәтеп булмый торган тискәре нәтиҗәләрен нейтральләштерә алмый.

Министрлык тарафыннан урманнарны саклау, торгызу буенча башкарыла торган чараларны урманнарның экологик потенциалын саклауга, климат үзгәрешләренә җайлаштыруга һәм урманнарның тотрыклылыгын арттыруга юнәлтелгән чаралар буларак карарга мөмкин.

Урманнарның экологик потенциалын саклау, климат үзгәрешләренә яраклаштыру һәм урманнарның тотрыклылыгын арттыру өчен Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны янгыннардан саклау, урманнарны торгызу, урманнардан файдалану, янгынга каршы минераллаштырылган полосалар кору, янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм яңарту, чыбык-чабыкны, урман түшәмәсен, коры үләннәрне һәм урмандагы тиз кабынучан башка материалларны профилактика өчен контрольдә тотып яндыру, урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматларны үз эченә алган стендларны һәм башка тамгаларны һәм күрсәткечләр урнаштыру, урманнарда янгын куркынычын һәм урман янгыннарын мониторинглау, җир өсте патрулен оештыру чаралары планлаштырыла. Зарарлы организмнарның чыганакларын локальләштерү һәм бетерү, шул исәптән санитария максатларында тоташтан һәм сайлап агач кисү, ликвидлы булмаган агач материалын җыю. Ясалма һәм табигый урман торгызу эшләреннән торган урман торгызу чаралары.

Урманнарның экологик потенциалын саклау, климат үзгәрешләренә җайлаштыру һәм урманнарның тотрыклылыгын арттыру буенча планлаштырылган чаралар Татарстан Республикасы Урман планына 21 нче кушымтада бирелде.

## 4.3. Урманнарны фактик үзләштерү мөмкинлекләрен анализлау һәм бәяләү нигезендә урманнардан файдалануның перспективалы юнәлешләре, урманнарны төп төрләре буенча файдалануны арттыру, Урман планын гамәлгә ашыру чорына план күрсәткечләре

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорда төбәк урманнарыннан файдалануның 2.1 бүлектә бирелгән анализы күрсәткәнчә, төбәктә урманнардан файдалану аның барлык мөмкин булган төрләре буенча гамәлгә ашырыла диярлек, әмма төбәктә урманнардан файдалануның аеруча зур ихтыяҗ булган төрләре – агач материалы әзерләү, рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясының 2 өлеше нигезендә билгеләнгән башка эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру. Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү эшләре урманнардан файдалануның төп төрләре түгел, әмма алар төрле ешлыкта урманнарда шулай ук башкарыла.

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына агач материалы әзерләү өчен урманнардан файдалану, үсеш алган автомобиль юллары челтәре, шулай ук төбәктә агач эшкәртү комплекслары булуны исәпкә алып, урманнардан файдалануның иң мөһим юнәлешләреннән берсе булачак.

Татарстан Республикасы Урман планы эшләнгән елдан алда килгән елда барлык төр агач кисүләрдә гомуми 15911 гектар мәйданда 1008 мең куб.метр ликвид агач материалы әзерләнде. Шул исәптән өлгергән һәм картайган агачларны кискәндә – 309,2 мең куб.метр ликвид агач материалы (агач әзерләүнең гомуми күләменнән 30,7 процент), урманнарны тәрбияләү максатларында кисүләр вакытында – 341,8 мең куб.метр ликвид агач материалы (33,9 процент), һәлак булган һәм зарарланган агач урманнарын кискәндә – 331,7 мең куб.метр (32,9 процент), урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын һәм урман инфраструктурасы оештыруга бәйле булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән агачларны кискәндә – 25,7 мең куб.метр ликвид агач материалы (2,5 процент).

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорында барлык төр кисүләрдә гомуми 129619,5 гектар мәйданда 6871,2 мең куб.метр ликвид агач материалы әзерләнде. Шул исәптән өлгергән һәм картайган агачларны кискәндә – 1917,8 мең куб.метр ликвид агач материалы (агач әзерләүнең гомуми күләменнән 27,9 процент), урманнарны тәрбияләү максатларында агач кисү вакытында – 2055,6 мең куб.метр ликвид агач материалы (29,9 процент), һәлак булган һәм зарарланган агач урманнарын кискәндә – 2333,0 мең куб.метр (34,0 процент), урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын һәм урман инфраструктурасы оештыруга бәйле булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү

өчен билгеләнгән агачларны кискәндә – 564,8 мең куб.метр ликвид агач материалы (8,2 процент) әзерләнде.

Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның план чорына өлгергән һәм картайган агачларны кискәндә ликвидлы агач материалын әзерләүнең ел саен мөмкин булган күләме 14801,6 гектар мәйданда 2025,8 мең куб.метр тәшкил итәчәк. Урман кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан дәүләт экспертизасын узган урманнарны үзләштерү проектлары нигезендә ел саен 106,0 мең куб.метр ликвидлы агач, гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлар өчен агач материалы әзерләү максатында ел саен 90,0 мең куб.метр ликвидлы агач кисү күздә тотыла. Кече һәм урта бизнес предприятиеләренә дәүләт ярдәмен исәпкә алып, ул юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан агач материалы әзерләү күләменең зур тизлек белән үсүенә йогынты ясады, 2019 елдан башлап кече һәм урта бизнес предприятиеләре өчен аукционнар уздыру юлы белән кимендә 588,1 мең куб.метр ликвид булмаган агач материалын сату күздә тотыла, план буенча 2021 елда ачылырга тиешле, проектта каралган тулай куәте 3200,0 мең куб.метр тәшкил итәчәк «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ заводының өченче чираты производствосын чимал белән тәэмин итү өчен өлгергән һәм картайган агачларны тоташтан кисү дә агач материалы әзерләү күләмнәрен арттырачак.

Урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын, урман инфраструктурасы оештыруга бәйле булмаган объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән агачларны кискәндә – ел саен 426,9 гектар мәйданда 5,5 мең куб.метр, шул исәптән РФ УК 43 - 46 статьялары нигезендә, урманнардан файдаланучы затларның аерым категорияләре тарафыннан урманнарны торгызуны һәм урманнарны үрчетүне гамәлгә ашыру өчен агач кисү.

Агачларның яшенә һәм урманнарны тәрбияләү максатларына карап, киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына агачларны карау максатларында уздырыла торган агач кисү эшләрендә агач материалын әзерләүне түбәндәге юллар белән башкару планлаштырыла: сирәкләү, аркылы кисү, агачларны яңарту максатында кисү, агачларның формаларын үзгәртү максатында кисү. Агачларны сирәкләп һәм аркылы кисү вакытында агач материалы әзерләүнең ел саен мөмкин булган күләме 8501,5 гектар мәйданда 290,7 мең куб.метр тәшкил итәчәк. Формаларын үзгәртеп кисү һәм яңартып кисү агач кисүнең ел саен мөмкин булган күләме ел саен махсус тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланачак.

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына төрле әзерләүчеләр тарафыннан агач материалы әзерләүнең планлаштырылган күләмнәре 5 нче таблицада күрсәтелде.

5 нче таблица

Төрле әзерләүчеләр тарафыннан агач материалы әзерләүнең планлаштырылган күләмнәре

| Әзерләүче | Үлч. бер. | Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорының елы | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Урман кишәрлекләрен арендага алучылар | гектар | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 | 1840,0 |
| | мең куб. метр | 106,0 | 106,0 | 106,0 | 106,0 | 106,0 | 106,0 | 106,0 | 106,0 | 106,0 | 106,0 |
| Гражданнар шәхси ихтыяҗлары өчен | гектар | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 |
| | мең куб. метр | 90,0 | 90,0 | 90,0 | 90,0 | 90,0 | 90,0 | 90,0 | 90,0 | 90,0 | 90,0 |
| Юридик затлар һәм хосусый эшкуарлар | гектар | 3980,4 | 5652,1 | 8082,5 | 12527,6 | 12527,6 | 12527,6 | 12527,6 | 12527,6 | 12527,6 | 12527,6 |
| | мең куб. метр | 588,1 | 835,1 | 1194,1 | 1852 | 1852 | 1852 | 1852 | 1852 | 1852 | 1852 |
| Сирәкләү, аркылы кисү уздыру юлы белән, урманнарны тәрбияләү максатларында Урманлыклар тарафыннан башкарыла торган агач кисү | гектар | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 | 7935,5 |
| | мең куб. метр | 268,0 | 268,0 | 268,0 | 268,0 | 268,0 | 268,0 | 268,0 | 268,0 | 268,0 | 268,0 |
| Урман, урман эшкәртү инфраструк-турасы объектларын һәм урман инфраструк-турасы оештыруга бәйле булмаган объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатаци-яләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләре- | гектар | 426,9 | 426,9 | 426,9 | 426,9 | 426,9 | 426,9 | 426,9 | 426,9 | 426,9 | 426,9 |
| | мең куб. метр | 5,5 | 5,5 | 5,5 | 5,5 | 5,5 | 5,5 | 5,5 | 5,5 | 5,5 | 5,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ндә урман кискәндә | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | гектар | 15182,8 | 16854,5 | 19284,9 | 23730,0 | 23730,0 | 23730,0 | 23730,0 | 23730,0 | 23730,0 | 23730,0 |
| | мең куб. метр | 1057,6 | 1304,6 | 1663,6 | 2321,5 | 2321,5 | 2321,5 | 2321,5 | 2321,5 | 2321,5 | 2321,5 |

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен урманнардан төрле максатларда, рациональ, өзлексез, аларны ярлыландырмыйча файдалану максатларында, гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен агач материалы әзерләү, юридик һәм хосусый эшкуарларга инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, дәүләт ихтыяҗларын яки муниципаль ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатларында, урманнардан планлаштырылган файдалану зоналарына бүлеп, урман фонды җирләре территориясе зоналарга бүленде һәм 6 нчы таблицада бирелде.

Зоналарга бүлү элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорында урманчылыкларда агач кисү күләмнәрен исәпкә алып, шулай ук агач материалы әзерләү максатларында урманнардан файдалану гамәлдәге шартнамәләр нигезендә башкарылуын исәпкә алып эшләнде.

6 нчы таблица

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорга җәмгыятьнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен агач материалы әзерләү максатларында урманнардан файдалануның планлаштырылган зонасы

| Урманчылык | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү буенча агач материалы әзерләүнең мөмкин булган гомуми күләменнән гражданнар тарафыннан шәхси ихтыяҗлары өчен агач материалы әзерләү, процент | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү буенча агач материалы әзерләүнең мөмкин булган гомуми күләменнән, Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан агач материалы әзерләү, процент | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү буенча агач материалы әзерләүнең мөмкин булган гомуми күләменнән урманнарны үзләштерү өлкәсендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен агач материалы әзерләү, процент | Өлгергән һәм картайган агачларны кисү буенча агач материалы әзерләүнең мөмкин булган гомуми күләменнән дәүләт ихтыяҗларын яки муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен агач материалы әзерләү, процент |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Әгерҗе | 0,8 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Азнакай | 1,7 | 98,3 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Аксубай | 3,4 | 96,6 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Әлки | 5,4 | 94,6 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Әлмәт | 1,3 | 80,7 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Арча | 23,1 | 76,9 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Баулы | 10,3 | 89,7 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Биләр | 6,4 | 93,6 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Болгар | 1,1 | 98,9 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Бөгелмә | 2,9 | 97,1 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Буа | 7,6 | 92,4 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Алабуга | 2,5 | 97,5 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Зәй | 2,8 | 77,2 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Зеленодольск | 26,9 | 73,1 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Ары | 13,5 | 86,5 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Кайбыч | 11,6 | 88,4 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Көләй | 1,9 | 98,1 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Кама | 6,9 | 93,1 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Кызыл Йолдыз | 12,0 | 85,0 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Лаеш | 12,3 | 87,7 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Лениногорск | 3,0 | 97,0 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Мамадыш | 18,9 | 81,1 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Минзәлә | 3,5 | 96,5 | Планлаштырылм ый | Планлаштырыл-мый |
| Түбән Кама | 2,6 | 97,4 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Нурлат | 4,2 | 95,8 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |
| Идел буе | 19,7 | 80,3 | Планлаштырыл-мый | Планлаштырыл-мый |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Шәһәр яны | Планлаштырылмый | Планлаштырылмый | Планлаштырылмый | Планлаштырылмый |
| Саба | 0,1 | 99,9 | Планлаштырылмый | Планлаштырылмый |
| Тәтеш | 7,3 | 92,7 | Планлаштырылмый | Планлаштырылмый |
| Чирмешән | 2,9 | 97,1 | Планлаштырылмый | Планлаштырылмый |
| Лубян | 0,3 | 99,7 | Планлаштырылмый | Планлаштырылмый |

Агач материалы әзерләүгә бәйле рәвештә агач кисүдән агач материалы алуның ел саен рөхсәт ителгән күләме (файдалану өчен исәпләнгән диләнке) 7 нче таблицада күрсәтелде. Һәлак булган һәм зыян күргән агачларны ел саен кисү күләме Татарстан Республикасында урманнарның санитар торышын исәпкә алып исәпләнә.

Татарстан Республикасында агач материалы әзерләү максатларында урман кишәрлекләреннән файдаланучы арендаторлар тарафыннан киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорга ел саен гомуми 62770,5 гектар мәйданда 106 мең куб.метр ликвидлы агач материалы әзерләү планлаштырыла.

Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булган чорга урманнардан файдалануның төп һәм аеруча перспективалы берничә төре булуга карамастан, төбәктәге урманнардан мөмкин булган барлык төрләрдә диярлек файдалану планлаштырыла. Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына урманнардан файдалануның әлеге перспективалы юнәлешләре Татарстан Республикасы Урман планына 22 нче кушымтада күрсәтелде.

7 нче таблица

**Татарстан Республикасы урманнарында агач материалы әзерләүгә бәйле рәвештә агач кисүдән алынган агач материалының ел саен рөхсәт ителгән күләме (файдалану өчен исәпләнгән диләнке)**

| Агач кисү төрләре | Ылыслы | | | Яфраклы каты токымнар | | | Яфраклы йомшак токымнар | | | Барлыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәй-даны, га | Запасы, мең куб.метр | | мәй-даны, га | Запасы, мең куб.метр | | мәй-даны, га | Запасы, мең куб.метр | | мәй-даны, га | Запасы, мең куб.метр | |
| | | лик-видлы | эшкә ярак-лы | | лик-вид-лы | эш-кә яраклы | | лик-вид-лы | эшкә ярак-лы | | лик-видлы | эшкә яраклы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Өлгер-гән һәм картай-ган урман кискән-дә | 492.2 | 77.5 | 63.6 | 1069.1 | 75.55 | 46.1 | 13240.3 | 1872.3 | 849.2 | 14801.6 | 2025.3 | 958.9 |
| Урман-нарны карау максат-ларында урман кискән-дә: сирәк-ләп кискән-дә, аркылы кискән-дә | 3727.3 | 147.5 | 101.9 | 1124.2 | 24.4 | 9.1 | 3650.0 | 118.8 | 53.5 | 8501.5 | 290.7 | 164.5 |
| Урман, урман эшкәртү инфрас-труктурасы объект-ларын һәм урман инфрас-труктурасы объект-ларын оешты-руга бәйле булма-ган объект-ларны төзү, үзгәртеп | 68.7 | 1.6 | 1.1 | 62.0 | 0.3 | 0.2 | 296.2 | 3.6 | 1.3 | 426.9 | 5.5 | 2.6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| кору һәм эксплу-атация-ләү өчен билге-ләнгән урман кискән-дә | | | | | | | | | | | | |
| Бар-лыгы | 4288.2 | 226.5 | 166.6 | 2255.3 | 100.3 | 55.4 | 17186.5 | 1994.7 | 904.0 | 23730.0 | 2321.5 | 1126 |

Җәмгыятьнең ресурс потенциалын арттыру өчен Татарстан Республикасы урманнарыннан рекрация максатларында файдалануның әһәмияте шактый зур. Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру республикада урманнардан файдалануның иң массакүләм төрләренең берсе булып тора, шәһәрләрдә яшәүчеләр саны даими тизлек белән артуга бәйле рәвештә туризм һәм табигатьтә ял итү популярлаша һәм аңа ихтыяҗ арта.

Урман кишәрлекләреннән рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдаланучы дәвалау-савыктыру, спорт һәм башка учреждениеләрдән тыш, төбәк чикләрендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү күздә тотылган урманнарны үзләштерүнең планлаштырыла торган, 8 нче таблицада билгеләнгән берничә зонасы бар. Спортны һәм сәламәт яшәү рәвешен үстерүгә юнәлдерелгән, тормышка ашырыла торган берничә проектка Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Президенты тарафыннан теләктәшлек белдерелде.

8 нче таблица

Чикләрендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру объектларын төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү күздә тотылган урманнарны үзләштерүнең планлаштырыла торган зоналары

| Урман-чылык | Кишәрлек урманчы-лыгы | Квар-тал № | Файдаланучының, объектның атамасы | Планлаштырыла торган чаралар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Әлки | Базарлы Матак | 17 | «Дубки» БСЛ муниципаль учреждениесе | Үзгәртеп кору максатларында спорт-техник корылмалар төзелеше планлаштырыла |
| Әлмәт | Поташ-Полянка | 106, 114, 155, 156 | «Орленок» БСЛ, «Дружба», «Солнечный», «Юность» спорт-савыктыру лагерьлары | Үзгәртеп кору максатларында физик культура-савыктыру һәм спорт-техник билгеләнешендәге корылмалар комплексын төзекләндерү һәм төзү планлаштырыла |
| Әлмәт | Поташ-Полянка | 134, 135 | «Ян» таудан чаңгы шуу комплексы | Таудан чаңгы шуу комплексын үзгәртеп кору максатларында чаңгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | трассасын киңәйтү күздә тотыла |
| Әлмәт | Поташ-Полянка | 174, 175, 202 | «Ян» таудан чаңгы шуу комплексы | Таудан чаңгы шуу комплексын үзгәртеп кору максатларында спорт-техник корылмалар төзү планлаштырыла |
| Әлмәт | Поташ-Полянка | 5, 6, 134 | «Ян», «Ромашкино» шифаханә-профилакторийлар ы | Шифаханәләрне үзгәртеп кору максатларында спорт һәм физик культура-савыктыру корылмаларын төзү планлаштырыла |
| Әлмәт | Поташ-Полянка | 134 | «СМП-Нефтегаз» АҖ | Халыкны ял иттерү һәм савыктыру максатларында парк тибында спорт-савыктыру комплексын төзү планлаштырыла |
| Әлмәт | Поташ-Полянка | 106 | «Транснефть-Прикамье» АҖ (ӘРНИ) | Шифаханәне үзгәртеп кору максатларында спорт һәм физик культура-савыктыру корылмаларын төзү планлаштырыла |
| Әлмәт | Поташ-Полянка | 174, 175, 202 | «Снежинка» ҖЧҖ «Юность» ӨББ МБУ | Таудан чаңгы шуу комплексын үзгәртеп кору максатларында спорт-техник корылмалар төзелеше планлаштырыла |
| Буа | Чүпрәле | 35, 36 | «Чайка» БСЛ МАУ | Чүпрәле районында туризмны һәм рекреация зоналарын үстерү максатларында таудан чаңгы шуу трассаларын төзү планлаштырыла |
| Лаеш | Питрәч | 76, 79, 80 | Питрәч районының «Комплекслы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» ӨББ МБМУ | Рекреация зоналарын үстерү максатларында чаңгы юллары һәм җәяүлеләр юллары өчен маршрут булдыру планлаштырыла |
| Лаеш | Питрәч | 76 | Питрәч районының «Комплекслы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» ӨББ МБМУ | Халыкны ял иттерү һәм савыктыру максатларында спорт корылмаларын төзү планлаштырыла |
| Мамадыш | Кләүш | 100 | Мамадыш районының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ | Мамадыш районында халыкны ял иттерү, савыктыру һәм рекреация зоналарын үстерү максатларында спорт һәм физик культура-савыктыру корылмаларын төзү планлаштырыла |
| Мамадыш | Комазан | 96 | Мамадыш районының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МУ | Халыкны ял иттерү максатларында парк тибында ял итү мәйданчыкларын төзү планлаштырыла |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Мамадыш | Комазан | 97 | Мамадыш районының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге | Халыкны ял иттерү һәм савыктыру максатларында чаңгы трассасын һәм спорт корылмаларын төзү планлаштырыла |
| Мамадыш | Соколка | 26 | «Кама» БСЛ МБУ | Балаларны ял иттерү һәм савыктыру максатларында балаларны савыктыру лагерын үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү планлаштырыла. Рекреация һәм мәктәп балаларының ял итү зоналарын үстерү максатларында спорт-савыктыру объектларын төзү планлаштырыла. |
| Минзәлә | Юртау | 152 | «Балалар иҗаты йорты» ӨББ МБУ | Балаларны ял иттерү һәм савыктыру максатларында балаларны савыктыру лагерын үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү планлаштырыла |
| Минзәлә | Юртау | 153 | «Олимп» БЯСМ ӨББ МБМУ | Рекреация зоналарын үстерү максатларында чаңгы юллары һәм җәяүлеләр юллары өчен маршрут булдыру планлаштырыла |
| Түбән Кама | Баграж | 70 | «Ялта-Зәй» спорт әзерлеге үзәге коммерциячел булмаган спорт учреждениесе» | Республикада чаңгы шуу спортын үстерү максатларында спорт корылмасын төзү планлаштырыла |
| Түбән Кама | Биклән | 7, 8, 9, 10 | «Батыр» БЯСМ» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | Түбән Кама районында туризмны һәм рекреация зоналарын үстерү максатларында чаңгы трассаларын төзү планлаштырыла |
| Түбән Кама | Биклән | 26, 118 | «Чайка» БСЛ | Үзгәртеп кору максатларында физик культура-савыктыру һәм спорт-техник билгеләнешендәге корылмалар комплексын төзү планлаштырыла |
| Түбән Кама | Биклән | 118 | «Түбән Кама индустриаль техникумы» ДАҺББУ | Түбән Кама районында туризмны һәм рекреация зоналарын үстерү максатларында чаңгы трассаларын төзү планлаштырыла |
| Түбән Кама | Биклән | 2 | «Нижнекамскнефте хим» ГАҖ «Нефтехимик» спорт клубы учреждениесе | Түбән Кама районында туризмны һәм рекреация зоналарын үстерү максатларында чаңгы трассаларын төзү планлаштырыла |
| Түбән Кама | Кызыл Йолдыз | 30 | БСЛ МБУ «Заря» | Лагерьны үзгәртеп кору максатларында спорт һәм физик культура-савыктыру корылмаларын төзекләндерү һәм төзү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | планлаштырыла |
| Нурлат | Чулпан | 42 | «Заречный» БСЛ | Рекреация зоналарын үстерү максатларында физик культура-савыктыру һәм спорт-техник билгеләнешендәге корылмаларны төзү һәм үзгәртеп кору планлаштырыла |
| Нурлат | Чияле Алан | 89, 96 | «Вишневая Поляна» БСЛ | Рекреация зоналарын үстерү максатларында физик культура-савыктыру һәм спорт-техник билгеләнешендәге корылмаларны төзү һәм үзгәртеп кору планлаштырыла |
| Нурлат | Чияле Алан | 80, 120 | БЯСМ | Рекреация зоналарын үстерү максатларында физик культура-савыктыру һәм спорт-техник билгеләнешендәге корылмаларны төзү һәм үзгәртеп кору планлаштырыла |
| Идел буе | Ключище | 27 | Инвестиция үсеше агентлыгы | Халыкны ял иттерү максатларында актив ял (баулы парк) паркын төзү планлаштырыла |
| Идел буе | Шыланга | 66, 27 | Казаньоргсинтез | Халыкны тернәкләндерү һәм савыктыру максатларында социаль-юнәлешле һәм мәдәни-савыктыру объектын булдыру планлаштырыла. |
| Идел буе | Ключище | 27 | Инвестиция үсеше агентлыгы | Халыкны ял иттерү максатларында актив ял (баулы парк) паркын төзү планлаштырыла |
| Шәһәр яны | Матюшино | 11, 13, 24, 25 | «Балкыш шифаханәсе» («Татэнерго» АЖ) | Халыкны дәвалау һәм ял иттерү максатларында шифаханә-профилакторийны үзгәртеп кору планлаштырыла |
| Шәһәр яны | Матюшино | 24 | «Балкыш шифаханәсе» («Татэнерго» АЖ) | Халыкны савыктыру максатларында дәвалау-савыктыру объектларын төзү планлаштырыла |
| Тәтеш | Тәтеш | 79 | Тәтеш районының БЯСП өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | Рекреация зоналарын үстерү максатларында чаңгы юллары һәм җәяүлеләр юллары һәм ярышлар өчен маршрут булдыру планлаштырыла |
| Тәтеш | Тәтеш | 150 | «Чайка» БСЛ | Рекреация һәм мәктәп балаларының ял итү зоналарын үстерү максатларында спорт-савыктыру объектларын үзгәртеп кору һәм төзү планлаштырыла. |

Элеккеге Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булу чорында рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану

templarын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына ел саен урманнардан 1450,9 гектардан ким булмаган мәйданда файдалану планлаштырыла, ә киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның бөтен чорына әлеге максатларда урманнардан файдалануның гомуми күләме 15947,2 гектар тәшкил итәчәк.

Разведкалау мәгълүматлары буенча Татарстан Республикасында төп файдалы казылмалар булып нефть, күмер, янучан сланец, бакыр, торф, известьташ һәм доломитлар тора. Әмма төбәкнең төп байлыгы һәрчак нефть булды. Нәкъ менә нефть ятмаларын эшкәрткәндә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү буенча эшләр башкару максатларында урманнар файдаланыла. Гомумән алганда, төбәктә 120дән артык нефть ятмасы эшкәртелә, аларның иң зурлары – төбәкнең көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан Ромашкино, Баулы, Саусбаш, Новоелхово ятмалары. Татарстанда нефть чыгаруның 70 елдан артык тарихы булуга карамастан, төбәктә элеккечә файдалы казылмаларның яңа ятмаларын эзләүгә юнәлтелгән геологик разведка, шулай ук махсус полигоннарда чыгару авыр булган нефть запасларын табу буенча яңа ысулларны һәм алдынгы технологияләрне сынау эшләре үткәрелә.

Бу факторларның барысы да урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү буенча эшләр башкару максатларында файдалануның перспективасы булу турында сөйли. Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына урманнардан әлеге максатларда файдалану күләме тайпылышсыз үсәчәк һәм 2028 елга елына 13709 гектардан да ким булмаячак, ә Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның бөтен чорына урманнардан файдалануның гомуми күләме 127975,6 гектар булыр дип көтелә.

Бүгенге аучылык элеккедән нык аерылып тора. Әгәр элек аучылык ризык табу ысулы булса, хәзер ул саны даими артып торучы зур шәһәрләрдә яшәүчеләр ялының бер төре, экотуризм, балык тоту һәм аучылык ярдәмендә көндәлек мәшәкатьләрдән читләшү теләге елның-елында популярлаша барачак. Төбәк буенча барлык автомобиль юлларының үсеш алган челтәрен, үтеп булмый торган территорияләр булмавын һәм республикада теләсә кайсы ноктага барып җитү мөмкинлеген исәпкә алып, 26 төр имезүче һәм 41 төр коштан торган аучылык фаунасын да өстәп, төбәкнең күп кенә урманчылыкларында урманнардан аучылык өлкәсендә эшчәнлек алып бару максатларында файдалану Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына төп файдалану төрләренең берсе булачак.

Әлеге максатларда ел саен файдаланырга планлаштырылган урманнарның гомуми мәйданы 186 120 гектардан ким булмаячак, ә Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе бөтен чорына урманнардан файдалануның гомуми күләме 2 079 200 гектар тәшкил итәчәк.

Кайбер урманчылыкларда урманнардан Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясының 2 өлеше нигезендә билгеләнгән эшчәнлекнең

башка төрләрендә файдалану өстенлекле булачак, ел саен урманнар 17718,8 гектар мәйданда файдаланылачак.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләре һәм торак пунктлар реестрында электр энергиясе һәм су белән өзлексез тәэмин итүгә ихтыяҗ булган республика әһәмиятендәге 14 шәһәр, район әһәмиятендәге 9 шәһәр, 18 ш.т.п., 3076 авыл торак пункты бар, шулай ук урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү, рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм башка максатларда файдаланганда, һичшиксез, тиешле инфраструктура булдыру зарур (электрүткәргеч линияләр, трассалар, торба үткәргечләр), ә бу урманнардан линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында файдалануга китерә. Шул рәвешле урманнардан линияле объектлар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү максатларында файдалану барлык урманчылыкларда теге яки бу дәрәҗәдәге ешлыкта гамәлгә ашырыла, ә Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына урманнардан файдалануның гомуми күләме 90376,7 гектар тәшкил итәчәк.

### 4.4. Үзләштерү интенсивлыгы буенча бүлеп, файдалануның төрле төрләре өчен планлаштырылган урманнарны үзләштерүне зоналарга бүлү

Агач материалы әзерләү, рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылма ятмаларын эшкәртү, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 6 статьясының 2 өлешендә билгеләнгән башка төрләр төбәктә урманнардан файдалануның аеруча перспектив төрләре булуын исәпкә алып, билгеле бер урманчылыкларда урманнардан файдалануның нәкъ менә шушы төп төрләре буенча төбәк урманнарын үзләштерүнең планлаштырылган зоналары бүленде. Үз чиратында урманчылыклар буенча урманнардан файдалану ешлыгы буенча бүлү Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына урманнардан файдалануның барлык төрләрен исәпкә алып башкарылды.

Урманнардан файдалануның перспектив юнәлешләрен планлаштырган вакытта һәр урманчылык буенча түбәндәге факторлар исәпкә алынды: Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның элеккеге чорында урманнардан файдалануның план күләмнәренә һәм юнәлешләренә ирешү, файдалы казылмаларның разведка үткәрелгән күләмнәре турында мәгълүмат, рекреация билгеләнешендәге гамәлдәге һәм планлаштырылган объектларны урнаштыру, агач эшкәртү предприятиеләрен урнаштыру, урманнарның максатчан билгеләнешеннән чыгып, урманнардан файдаланудагы чикләүләр.

Үткәрелгән анализ нигезендә, шулай ук табигый-географик районлаштыруны исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә

ихтимал булган файдалану ешлыгы һәм файдалану юнәлешләре буенча аерылып торган зоналар ачыкланды.

Файдалану төрләре буенча зоналарга бүленеш һәм файдалану ешлыгы буенча бүлү турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Урман планына 4 нче карта-схемада бирелде.

Файдалануның ешлыгы зур булган зонага Кама алдының көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләре һәм Кама аръягының көньяк-көнчыгыш өлеше карый, ул 18 урманчылыкны, шул исәптән аңа Әгерҗе, Азнакай, Әлмәт, Арча, Баулы, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Исләйтар, Кәләй, Лаеш, Лениногорск, Минзәлә, Түбән Кама, Шәһәр яны, Саба, Чирмешән урманчылыклары керә.

Югары ешлыклы зона территориясендә төбәк үзәге – Казан шәһәре, шулай ук эре сәнәгать шәһәрләре – Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт урнашкан, аларда төбәкнең эшкә сәләтле халкының күп өлеше яши. Әлеге зона территориясе буенча, күп санлы төбәк юлларыннан тыш, шулай ук 3 федераль автомобиль трассасы, Куйбышев тимер юлы уза.

Моннан тыш, әлеге зонада «Татнефть» ААҖ, «ТАИФ-НК» ААҖ, «Түбән Кама Нефтехим» ААҖ, «Казаноргсинтез» ААҖнең барлык төп сәнәгать объектлары, өзлексез җитештерү өчен кирәкле даими эшләүче һәм үсүче инфраструктурага мохтаж предприятиеләр тупланган. Нәкъ менә шул зонада – төбәкнең җир асты байлыкларының төп файдалы казылмасы – нефтьнең разведка үткәрелгән барлык ятмалары тупланган.

Урманнардан файдалануның уртача ешлыгы булган зонага республиканың үзәк өлеше карый, ул 9 урманчылыкны: Аксубай, Әлки, Биләр, Болгар, Кама, Кызыл Йолдыз, Мамадыш, Нурлат, Лубян урманчылыкларын үз эченә ала. Әлеге зонаның үзәктә урнашуы, күп санда торак пунктлар булу, шулай ук мул сулы ике елга – Идел һәм Кама елгасы белән уратып алынуы өстенлек булып тора, әмма тимер юлларның һәм эре сәнәгать объектларының булмавы урманнардан файдалануның ешлыгы уртача булуны күздә тота.

Урманнарны файдалану түбән ешлыкта булган зонага Идел алды керә, аның составында Татарстан Республикасының Буа, Кайбыч, Идел буе, Тәтеш урманчылыклары урнашкан, ул урманнарның аз булуы белән (уртача алганда 11,9 процент тәшкил итә), шулай ук нык үскән авыл хуҗалыгы алып барылу белән аерылып тора, моның сәбәбе районда соры, көлсу, кара туфрак күбрәк булуы белән аңлатыла.

Урманнардан файдалануның төп төрләре ачыклануны исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясе файдалану төрләре буенча зоналарга бүленде.

Урманнардан агач материалы әзерләү максатларында файдалану Әгерҗе һәм Зәй урманчылыкларында башкарылыр дип ниятләнә, анда урманнардан файдаланучы «Бөгелмә урман комбинаты» ҖЧҖ, «Хазар» ҖЧҖ, «Урман» ҖЧҖ кебек агач әзерләү оешмалары урнашкан, алар өлешенә урманнарның гомуми мәйданыннан әлеге максатларда урманнан

файдалануның Әгерҗе урманчылыгына 89,9 проценты, Зәй урманчылыгына 20,3 проценты туры килә, шуңа күрә әлеге урманчылыклар урманнардан файдалануның югары ешлыгы күзәтелгән зонага карый. Шулай ук урманнардан агач материалы әзерләү максатларында файдаланучы тагын ике арендатор бар: хосусый эшкуар Зиннәтуллин һәм «Елхово урманы» ҖЧҖ, әмма әлеге арендаторлар урнашкан урманчылыкларда агач материалы әзерләү урманнардан файдалануның өстенлекле төре булып тормый. Урманнардан бу төрдә файдаланучылардан тыш, башка арендаторлар юк.

Янәшәсендә урман-сулар урнашкан торак пунктлар янындагы матур урыннар урманнардан рекреация максатларында файдалану өчен аеруча кызыктыргыч булып тора. Татарстанда зур шәһәрләр янындагы Урман паркы зоналары һәм Яшел зоналар, шулай ук Идел һәм Кама буйларындагы урман биләмәләре әлеге таләпләргә җавап бирә. Урманнардан рекреация максатларында файдалану Татарстан Республикасы Урман планының 4 нче карта-схемасында бирелде. Әлеге зонага Шәһәр яны, Зеленодольск, Лаеш, Ислейтар, Түбән Кама, Алабуга урманчылыклары керә, аларның чикләрендә зур торак пунктлар, шулай ук су объектлары бар, нәкъ менә шушы урманчылыклар урманнардан рекреация максатларында файдалануны иң зур күләмдә гамәлгә ашыра (гомуми күрсәткечнең 76,6 проценты).

Шулай ук Биләр, Болгар һәм Шәһәр яны урманчылыкларында Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына урманнардан файдалануның төп төре рекреация эшчәнлеге булачак, тик районнарда халык саны аз, урманчылыкларның урнашкан урынын һәм эре шәһәрләр булмавын исәпкә алып, урманнардан файдалану уртача һәм аз күләмдә планлаштырыла.

Билгеле булганча, Татарстан Республикасында урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү буенча эшләр башкару максатларында файдалану төбәк икътисадын даими югары дәрәҗәдә тотучы төп чимал – нефть табу максатларында гамәлгә ашырыла. Урманнардан бу төр файдалану, нигездә, нефть ятмаларына разведка үткәрелгән урыннарда, шулай ук магистраль торба үткәргечләр челтәре һәм нефть продуктларын эшкәртү буенча комплекслар челтәре төзелгән һәм эшли торган районнарда булачак. Әлеге максатларда төбәкнең көньяк-көнчыгыш өлешендә – Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Кәләй, Лениногорск, Чирмешән урманчылыкларында урманнардан күп, Аксубай, Нурлат урманчылыкларында уртача күләмдә файдалану күздә тотыла. 2017 елда әлеге урманчылыклар өлешенә урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү буенча эшләр башкару максатларында файдалануның бу юнәлештә урманнардан файдалануның гомуми күләменнән 90,4 проценты туры килә һәм 10954,4 гектар тәшкил итә, ә 2029 елга бу күрсәткеч 12205 гектарга җитәргә тиеш.

Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру максатларында файдалануны аучылык ресурслары зур булган

урманчылыкларда башкару ниятләнә. Аларга Әлки, Арча, Кама, Кызыл Йолдыз, Мамадыш, Минзәлә, Саба, Тәтеш, Лубян урманчылыклары керә.

РФ УК 6 статьясының 2 өлеше нигезендә билгеләнгән урманнардан файдалануның башка төрләре төрле максатларда урманнардан файдалану минималь, урманнар аз булган һәм хуҗалыкның башка тармагы – авыл хуҗалыгы үсеш алган урманчылыкларда башкарылыр дип ниятләнә. Әлеге территорияләргә Кайбыч һәм Буа урманчылыгы урманнары карый.

Юлларның үсеш алган челтәре, торак пунктларның күплеге һәм сәнәгать инфраструктурасы төзелгән булу Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына урманнардан барлык төрләр буенча файдалануны алдан билгели.

Файдалануның төрләре өчен, үзләштерү ешлыгы буенча бүлеп, урманнарны планлаштырылган үзләштерү зоналарының 4 нче карта-схемасы Татарстан Республикасы Урман планына 1 нче кушымтада бирелде.

### 4.5. Урман һәм урман эшкәртү инфраструктураларын аларның барлыгы һәм урманнардан файдалануның төрләре өчен урманнарны үзләштерү перспективаларын исәпкә алып планлаштырылган үсеше

Урман инфраструктурасы күрсәткечләре барыннан элек юллар челтәре белән сыйфатлана. Урманнарга транспорт керү һәм транспорт юллары белән тәэмин ителү сыйфатламасы әлеге Татарстан Республикасы Урман планының 3.10 бүлегендә тасвирланды, урманчылыкларның транспорт юллары белән тәэмин ителү дәрәҗәсе турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Урман планына 19 нчы кушымтада бирелде, мәгълүматларга караганда, барлык урманчылыклар транспорт юллары белән яхшы тәэмин ителгән.

Татарстан Республикасы агач эшкәртү тармагының әйдәп баручы предприятиеләре булып «Зеленодольск фанера заводы» ГАҖ, «Идел буе фанера-җиһаз комбинаты» ҖЧҖ һәм «Кастамону Интегрейтед Вуд Индастри» ҖЧҖ тора, алар урман кишәрлекләреннән читтә урнашкан, җитештерү эшчәнлеге өчен кирәкле инфраструктура белән тәэмин ителгән. Киләсе Татарстан Республикасы Урман планы гамәле чорына урман эшкәртү инфраструктурасын үстерү планлаштырылмый.

### 4.6. Урман кишәрлекләрен план буенча файдалануга тапшыру турында белешмәләр

Урманчылыклар кисемендә, шулай ук файдалану төрләре күзлегеннән чыгып, Татарстан Республикасы Урман планы гамәлдә булуның киләсе чорына план буенча урман кишәрлекләрен файдалану өчен тапшыру турында белешмәләр Татарстан Республикасы Урман планына 23 нче кушымтада бирелде.

## 4.7. Урманнарны янгын куркынычы янау класслары буенча бүлү, урманнарны янгыннардан саклау буенча чаралар үтәүнең план күрсәткечләре

Төбәк урманнарының табигый янгын чыгу куркынычы класслары буенча бүленеше 9 нчы таблицада күрсәтелде.

9 нчы таблица

Татарстан Республикасы урманнарының табигый янгын чыгу куркынычы класслары буенча бүленеше

| Урманчылыкның аталышы | Үлчәү берәмлеге | Янгын чыгу куркынычы классы | | | | | Барлыгы | Уртача классы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV | V | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнар | | | | | | | | |
| Әгерҗе | гектар | 5510.1 | 2157.7 | 10479.2 | 19995.3 | 7203.7 | 45346 | 3.5 |
| | процент | 12.2 | 4.8 | 23.1 | 44.1 | 15.9 | 100 | |
| Азнакай | гектар | 404 | 1127 | 9659 | 34028 | 885 | 46103 | 3.7 |
| | процент | 0.9 | 2.4 | 21.0 | 73.8 | 1.9 | 100 | |
| Аксубай | гектар | 1291 | 690.3 | 1225.3 | 13735.1 | 12680.3 | 29622 | 4.2 |
| | процент | 4.4 | 2.3 | 4.1 | 46.4 | 42.8 | 100 | |
| Әлки | гектар | 1940 | 966 | 1691 | 30553 | 2312 | 37462 | 3.8 |
| | процент | 5.2 | 2.6 | 4.5 | 81.6 | 6.2 | 100 | |
| Әлмәт | гектар | 101 | 4471 | 23538 | 20451 | 1605 | 50166 | 3.4 |
| | процент | 0.2 | 8.9 | 46.9 | 40.8 | 3.2 | 100 | |
| Арча | гектар | 6577.2 | 0 | 6749 | 14094.4 | 4782.4 | 32203 | 3.3 |
| | процент | 20.4 | 0.0 | 21.0 | 43.8 | 14.9 | 100 | |
| Баулы | гектар | 1932.4 | 13534.2 | 1502.8 | 4147.1 | 2320.5 | 23437 | 2.6 |
| | процент | 8.2 | 57.7 | 6.4 | 17.7 | 9.9 | 100 | |
| Биләр | гектар | 1285.6 | 1764 | 812.9 | 35816.8 | 11095.7 | 50775 | 4.1 |
| | процент | 2.5 | 3.5 | 1.6 | 70.5 | 21.9 | 100 | |
| Болгар | гектар | 1829 | 931 | 2171 | 11257 | 2664 | 18852 | 3.6 |
| | процент | 9.7 | 4.9 | 11.5 | 59.7 | 14.1 | 100 | |
| Бөгелмә | гектар | 4996.2 | 21882.2 | 4417 | 8917.5 | 3920.1 | 44133 | 2.7 |
| | процент | 11.3 | 49.6 | 10.0 | 20.2 | 8.9 | 100 | |
| Буа | гектар | 451 | 541 | 2218 | 14160 | 1197 | 18567 | 3.8 |
| | процент | 2.4 | 2.9 | 11.9 | 76.3 | 6.4 | 100 | |
| Алабуга | гектар | 3060.1 | 4017.5 | 4423.2 | 14580.7 | 2971.5 | 29053 | 3.4 |
| | процент | 10.5 | 13.8 | 15.2 | 50.2 | 10.2 | 100 | |

